МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№3 / март 2013



ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Башкалабызның Каюм Насыйри урамындагы 11 нче йорт
Казан сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе, иганәче
Борһанетдин Фәхретдин улы Муллин (1836-1917) йорты.
Йорт XIX йөзнең II яртысында төзелә.

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№3 (15) / март 2013

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Ренат МИҢНЕГАЛИЕВ
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректорлар:
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ № С-510
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Басарга кул куелды: 28.02.2013
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **Алтын Урда дәүләтендә (Җучи олысында) сәүдә итүне оештыру үзенчәлекләре.** *Азат Арсланов*
14 **XIX гасыр ахыры — XX йөз башы төрек-татар багланышлары.** *Исмәгыйль Төркуглы*
30 **Милли матбугат: үткәне һәм бүгенгесе. «Кызыл» сүзендә бернинди сәясәт юк...»** *Фаил Фәтхетдинов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*
34 **Без тарихта эзлебез.** («Мәгариф» журналына 100 ел) *Габделхак Шәмсетдинов*
38 **Гаилә һәм җәмгыять тоткасы.** *Илдус Заһидуллин, Ленар Гобәйдуллин*
46 **Гаилә — миллəтнең нигезе яки татар гаиләсендә бала тууга мөнәсәбәт.** *Гүзәл Галиева*
57 **Гасырлардан килгән хәзинә.** *Марат Гыйбатдинов, Ләлә Мортазина*
58 **Мәшһүр хатыннар.** *Маһруй Мозаффария*
59 **«...Ирекләнер чаклар житте, ирекләник».** *Альта Мәхмүтова*
65 **«Әй, газизә бикәләр!» [Маһруй Мозаффария. Нәсыйхәтнамә лиәһли заманиһи].** *Ленар Гобәйдуллин*
69 **Ханымнар.** *Мәхмүдә Мозаффария*

СӘНГАТЬ

72 **Уйнап узган гомер.** (Нәҗибә Ихсановага 75 яшь) *Луара Шакирҗан*
78 **Альтернатив... яки кинәсез кино.** *Әхтәм Зарипов*
83 **«Мәхәббәттән башка берни белмисең син...»** *Рәдиф Гаташ*

ӘДӘБИЯТ

86 **Караш җитмәсне колачлаган әдип.** (Рабит Батуллага 75 яшь) *Дания Заһидуллина*
100 **Мәһди йолдызлыгы ни сөйли?** *Рашат Низами*
107 **Алда безне ни көтә?** (Рәфикъ Юныска 70 яшь) *Рәфикъ Юныс белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе*
112 **Батырша.** *Фәүзия Бәйрәмова*

120 **Тарих сәхифәләреннән**

Яңа китаплар. *Илдус Заһидуллин*

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә
язылырга мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә — Казан татарлары гаиләсе табын янында. *XIX гасыр ахыры — XX йөз башы. Традиционная культура татар XIX-XX веков (Санкт-Петербург, 2012) китабыннан;*
4 нче битендә — хәзерге Чистай шәһәре тирәсендә яшәүчеләрнең күкрәк бизәгенә тагылган айсыман асылма. *Идел Болгарстаны. XI-XIII гасырлар*

Бу санда авторларның, Л.Гобәйдуллин, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Хөрмәтле укучыларыбыз!
«Чын мирас» журналының 1 нче һәм 2 нче саннарында (кайбер нөсхәләрдә) нәшрият хезмәткәрләренең игътибарсызлыгы аркасында киткән техник хаталар өчен сездән гафу үтенәбез.

ТАРИХ

...Кайттылар ла, тарих, кайттылар
Вөҗданы пакь, зурга хаклылар.
Исән кайтты исән булганнар
Һәм терелеп кайтты үлгәннәр —
Пакь исемнәр безгә кайттылар.

Рәдиф Гаташ

АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНДӘ (ҖУЧИ ОЛЫСЫНДА) СӘҮДӘ ИТҮНЕ ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

АЗАТ АРСЛАНОВ,
Казан (Идел буе) федераль университеты
Тарих институтының татар халкы тарихы кафедрасы аспиранты

УРТА ГАСЫР ЕВРАЗИЯ КҮЧМӘННӘРЕ ҺӘМ УТРАК ТОРМЫШТА ЯШӘГӘН СӘҮДӘГӘРЛӘР АРАСЫНДА ТЫГЫЗ ИКЪТИСАДИ МӨНӘСӘБӘТЛӘР БУЛУЫН ШУЛ ЧОРДА УК КҮПСАНЛЫ СӘЯХӘТЧЕЛӘР БИЛГЕЛӘП ҮТКӘН. ТАРИХЧЫЛАР ДА ҮЗЛӘРЕНЕҢ ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ШУНДЫЙ УК НӘТИҖӘ ЯСЫЙ.

Галимнәр фикеренчә, бу күренешнең төп сәбәбе күчмәннәр икътисадының табигый рәвештә терлекчелек товарларын гына җитештерүгә юнәлтелгән булуыннан гыйбарәт, калган кирәк-яраклар я бөтенләй җитештерелмәгән, яисә аларны җитештерү күләме чиктән тыш азсанлы булган дип билгеләнә.

Нәкъ менә шул сәбәпле күчмәннәр даими рәвештә савыт-саба, тукыма, башка төрле һөнәрчелек товарларына, көз һәм кыш айларында терлек азыгына кытлык кичергәннәр. Бу товарларны алар күршеләреннән — утрак тормышта яшәүче халыклардан таба алганнар. Шуңа күрә күчмә халыклар акрынлап утрак тормыш алып барган зур дәүләтләр белән сәүдә мөнәсәбәтләренә керә башлыйлар.

Тора-бара күчмә һәм утрак дөнья арасында сәүдәнең масштабы киңәя. Әмма бу, үз чиратында, икенче кыенлык тудыра. Сәүдәнең интенсивлыгы арткан саен, күчмәннәрнең дә импорт товарларга, аларны җитештергән илләргә һәм сәүдәгә бәйлелеге арта дигән сүз. Әлеге күренеш сәүдәне күчмәннәр сәясәтенә тәэсир итү чарасы итеп кулланырга мөмкинлек биргән. Сәүдәгәрләрнең, аеруча ерак илләргә сәфәр кылып сату-алу итүчеләрнең даими рәвештә яңа һәм, иң мөһиме, табышлы базарларны эзләү

Кытайда Венеция сәүдәгәрләре. Марко Полоның сәяхәтнамәсеннән, 1412 ел

ихтыяҗы барлыкка килгән. Бу ихтыяҗны алар күчмә ыруглар белән сәүдә итеп канәгатьләндергәннәр. Болар һәммәсе күчмәннәр һәм сәүдәгәрләр арасында ике як өчен дә файдалы мөнәсәбәтләр урнашуына китергән. Шул сәбәпле күчмәннәр җәмгыятендә төрле мәдәниятләрнең тыгыз бәйләнышына мөмкинлек тудырыла. Күрәсең, нәкъ менә шул күренеш күчмә кабиләләр берләшмәсендә дәүләтләрнең барлыкка килүенә төп этәргеч ясый.

Әлеге фикерне Гарвард университеты профессоры Омельян Прицак кебек кайбер чит ил галимнәре дә әйтә. Аның карашынча, нәкъ менә сәүдәгәрләр, үзләренә күрә бер катализатор ролен башкарып, күчмәннәр империяләренең барлыкка килүенә этәргеч ясаган төп көч булган [1]. Шулай итеп, монгол яуларының төп сәбәбенә караш та бераз үзгәреш кичерә. Әгәр дә элек без монгол яуларының төп сәбәбен бары тик күчмә терлекчелеккә һәм, гомумән, яшәү өчен яңа җирләргә ихтыяҗда күрсәк, хәзерге көндә без, мөгаен, сәүдә мәнфәгатьләре дә күздә тотылгандыр, дип әйтә алабыз. Урта Азия һәм Көнбатыш Европа дәүләтләренә юнәлтелгән яулап алу сугышлары, бу күзлектән караганда, иң интенсив һәм сәүдәгәрләр тарафыннан актив файдаланылган кәрван сәүдә юлларын кулга алырга омтылыш буларак күзаллана.

Чыңгызыйларның сәүдә эшләре белән кызыксынуы инде күптәннән билгеле. Моны чагылдырган тарихи документлар да шактый күп. Шуларның иң билгелесе — 1266 һәм 1271/1272 еллар аралыгында Җучи Олысы ханы Мәңгү Тимер тарафыннан Владимир кенәзе Ярослав Ярославовичка биргән ярлык [2]. Әлеге документта кенәзгә Рига сәүдәгәрләрен Новгород җирләре аша Алтын Урда шәһәрләренә тоткарлыксыз уздырырга [3] дигән әмер бирелә. Ярославка ярлыкның эчтәлеген Ригада яшәүчеләргә дә җиткерергә кушыла. Әмергә җавап буларак, Ярослав Рига сәүдәгәрләренә аларны яклаячагы һәм үз өлкәсе аша юлларның ачык булуы турында грамота җибәрә [4].

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: сәүдәгә карата булган уңай

1. Пріцак О. Походження Русі. Стародавні скандинавські джерела (крім ісландських саг). [переклад з англійської О.Буценка та Ю.Олійника]. — Т.І. — Киев: Обереги, 1997. — С.10-20.

2. Гатин М. Ярлык Менгу-Тимура князю Ярославу Ярославичу // Гатин М., Абзалов Л. История татар с древнейших времён в семи томах. — Том 3: Улус Джучи (Золотая Орда). XIII — середина XV вв. — Казань, 2009. — С.851.

мөнәсәбәт һәм чит ил сәүдәгәрләренең куркынычсызлыгын кайгырту Мәңгү Тимергә генә түгел, ә барлык монгол дәүләтләре башлыкларына да хас булган.

Шуңа нисбәтле, әлеге кыска гына мәкаләнең төп максаты — сәүдәгәрләр һәм Алтын Урда аристократиясе арасында урнашкан мөнәсәбәтләрнең характерын билгеләү. Теманы ачып бирү өчен, безгә түбәндәге сорауларга җавап табарга кирәк: Алтын Урдада сәүдәгәрләрнең статусы нинди булган? Сәүдәгәрләр аристократиягә һәм ханнарга нинди файда китергәннәр? Сәүдәгәрләрнең дәүләт сәясәтенә тәэсире нинди булган? «Уртак»ларның Алтын Урда үсешенә керткән өлеше ни дәрәҗәдә? Тикшерү барышында безнең төп игътибар «уртак»ларга юнәлтелә. Моның сәбәбе бик гади. Нәкъ менә сәүдәгәрләрнең әлеге төркеме аристократия белән турыдан-туры мөнәсәбәттә яши.

Урта гасыр көнчыгыш чыганакларында гарәби «таджир» термины белән берлектә еш кына төрки «уртак» термины да очрый [5]. Әлеге термин борынгы һәм хәзерге заман төрки телләрендә «үзенең хезмәттәше, компаньоны белән берлектә эшләгән кеше»не аңлата [6]. Атаманың килеп чыгышын һәм урта гасырларда кулланышын өйрәнгән төрек галимәсе Мәләк Озйетгин (Ozyetgin A. Melek) фикеренчә, бу термин нәкъ менә шул мәгънәдә уйгырларда киң таралган була. «Уртакчы»лар институтының барлыкка килүе һәм киң күләмдә таралышы да шушы халык белән бәйле. Уйгырлардан әлеге күренешне соңрак монголлар да үзләштергәннәр [7]. «Уртак» исеме белән, гадәттә, заем капитал ярдәмендә сәүдә иткән аерым сәүдәгәрне дә, сәүдә белән шөгыльләнгән ширкәтләрне дә атаганнар. Әгәр дә беренче очракта сәүдәгәр кемнәндер алып торылган акча ярдәмендә эш итсә, икенче очракта сәүдә итү өчен капитал ширкәттә булган һәрбер сәүдәгәрнең керткән акчасыннан формалашкан. Әлбәттә, «уртак» дип исемләнгән сәүдә ширкәтләре бары тик үз акчалары белән генә эш иткән дигән сүз түгел, алар кирәк чакта аристократларга һәм ханнарга матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итә алган.

«Уртак» терминының югарыда атап үтелгән мәгънәләрдә кулланылуы башка көнчыгыш чыганаклары белән дә дәлилләнә. Мисал өчен XIV нче гасыр фарсы тарихчысы Шиһабеддин Габдуллаһ ибне Фазыйлаллаһ Ширази үзенең «Тарих-и Вассаф» дип исемләнгән хезмәтендә әлеге атаманы шактый еш куллана. Бу хезмәттә «уртак» термины Бәркә хан сәүдәгәрләренә нисбәтле әйтелә. Шулай ук әлеге терминны без Рәшидетдин һәм Җувәйни хезмәтләрендә дә очратабыз. Биредә «уртак» сүзен ул аерым сәүдәгәрләргә дә сәүдә белән шөгыльләнгән ширкәтләргә карата да куллана.

Төрки «уртак» терминының берничә синонимы булган. Монгол империясенең төрле төбәкләрендә терминга хас мәгънәне төрле сүз белән атаганнар. Юань чорына караган (1271-1368 еллар) Кытай чыганакларында охшаш мәгънәгә ия булган «wot'o» сүзе очрый. Монгол телендә «orto[γ]» сүзе бар. Институт буларак «уртак»лар Җучи Олысында да булган. Алтын Урда чорына

3. Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266-1359 гг.) / сост., вступ. ст., коммент., указатели, подбор иллюстрации и карт М.С.Гатин, Л.Ф.Абзалов. — Казань: Татар. кн.изд-во, 2011. — С.258.

4. Шунда ук.

5. Якубовский А.Ю. Развалины Ургенча — Л.: ГАИМК, 1930. — С.14.

6. Özyetgin A.M. On the Term Ortuq (~ Ortaq) Merchant among the Old Turks // International Journal of Central Asian Studies. – Vol.11-1. — 2007. — P.6.

7. Шунда ук. — Б.8.

8. Шунда ук. — Б.6.

Баскаклар.
С.В.Иванов.
1909 ел

бәйле төрки телле текстларда «bāzirgān» сүзе еш кына кулланыла. Мәләк Озйетгин Алтын Урда чоры ярлыкларында бу сүз «уртак» термины белән берлектә кулланыла, дип билгели [8].

«Уртак»лар сәүдә итәргә кирәк булган акчаны, ханга мөрәҗәгать итеп, дәүләт казнасыннан аз процентка алганнар һәм тиешле сумманы алдан билгеләнгән вакытка кире кайтарырга тиеш булганнар. Шунысы кызык: акча көмеш я алтын тәңкәләр белән түгел, ә сатырга алынган товарның бер өлеше белән сәүдәгәрдән ханга бүләк формасында кайтарылган. Америка галиме Томас Олсен тагын шуны да билгеләп китә: ханнарның сәүдәгә инвестицияләре шулай ук табигый формада — ханның сәүдәгәргә бүләге рәвешендә башкарылган [9]. Әлеге операциягә карата «sauya», ягъни бүләк термины кулланылган [10]. Бу үзенчәлекне күздә тотканда, венецияле сәүдәгәрләрдән бертуган Пололарның 1260 елда Бәркә хан белән очрашу турындагы истәлекләре бөтенләй башка мәгънәви төсмер ала. Марко Полоның «Дөньяның күптөрлелеге турында китап» дип аталган хезмәтендә тасвирланган әлеге очрашуның кайбер әһәмиятле детальләрен шәрехләп үтәбез. Сәүдәгәр Николо һәм аның туганы Маффео Бәркә ханга бүләк итеп кыйммәтле ташлар тапшыра. Хан, авторның язмаларына караганда, бүләкне бик шатланып кабул итә һәм ташлар өчен икеләтә арттырып түләргә әмер бирә, өстәвенә күптөрле кыйммәтле бүләкләр дә тапшыра. Автор билгеләвенчә, болар, ким дигәндә, венецияле сәүдәгәрләрнең ханга биргән бүләкләреннән ике тапкыр кыйммәтрәк була [11]. Алга таба бу бүләкләр сәүдәгәрләр тарафыннан сатылып, аларга шактый зур табыш китерә [12].

Әлеге вакыйгалардан күренгәнчә, хан үз капиталының бер өлешен бертуган Пололарның сәүдә эшенә кертә һәм Поло гаиләсенең өлкән буын вәкилләре Бәркә ханның сәүдә агенты булып санала. Башкача әйткәндә, венецияле сәүдәгәрләр һәм Бәркә хан үзара «уртаклык» оештыралар [13].

9. Allsen T.T. Mongolian Princes and Their Merchant Partners 1200-1260 // Asia Major. — Princeton, NJ: Princeton University Press, 1989. — P.120.

10. Pelliot P. Sao-houa, Sauya, Sauyat, Saguate // T'oung Pao. — №32. — 1936. — P.230-237.

11. Марко Поло. Книга о разнообразии мира / Пер. И.М.Минаева. — М.: ЭКСМО, 2005. — С.6.

12. Allsen T.T. Mongolian Princes and Their Merchant Partners 1200-1260 // Asia Major. — Princeton, NJ: Princeton University Press, 1989. — P.120.

13. Шунда ук. — Б.121.

14. Шунда ук. — Б.116.

Бу очракта төп кредитор дәүләт булган, әмма «уртак»ларда ханнар гына түгел, аристократия вәкилләре дә катнаша алган. Монгол аристократиясенең сәүдә эшләрендә катнашу тәртипләренә Чыңгыз хан нигез салган. 1218 елда, хәрәзмшаһ Мөхәммәд белән солых төзегәч, хан үзенең туганнарына һәм якыннарына яулап алу сугышларыннан кергән табышны Хәрәзмгә сәүдә итү өчен җибәреләчәк кәрванга салырга әмер бирә.

Еш кына аристократия вәкилләре сәүдәгә салынган акчаларын ничек тә булса сакларга тырышкан. Моның өчен «уртак»ларга аерым, аларның файдасына тулы куәте белән уңай ярдәм итә торган мөмкинлекләр тудырылган. Бик еш кына бу гамәлләр чамадан артып киткән һәм дәүләт мөлкәтен максатчан файдаланмау очраклары да булган. Мисал өчен Чыңгыз ханның дүртенче улы Тулуйның хатыны һәм Монгол империясенең дүртенче бөек ханы Мункәнең анасы Сорхуктани бервакыт Үгәдәй ханнан үзенең илчелеге составына «уртакчылар» ын керүне таләп итә. Мондый таләпнең мәгънәсе бик гади. Илчеләр сафына кертелгән сәүдәгәрләр юлда Монгол империясе түрәләренә тиеш булган барлык ташламалардан да файдалана алган һәм шулай итеп аларның юл чыгымнары бермә-бер кимегән. Бу, үз чиратында, чиста керемнең артуына китергән [14]. Сәүдәгәрләрнең юл чыгымнарын киметү өчен, аларга махсус ярлыклар бирелгән. Әлеге документларга ия затлар статус ягыннан дәүләт түрәләре, илчеләр һәм салым җыючылар белән бертигез йөргән. Димәк, «уртак»ларга (сәүдәгәрләргә) ямнарда, ягъни почта станцияләрендә бушлай атлар алыштыру һәм кораллы сакчылар белән сәяхәт итү, бушлай азык-төлек алу кебек мөмкинлекләр дә биргән. Шулай ук бу документ сәүдәгәрләрне башка төр салым һәм җыемнардан да азат иткән.

Моннан тыш сәүдәгәрләр башка өстенлекләргә дә ия була. Икътисади яктан моның файдасы бик үк булмаса да, ул «уртакчы» сәүдәгәрләрнең аерым социаль урынын билгеләп торган. Кытайда Юань императорлары идарә иткән дәвердә сәүдәгәр «уртаклар» , алда саналып үткән өстенлекләрдән тыш, үзләре белән корал йөртү хокукына ия була. 1263 елгы Хубилай карарында корал йөртергә хокукы булган халыклар һәм социаль төркемнәрнең исемлеге бирелә. Алар — монголар (Ta-ta), уйгырлар (Wei-wu-erh), мөселманнар (Hui-hui), «уртак»лар (wo-t'o), даругачы һәм баскаклар (ta-lu-hua-chi'ih) [15].

Сәүдәгәрләргә карата һәрьяклап ярдәм итү һәм мөмкин кадәр уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән дәүләт сәясәте, монгол империясе тәхетенә 1251 елда бөек хан Мункә килгәч, берникадәр үзгәрешләр кичерә. Аның әмере белән сәүдәгәрләрдән ташламалар биргән ярлыклар алына һәм дәүләт ресурсларыннан бушлай файдалану мөмкинлеге бетерелә [16]. Мункә башлап җибәргән бу эшне Хубилай хан дәвам итә. 1263 елда ул барлык сәүдәгәрләрдән салым һәм җыемнарны тулысынча түләтергә карар кыла [17]. Кораллы сакчылар белән сәяхәт итү хокукы саклана, әмма ре-

15. Endicott-West E.Merchant Associations in Yuan China: The Ortoy // Asia Major.- Princeton, NJ: Princeton University Press, 1989. — P.10-146.

16. Рашид ад-Дин. Сборник летописей. Т.II / Пер. с перс. Ю.П.Верховского, примеч. Ю.П.Верховского и Б.И.Панкратова, ред. И.П.Петрушевского. — М.-Л., 1960. — С.141.

17. Endicott-West E.Merchant Associations in Yuan China: The Ortoy // Asia Major. — Princeton, NJ: Princeton University Press, 1989. — P.10-146.

формалардан соң сакчыларга сәүдәгәрләр үзләре түләргә тиеш була [18].

Шулай итеп, Мункә хан һәм Хубилай хан чорыннан сәүдәгәрләр өстенлекләрен югалта, әмма, гомумән алганда, дәүләт башлыкларының, аристократиянең сәүдәгәрләргә карата булган позитив һәм сакчыл карашы үзгәрми. Монгол дәүләтенең аерым олыс хөкемдарлары, шул исәптән Алтын Урда ханнары, бөек ханнарның карарларын читләтеп уза. Алар сәүдәгәрләргә шәхси тарханлык биреп, салым һәм җыемнар түләүдән азат итә. Моннан тыш ханнар үз сәүдәгәрләренең сәүдә итү мөмкинлекләрен киңәйтергә тырыша һәм аларның эшкуарлык итү мөмкинлеген чит илләрдә дә җайга салырга омтыла. Мондый омтылышның иң ачык мисалы Алтын Урда ханнарының дипломатик хатларында күренә. Хатларда сәүдәгәрләр бик еш телгә алына. Мисалга Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәтнең төрек солтанына язган хатын гына алыйк. Әлеге хатта хан солтанга дипломатик мөнәсәбәтләрне яңадан торгызырга тәкъдим итә һәм махсус рәвештә: «Коры җирдән һәм судан элеккеге кебек сәүдәгәрләр йөрсен», — дип мөрәҗәгатен тәмамлый [19].



Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәднең төрек солтаны Мурат IIгә язган хаты. 1428 елның 14 марты.
ТР Милли архивы. Ф.169. Оп.1. Д.5.

Чит илләрдә эш иткән Алтын Урда сәүдәгәрләренә һәм, беренче чиратта, «уртак»ларга карата булган мөнәсәбәт ханнарның игътибарын һәрвакыт үзенә җәлеп итеп торган. Җучилылар үз сәүдәгәрләренә карата шәфкатьсез һәм гадел булмаган мөнәсәбәткә бик катгый җавап биргән. Моны аңлатуы бик җиңел. Урта гасырларда сәүдәгәр — ул дәүләтенең мәдәни һәм икътисади элитасы вәкиле, чит җирдә илнең йөзе, дип әйтсәк тә арттыру булмас. Шуңа күрә сәүдәгәрне мыскыллау яки аңа зыян китерү ханның үзенә, гомумән, дәүләткә һөҗүм итү кебек бәяләнгән. Мондый очраклар, гадәттә, бик тискәре нәтиҗәләргә китергән. Мисал өчен, 1343 елда Азак (Азов) шәһәрендә Алтын Урданың Венеция белән мөнәсәбәтләренә шактый җитди тәэсир иткән вакыйга була. Күренекле венецияле сәүдәгәр Андреоло Чиврано, Алтын Урда сәүдәгәре Хуҗа Гомәр белән сугышып, аны үтерә. Бу хәбәрне ишеткән Җанибәк хан, җавап буларак, бөтен венециялеләрне тиз арада 5 елга шәһәрдән куарга дигән әмер бирә [20]. Моннан тыш, хан әмере белән, Дон елгасы тамагында урнашкан Пиза сәүдәгәрләре карамагындагы Порто-Пизано шәһәре җир белән тигезләнә [21]. Хан болар белән генә канәгать булмый, 1344-1345 елларда Генуя сәүдәгәрләре яшәгән Кафа шәһәрен камап ала һәм аңа һөҗүм оештыра.

1353 елда Венеция белән Алтын Урда арасын бозарлык тагын бер вакыйга була. Урта диңгездә венециялеләр Генуя галерасына (ишкәкле хәрби корабль) һөҗүм итеп, аның пассажирларын әсирлеккә ала. Пассажирлар арасында берничә Алтын Урда сәүдәгәре дә була. Шул сәүдәгәрләрнең берсен үтерәләр, ә кал-

18. Di Cosmo N.Mongols and Merchants on the Black Sea Frontier in the Thirteenth and Fourteenth Centuries: Convergences and Conflicts // Mongols, Turks and others. Eurasian Nomads and the Sedentary World / Ed. by R.Amitai and M.Biran. — Leyden; Boston, 2005. — P.399-400.

ган икесен, чишендереп, төрмәгә ябалар. Бу хәлне белеп, Җучи Олысы ханы тагын үз сәүдәгәрләренең хокукын һәм иминлеген яклап чыга. Нәтиҗәдә, халыкара дәрәҗәдә озак елларга сузылган хөкем процессы башланып китә. Башка очраклардан аермалы буларак, бу юлы эш канкоешка кадәр барып җитми — корал кулланмыйча гына хәл ителә. Әлеге факт Алтын Урда ханнарының халыкара конфликтларны һәрвакытта да корал белән хәл итмәвен күрсәтә һәм ханнарның чиктән тыш канечкеч, мәрхәмәтсез булулары турында киң таралган карашны кире кага.

Сәүдәгәрләр дәүләтнең сәяси тормышында да актив катнашкан. Мәсәлән, сәяси көрәш һәм бәрелешләр вакытында алар теге яки бу дәүләт башлыгына ярдәм күрсәткән, шул рәвешле аны кирәкле суммада акча белән тәэмин итеп торган. Мәгълүм ки, 1313 елда тәхеткә Үзбәк хан утыру да мөселман сәүдәгәрләре өчен мөһим роль уйнаган. Сәүдәгәрләр ярдәме белән тәхеткә күтәрелгән ханнар, үз чиратында, алар алдында бурычлы булып калмаган. Урта гасыр гарәп тарихчылары ән-Нувайри, әл-Макризи һәм әл-Айни сурәтләгән вакыйгаларда Мисыр солтаны әл-мәлик-ән-Насыйр хан кызына өйләнмәкче була. Әлеге хәлне белгән Үзбәк хан үзенең кардәш туганының кызы Тулун бикәне хатынлыкка бирергә ризалаша, ләкин гаять зур калым таләп итә (ән-Нувайри китергән мәгълүматларга карганда, 100 томан алтын яки 1 миллион динар) [22]. Солтанның илчеләре үзләрендә андый сумма юклыгын әйткәч, хан: «Без сәүдәгәрләргә күпме түләргә кирәклеген хөкем итәргә кушарбыз», — дип җавап кайтара [23]. Шулай итеп, илчеләр калымны, Урда сәүдәгәрләреннән бурычка акча алып түләргә мәҗбүр булалар. Мөселман сәүдәгәрләренең алдарак Үзбәк ханга күрсәткән ярдәмен исәпкә алсак, әлеге вакыйганы рәхмәт йөзеннән эшләнгән гамәл дип санарга мөмкин. Шулай итеп, хан үзенең сәүдәгәрләренә файдалы табыш ясарга һәм илчеләрдән кергән акчаның проценты хисабына шактый зур керем алырга мөмкинлек бирә.

Тагын бер гаять кызыклы факт Алтын Урда сәүдәгәрләренең Җанибәк ханга булган тәэсирен сурәтли. Алда әйтелгәнчә, XIV гасырның 40 нчы елларында хан Кара диңгез буенда урнашкан Венеция һәм Генуэз колонияләре белән сугыш алып бара. Әмма 1350 елда сугыш хәрәкәтләрен кинәт туктата. Моның төп сәбәбе шунда ки, Италия республикалары белән сугыш алып бару сәбәпле, сәүдә мөнәсәбәтләре начарая һәм сәүдәгәрләрнең керемнәре бермә-бер кими [24]. Шуңа күрә сәүдәгәрләр, ханга мөрәҗәгать итеп, сугышны туктаталар. Күргәнебезчә, сәүдәгәрләрнең дәүләт сәясәтенә югары дәрәҗәдә йогынты ясарга шактый күп мөмкинлекләре булган.

Сәүдәгәр-«уртак»лар нинди хезмәтләре өчен шундый киң өстенлекләрдән файдалана һәм ханнарның шәхси ышанычын яулап ала алган соң? Әлеге сорауга җавап гади. Урта гасырларда кешеләр географиядән аз хәбәрдар булган. Алар бик сирәк очракта туган илләреннән киткән. Еш кына инсаннарның белеме туганнарының сугыш вакытында күргәннәре турында-

19. Султанов Т.И. Письмо золотоордынского хана Улуг-Мухаммеда турецкому султану Мураду II // Тюркологический сборник. 1973. — М., 1975. — С.55.

20. Григорьев А.П. Коллекция золотоордынских документов XIV века из Венеции / А.П.Григорьев, В.П.Григорьев. — СПб: Издательство СПбГУ, 2002. — С.79.

21. Хеллер К. Золотая Орда и торговля с Западом // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани. 1223-1556. — Казань, 2001. — С.118-119.

22. Гатин М.С. Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266-1359 гг.). — Казань: Татар. кн.изд-во., 2011. — С.118.

23. Шунда ук. — Б.119.

24. Шостак В. История черноморской торговли в средних веках. Ч.I. — Одесса: тип-я Л.Нитче, 1850. — С.86.

Алтын Урда шәһәре Азакта базар

гы мәгълүмат, азсанлы сәяхәтчеләрнең хикәяләре я күпсанлы сәүдәгәрләрнең сөйләүләре (чөнки аларның тормышлары чит җирләргә сәфәр чыгуларга бәйле) белән чикләнгән. Сәүдәгәрләр һәм сәяхәтчеләр Җучи Олысы территорияләре аша үтеп кенә китмәгән, ә җирле халык һәм дәүләт идарәчеләре белән аралашкан. Үзләренең чит илдә яшәү шартларын җайлаштыру максатыннан, алар белемнәре белән уртаклашкан һәм халыкны үзләре өчен гадәти булган яшәү рәвеше, мәдәният, әдәп кагыйдәләре буенча яшәргә өндәгән. Шул рәвешле, далаларда яшәүчеләр һәм Дәште Кыпчак шәһәрләре халкы мәгълүмат алмашу процессына кертелгән. Ерак дәүләтләр һәм үзләренең күршеләре турындагы мәгълүматларны гади халык кына түгел, ә ханнар да алган. Сәүдәгәрләр алар өчен информаторлар вазифасын башкарган, ягъни башка хөкемдарлар, территорияләр, гаскәриләр саны һ.б. турындагы белем чыганагы саналган.

Сарай эчендә сәүдәгәрләрнең абруе аларның ханга сирәк очрый торган әйбер алып кайтулары я кызыклы мәгълүмат, башка дәүләтләрдә барган хәлләр турында хәбәр итүләре белән бәйле булган. Алтын Урда ханы Бәркәнең һәм бөек хан Хубилайның Поло гаиләсенә, Чыңгызыйлар дәүләтендәге төрле ханнарның Ибн Баттутага мәрхәмәтле мөнәсәбәте шуның белән дә аңлатыла.

Монгол дәүләтенең оешу этабында һәм яңа басып алынган территорияләрдә административ институтлар формалашу барышында, хан алдында кадрлар проблемасы туа. Бик еш хакимнәр белемле кешеләр җитмәвеннән интеккән. Башта хакимияттәге вазифаларны башкарыр өчен, тиешле белемгә ия җирле элита вәкилләре чакырылган, әмма алар үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан. Әлеге хәлнең барлык куркынычлыгын аңлаган хакимнәр түрәләр аппаратын тугрылыклы белгечләр белән тәэмин итәргә омтылган. Идарә эшләрен башкарырдай һәм дәүләт институтларының эшләвен тәэмин итәрдәй кешеләр

күчмә аристократия арасында бик аз булу сәбәпле, хакимият сәүдәгәрләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган. Урта гасырларда сәүдәгәрләр халыкның иң укымышлы катламын тәшкил иткән. Алар укый-яза, исәп-хисап эшләрен алып бара белгән, берничә телдә сөйләшкән, башка дәүләтләрнең географиясеннән һәм икътисадыннан хәбәрдар булган.

Ә иң мөһиме — сәүдәгәрләр монголларга карата дошманлык хисләрен тоймаган, аларны химаяче [25], сәүдәнең иминлеген саклаучы идарәчеләр итеп күргән. Шуңа күрә Монгол империясенең башлангыч этабында түрәләр роленә нәкъ менә сәүдәгәрләр иң кулай кандидат булып саналган.

Сәүдәгәрләр актив җәлеп ителгән вазифаларның берсе булып дипломат эше исәпләнгән. Иң билгеле мисаллардан — Чыңгыз ханның илчесе сыйфатында хәрәзмшаһ Мөхәммәд II янына җибәрелгән сәүдәгәр Мәхмүд Йалавач һәм Хубилай ханда дипломат буларак хезмәт иткән Поло гаиләсе. Әлеге исемлеккә гарәп тарихчылары искә алган «алан сәүдәгәрләреннән вәкаләтле вәкил»не дә кертеп була. Билгеле булганча, ул 1260 нчы еллар башында Алтын Урда ханы Бәркә һәм Мисыр солтаны Бәйбарс арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруга зур өлеш кертә [26].

XIV гасырда Чыңгызыйлар идарә иткән дәүләтләрдә түрәләр династияләре формалаша башлый. Алар арасында нәселле дипломатлар булу сәбәпле, сәүдәгәр-дипломатларның роле икенче планга күчә, әмма бөтенләй юкка чыкмый. Сәүдәгәрләр дустанә мөнәсәбәтләрдә торган дәүләтләргә юл тоткан илчеләрне озатып бару вазифасын башкаруны дәвам итәләр. Илчеләрнең кирәк-яракларга тотылган чыгымнарын киметү максатыннан, дипломатик йөкләмәләр, рәсми шәхесләрдән кала, читтән килгән сәүдәгәрләргә дә бирелгән. Мисалга Алтын Урда сәүдәгәре Мозаффарны китерергә мөмкин. 1337 елның 2 октябрендә ул, югары әмирләрнең кушуы буенча, Мисыр солтаны әл-мәлик-ән-Насыйрның сарай даирәсенә дипломатик вазифа белән бара [27].

Дәүләт тарафыннан сәүдәгәрләргә йөкләнгән тагын бер функция — салым җыю. Монгол империясендә, шул исәптән Алтын Урдада да салым җыю хокукын ирекле кешегә тапшыру (откуп) практикасы киң кулланылган. Аерым өлкәләрдә салым җыярга теләгән сәүдәгәр казнага алдан билгеләнгән күләмдә акча кертергә тиеш булган. Шул акчаны керткәч, аңа үзе сайлаган төбәктән салым җыярга рөхсәт бирелгән.

Дәүләт системасы формалашкач, салым җыю эше аерым түрәләргә — баскакларга тапшырылган. Әмма еш кына баскаклар вазифасын аерым сәүдәгәрләр (гадәттә «уртак»лар) я сәүдәгәр ширкәтләренең башлыклары үтәгән. Үз кулына аерым территорияләрдән салым җыюны алган сәүдәгәргә мисал итеп Үгәдәй ханның һәм Туракин хатынның «уртагын», Елюй Чуцайның төп сәяси көндәше хәрәзмле Габдрахманны китерергә мөмкин. 1240 елда ул кайбер Кытай өлкәләреннән салым җыю мөмкинлеген ала, ә 1242 елдан Төньяк Кытайның наместнигы була [28].

25. Allsen T.T. Mongolian Princes and Their Merchant Partners 1200-1260 // Asia Major. — Princeton, NJ: Princeton University Press, 1989. — P.116.

26. Закиров С. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом (XIII-XIV вв). — Москва: «Наука», 1966. — С.42-43.

27. Селезнёв Ю.В. Элита Золотой Орды. — Казань: Издательство «Фэн» АН РТ, 2009. — С.133.

28. Почекаев Р.Ю. Аннотированный список имён // Султанов Т.И. Чингиз-хан и Чингизиды. Судьба и власть. — М.: АСТ, 2006. — С.373.

Мәгълүм ки, әлеге система Алтын Урдада да булган. XIII гасырның 50 нче еллар ахыры — 60 нчы еллар башында төньяк-көнчыгышта урнашкан рус кенәзлекләреннән салымны монгол каханы Мункәдән бу хокукны сатып алган мөселман сәүдәгәрләре җыя башлый.

Әлеге система сәүдәгәрләргә салымны нормадан арттырып җыю мөмкинлеге бирә, шул рәвешле үзләренең кереме дә арта. Билгеле бер этапта салым җыюдан алынган керем сәүдә эшләреннән килгән табыштан күпкә артып китә. Ләкин Алтын Урдада әлеге система озак сакланмый. Тәхеткә Бәркә хан килү белән, откуп системасы гамәлдән чыгарыла. Монгол империясенең башка өлкәләрендә, мәсәлән, Кытайда һәм Үзәк Азиядә откупщиклар XIV гасырга кадәр гамәлдә була [29].

Еш кына Алтын Урда сәүдәгәрләре Урда элитасы вәкилләренең һәм идарә иткән вассал дәүләтләрнең кредиторлары да булган. Алар үзләренең күптөрле ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, акча биреп торып, керем буларак, процент алган. Әйтик, Алтын Урда сәүдәгәре Рәҗәп хуҗа һәм Хәбиб кенәзнең Юрий Галицкийның кредиторлары булганлыгы билгеле [30].

Күп кенә рус, аеруча Тверь һәм Мәскәү шәһәре кенәзләре, Алтын Урда сәүдәгәрләреннән бурычка акча алып торган [31]. Әлеге акча еш кына ханга, аның гаиләсенә бүләк ясау һәм абруйлы зур түрәләргә ришвәт бирү максатыннан кулланылган. Кайчагында әлеге сумма теге яки бу кенәз түләгән салым күләменнән дә зуррак булган [32]. Тверь шәһәре елъязмачысы 1321 елда: «Въ лето 6829. По весне прізнль въ Кашинъ Гачна Татаринъ съ Жидовиномъ дзьжвикомъ, много тягости учинилъ Кашину», — дип язып калдырган [33]. Бу шәһәрнең кенәзе Михаил Ярославич һәм аның улы Константин Алтын Урдада вакытта җирле сәүдәгәрләрдән бурычка зур күләмдә акча алып тора. Әлеге сумма шулкадәр зур булган ки, бурычны кире кайтару өчен, кенәз варислары әһәмияте ягыннан кенәзлектә икенче урында торган Кашин шәһәрен бирергә мәҗбүр булалар.

Әйтелгәннән чыгып, түбәндәге нәтиҗәгә килеп була: Чыңгыз хан чорыннан башлап сәүдәгәрләр төрки-монгол ханлыкларының сәяси тормышында мөһим роль уйнаган. Чыңгыз хан варислары — Алтын Урда ханнары сәүдә эшләрендә аның сәясәтен дәвам иткән: сәүдәгәрләрне ил эчендә һәм халыкара мәйданда яклаганнар. Бу гаҗәп хәл саналмаган. Чөнки Алтын Урда сәүдәгәрләре ханнарга төрле яктан хезмәттәшлек күрсәткән. Алар сәүдә вәкиле, түрә, дипломат, информатор һәм шпион буларак актив эшләгән. Сәүдәгәрләр хан сараенда зур дәрәҗә тоткан һәм дәүләт сәясәтенә турыдан-туры йогынты ясаган.

«Уртаклык»ларга килгәндә, чыганаклардан күренгәнчә, Монгол империясе дәверендә алар сәүдәгәрләрнең мәнфәгатен яклаучы профессиональ берләшмәгә әйләнә. Кайберләренә югары даирәдә шактый зур ярдәм күрсәтелә, шуңа күрә алар Алтын Урда җәмгыятендә дәрәҗәле статуска ия булалар. ■

29. Почекаев Р.Ю. Право Золотой Орды. — Казань: Издательство «Фэн» АН РТ, 2009. — С.164.

30. Селезнёв Ю.В. Элита Золотой Орды. — Казань: Издательство «Фэн» АН РТ, 2009. — С.25, 152.

31. Полубояринова М.Д. Русские люди в Золотой Орде. — М.: Издательство «Наука», 1978. — С.15-16.

32. Греков Б.Д. Золотая Орда и её падение. — М.-Л.: Издательство АН СССР, 1950. — С.226.

33. Рогожский летописец. Тверской сборник. (Полное собрание русских летописей. — Т.XV.). — М.: Языки русской культуры, 2000. — С.414.

XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТӨРЕК-ТАТАР БАГЛАНЫШЛАРЫ*

ИСМӘГЫЙЛЬ ТӨРКУГЛЫ,
Мәрмәрә университетының Тюркология институты докторы

ТАТАРЛАР ТАРАФЫННАН ИСТАНБУЛДА ЧЫГАРЫЛГАН ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР

1905-1908 еллар арасында Госманлы дәүләтендәге кардәшләренә караганда тагын да ирекләрәк матбугатка ия булган татарларның чыгарган газета-журналлары Истанбулда да тарала иде. Бу чорда чыккан татар матбугаты арасында Госманлы дәүләтенә каршы тегеяки бу исемдәге газета-журнал очрату мөмкин булмаса да, солтан Габделхәмит II чорында Петербургтагы Госманлы илчелеге, кайбер татар газеталарының эшчәнлеген туктату өчен, Россия тышкы эшләр министры граф Ламсдорф аркылы җитди гамәлләр кыла [1]. Мәсәлән, Петербургта Габдерәшит Ибраһим тарафыннан чыгарыла торган «Өлфәт» газетасының нәшерен туктату максаты белән, Госманлы дәүләтенең Петербургтагы илчесе Россия тышкы эшләр министры граф Ламсдорфка мөрәҗәгать итә. Ләкин бу газетаны рус кануннары нигезендә туктату мөмкин түгел, дигән җавап ала [2]. Янә Габдерәшит Ибраһим чыгара торган «Миръат» («Көзге») журналының, Гатаулла Баязитов тарафыннан нәшер ителгән «Нур», Һади Максуди мөхәррирлегендә дөнья күргән «Йолдыз» газеталарының Госманлы туфракларына керүе тыелганлыгын күрсәтә торган документлар бар [3]. Архивта Исмәгыйль Гаспралы «Тәрҗеман»-ының да тыелганлыгын исбатлаган

*Дәвамы. Башы журналның 1, 2 нче саннарында

күпсанлы документлар саклана [4]. Ләкин газета даими рәвештә тыелмый. Югарыда телгә алынган газеталарны яхшылап тикшерсәк, аларны Госманлы дәүләтенә каршы нинди дә булса сәясәт алып барганнардыр дип әйтеп булмый. Бары тик «Өлфәт» газетасында гына Госманлы матбугатының Россия мөселманнарына игътибарсыз булуы тәнкыйтьләнә. Әмма бу газета-журналлар рус һәм көнбатыш матбугатында пантюркизм [5] һәм панисламизм [6] басмалары буларак күрсәтелә. Габделхәмит II дә шул ук матбугатлар тарафыннан панисламист буларак танытыла. Шулай да әлеге газета-журналларның Госманлы туфракларына үтеп керүе нигә тыелган соң? Бу сорауга анык җавап бирү авыр, фәкать шуны гына әйтергә була: солтан Гәбделхәмит II үз карамагында булмаган матбугатка салкын караган һәм Россия мөселманнары чыгарган газета-журналларның «Яшь төрекләр» тарафыннан үзләштерелү ихтималына каршы саклык чарасы күргән.

Муса Акъегетзадә тарафыннан нәшер ителгән **«Мәтин»** газетасын татарларның Истанбулда чыгарган беренче матбугаты дияргә мөмкин. Муса Акъегетзадә II мәшрүтият игълан ителер алдыннан (20 июль, 1908 ел) Эчке эшләр министрлыгына гариза язып, «Җиһан» исемле сәяси һәм гыйльми бер газета чыгару турында рөхсәт сорый. Рөхсәт бирелүенә карамастан, нигәдер бу газетаны чыгармый [7]. Акъегетзадә, II мәшрүтият игълан ителеп, берничә көн узуга, «Мәтин» исемле гыйльми, икътисади, әдәби һәм хәрби газета чыгарырга тотына. Газетаны гамәлгә куючылар арасында хатыны Хәйрия ханым һәм Хәлил әфәнде исемле шәхесләр бар. Аныңча, Ватан авыр хасталык кичерә, әгәр мәшрүтият игълан ителмәгән булса, илнең кайбер актык кыйммәтләре кулдан китәчәк. Ә мәшрүтиятнең игълан ителүе әлеге кыйммәтләрнең югалуына киртә булып тора. М.Акъегетзадә «Мәтин»дәге мәкаләләрендә II мәшрүтиятнең игълан ителүен «Яшәсен гаделлек, яшәсен хөрлек, яшәсен мәшрүтият» шигаре белән бик сөенеп каршылый һәм «чирле ватан»ның әкренләп аякка басачагына өмет баглый [8]. М.Акъегетзадәнең мәкаләләрендә нигездә мәшрүтият, ил алдында ватандашларының бурычлары, гаскәрилек темалары яктыртыла. Бу газета ябылгач, «Өч газета» исемле тагын бер матбугат нәшер итә [9]. Мәһмәд Рәшат җитәкчелегендәге әлеге газета «Мәтин», «Фәйз-и Хөррият» һәм «Тасвир-и Хыял» дип аталган басмаларның берләшүеннән барлыкка килә. «Мәтин» газетасында Акъегетзадәнең мәкаләләре аз чыга. «Өч газета»ның «нәширләре» бүлегендә Муса, Виждани һәм Яни исемнәре тора. Акъегетзадә тарафыннан чыгарылган бу газеталар озын гомерле булмый. Алар Акъегетзадә губернаторның җирле җитәкчесе буларак Анадулыга җибәрелгәч, ябылып бетә.

Әлеге газеталар, татарлар турында бернинди мәкалә язмасалар да, мөһаҗирлектәге беренче татар матбугаты буларак, гаятъ зур тарихи әһәмияткә ия.

Оренбурглы татар байларыннан булган мәшһүр Мәхмүт бай Хөсәеновнең Истанбулдагы татар шәкертләре өчен тулай торак төзү максатыннан биргән ун мең алтыны тагын да файдалырак эш өчен кулланыла — бу акча белән йөз ел буе өзлексез чыгып килә торган **«Төрек йорты»** журналына нигез салына. Йосыф Акчура Мәхмүт байны ничек ризалаштыргандыр, анысы безгә мәгълүм түгел, ләкин оренбурглы бай татарларның вакытлы матбугатка зур игътибар бирүе билгеле. «Шура»га охшаш бер журналның Истанбулда чыгарылуы төрек-татар мәдәниятенең үсешенә зур файда китерә. 1917 елга

متین

Муса Акъегетзадәнең Истанбулда чыгарылган «Мәтин» газетасы

кадәр Йосыф Акчура җитәкчелегендә чыккан «Төрек йорты» чын мәгънәсендә бар төрки дөнья журналы була. Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Галимҗан Идриси, Исмәгыйль Гаспралы, Хәлим Сабит, Муса Ярулла Биги, Ризаэддин Фәхреддин, Фатих Кәрими һәм тагын бик күп татар зыялылары бу журналда төрле мәкаләләрен бастыра. 1917 елга чаклы журналның һәр санында диярлек Россия татарлары турында язмалар басыла, төньяк һәм көньяк төрекләре, ягъни татарлар һәм төрекләр бер-берсенә танытыла.

1910 елда Ерак Көнчыгышка сәяхәтен тәмамлап, Истанбулга әйләнеп кайткан Габдерәшит Ибраһим троицкилы Әхмәт Таҗетдин белән бергә **«Мөселманнарның танышуы»** исемле журнал чыгара башлый. Журналда дини, сәяси, тарихи һәм фәлсәфи темалар белән бергә Россия мөселманнарының тормышы да яктыртыла. Атна саен чыккан бу журналның утыз ике саны дөнья күрә. 1911 елның 2 мартыннан Габдерәшит Ибраһим Истанбулда **«Ислам дөньясы»** дип аталган тагын бер журнал чыгара. Бу журналның нибары 26 саны укучы кулына барып ирешә. Анда, нигездә, ислам дөньясы, Россия мөселманнары һәм Балкан сугышлары белән бәйле мәкаләләр урын ала. Журналның мөхәррире Госман Җуди була. «Ислам дөньясы»ның 10 нчы санында Муса Ярулла Бигинең «Хәсрәтләнгән идем, инде аңладым» дигән мәкаләсе басылгач, «шәйхелисламлык» әлеге матбугатны мәхкәмәгә бирә. Суд баш мөхәррирга төрмә һәм акча түләү җәзасы карарын чыгара. Нәтиҗәдә, болай да авырлык белән нәшер ителгән журнал чыгудан туктый.

Татарлар чыгарган тагын бер журнал **«Ислам мәҗмугасы»** дип атала. 1914 елның 12 феврале — 1918 елның 30 октябре арасында җәмгысы 63 саны дөнья күргән бу мәгълүмат чарасының мөдире Хәлим Сабит була. Журналда татарларның сәүдә тармагындагы уңышлары кыска язмалар рәвешендә Госманлы төрекләренә аңлатыла һәм аларга да төньяктагы төрек кардәшләреннән *(татарлардан — ред.)* үрнәк алырга кирәклеге ассызыклана. Хәлим Сабит, Габдерәшит Ибраһим, Ризаэддин Фәхреддин, Сәрвәретдин Мифтахетдин, Галимҗан Идриси, Фәүзия Ибраһим журналның танылган язучылары була. Шулай ук Россиядәге төрле татар газеталарыннан Фатих Әмирхан, Фуат Туктар һәм Муса Ярулла Бигинең кайбер мәкаләләре дә үзгәртелмичә басыла.

Габдерәшит Ибраһимның кызы Фәүзия Ибраһим тарафыннан, 1925 елның 26 гыйнварыннан башлап Истанбулда нәшер ителгән **«Асар-ы Нисван»** журналы Төркия Җөмһүрияте чорының тәүге хатын-кызлар журналларыннан берсе була. Яңа оешкан Төркия Җөмһүриятендә хатын-

اسلام دنیاسی

اعترافی لازم اولان

آجی حقیقتلر

قریم تاریخی

عالم اسلام

Габдерәшит Ибраһим тарафыннан Истанбулда чыгарылган «Ислам дөньясы» журналы

кызларның социаль һәм икътисади тормышта ирләр белән тигез булырга тиешлеген шигарь иткән әлеге басма белем алу, гаилә тормышы, бала карау, чисталык, чигү-тегү кебек төрле темалар буенча юл күрсәтергә тырыша. 1926 елның сентябрендә журналның исеме «Хатын-кыз язмалары» дип үзгәртелә. Ләкин 28 нче саны дөнья күргәннән соң, матди кыенлыклар аркасында журнал чыгудан туктый. Журналга язучылар арасында Фәүзиянең бертуган сеңелесе Кадрия Ибраһим да була.

ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕ ТАРАФЫННАН ТӨРЛЕ ОРДЕН ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘР БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНГӘН ТАТАРЛАР

Госманлы Дәүләте кайбер татарларны орден һәм медальләр белән дә бүләкләгән. Аларны нинди сәбәпләр нигезендә биргәнлеге турында архив документлары арасында әллә ни мәгълүмат юк. Бары тик Гатаулла Баязитов һәм Хәсәнгата Габәшигә бирелгән орден һәм медальләрнең сәбәбе билгеле. Гатаулла Баязидовка француз язучысы Эрнест Ренанга кайбер фикерләрен кире кагып язу җибәргәне өчен өченче дәрәҗәле «Мәҗидия» ордены бирелсә, Хәсәнгата Габәши «Төрки кавемнәрнең тарихы» исемле әсәре өчен орден һәм агат тәсбих белән бүләкләнә. Оренбург мәхкәмәи шәргыя мөфтие Мөхәммәдьяр Солтановка — икенче, янында эшләүче имам Фәйзерәхим Даутовка — дүртенче дәрәҗәле Госманлы ордены, Галимҗан Барудига икенче дәрәҗә «Мәҗидия» ордены Истанбулга сәфәрләре өчен бирелгәндер дип фараз кылырга җирлек бар. Галимҗан Барудиның хатынына да икенче дәрәҗә «Шәфкать» ордены

бирелгән. Казан галимнәреннән булган Нургали әфәнде исемле кешенең беренче дәрәҗә Госманлы орденына, казанлы Насреддин әфәнденең хатыны Нусникамалның сәнәгать медаленә ни өчен лаек булулары мәгълүм түгел.

ТӨРЕК ЗЫЯЛЫЛАРЫНЫҢ ТАТАРЛАР БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЛАРЫ

Күп кенә татар зыялыларының юлы Истанбул аша узса да, госманлыларның Идел-Урал төбәгенә битараф булулары сизелә. 1905 елдан соң дөнья күрә башлаган татар вакытлы матбугатында да Төркия әдипләре һәм галимнәренең Россиягә килмәүләре, татарларның әдәби, икътисади, фәнни һәм иҗтимагый яшәешләре белән кызыксынмаулары тәнкыйтьләнгән [10]. Хәтта Госманлы матбугатының шималь төрекләренә *(текстта «шималь төркиләре» — төньяк төркиләре, ягъни татарлар мәгънәсендә. — Ред.)* ике тиенлек тә игътибар күрсәтмәүләре һәм Истанбулга барган татар галимнәренә бохаралы иске муллаларга күрсәтелгән игътибар кадәр дә кызыксыну булмаганлыгы турында язылган [11].

Мәгълүм булганча, Госманлы зыялыларыннан Идел-Урал төбәгенә бары тик алты кеше генә сәфәр кыла. Алар — Сөләйман Ками, Сөләйман Карчынҗызадә, Җәләл Нури Иләри, «Садр-ы Сабык» һәм «Аян» мәҗлесе әгъзасы, генерал Хөсәен Хилми паша [12], Милек актлары һәм җир кадастры министры Мәхмүт Әсад әфәнде [13], «Икъдам» газетасының нәшире Әхмәт Җәүдәт.

Сөләйман Ками Россиягә 1887 елның 31 маенда башлаган сәфәре вакытында Казан, Пермь кебек татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрдә була, ләкин юлъязмаларында татарлар турында әллә ни мәгълүмат бирми. Ул Казанда уздырган бер көнендә шәһәрнең әһәмиятле урыннарын, музейларын карап йөри. Татар мәхәлләсендәге мәчетләрне һәм үзе белән бер телдә сөйләшүче татарларны мактап телгә ала [14].

Сөләйман Карчынҗызадәнең Урта Азия, Төркестан, Европа һәм Россиягә сәяхәтнамәсе «Олуг сәяхәт» исеме белән 1907 елда Петербургта Габдерәшит Ибраһим типографиясендә басыла. Сөләйман Карчынҗызадә бу сәфәре кысаларында Уфа, Самара, Пенза, Рязань кебек шәһәрләр һәм анда гомер итүче мөселманнар турында да мәгълүмат бирә.

1912 елда Россия, Финляндия, Швеция, Норвегия һәм Дания кебек илләргә сәяхәт кылган журналист һәм фикер иясе **Җәләл Нури Иләри** истәлекләрен Истанбул каласында «Төньяк хатирәләре» исемле китапта бастыра. Ул әсәрендә XX гасыр башында татарларның алгарышы турында мактап яза һәм кызыклы гына мәгълүматлар китерә. Аныңча, төрекләр — гомуми бер үзенчәлеккә ия милләт булып, татарлар аларның бер өлеше.

«Бу нисбәттән һәр татар — төрек, һәр төрек татар түгелдер. Ун-унбиш ел элек мәгарифтә, иҗтимагый фикердә Идел буенда бернәрсә дә юк иде, хәзер исә Ш.Мәрҗани мәрхүмнең тырышлыгы белән язма тел, әдәбият, шагыйрьләр, бик мөһим нәшриятлар, күпсанлы газета-журналлар бар. Хакимият кулларында булмагач, бу шималь төрекләре көчләрен сәүдәгә, сәнгатькә биргәннәр. **Хөкүмәт татар мөселман мәгарифенең үсеше өчен бер тиен бирмәсә дә, татарлар һәр җирдә мәчет-мәдрәсә тоталар һәм анда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын үз кесәләреннән түлиләр. Имамнарның күпчелеген иганә җыючы адәмнәр тәшкил итә. Татар имамнарының бурычлары — бездәге кебек эндәшми калудан гыйбарәт булмыйча, җәмәгатьчелеккә, ислам җәмгыятенә җитәкчелек итү.** Аларның ролен бездәге грек митрополиты роленә охшату хата

Идел-Уралга сәяхәт кылган госманлы Мәхмүт Әсад әфәнде

Идел-Уралга сәяхәт кылган госманлы Хөсәен Хилми паша

булмас кебек. Россия хөкүмәтенең бу имамнар арасында фетнә орлыклары чәчүче һәм бер-берсен әләкләүче агент итәргә тырышканлыгы турында да сөйләнә. Мәсәлән, Россиядәге ислам галимнәренең башында торучы, гыйлеме белән мәшһүр мулла Галимҗан Баруди хәзрәтләре мондый фетнә һәм хәйләкәрлеккә корбан булып, бервакыт көрәк җәзасына хөкем ителгән иде.

Имамнар җомга намазыннан соң мөнбәрдән татар телендә җирлек һәм заманга туры килерлек вәгазьләр белән чыгалар. Кызганыч ки, хәлифәгә мәдхия укымыйлар. Гыйбадәт ахырында имам әфәнде: «Сөекле падишаһыбыз император хәзрәтләренә бер дога!» — дип, кулларын югары күтәрә.

Татар авыллары, рус авылларына караганда, чагыштырмача җанлырак. Рус авылларында искелек һәм наданлык дәвам итә. Мөселман авылларында исә бер уяныш сизелә һәм халык арасында фикер хөрлеге башлана. Шималь төрекләренең уңганлыкларына ышанганлыгымнан, бер гасырдан соң аларның Россия күләмендә бик зур баскычта урын тотачакларын хәзердән үк әйтә алам.

Идел буена сәяхәтемдә бу талантлы милләтнең башкарган эшләрен үз күзләрем белән күрдем. Хатын-кызлары ябулы булса да, татар дөньясы гыйффәт һәм намуслылык ягыннан мактауга лаек. Күңел ачу мәсьәләсендә Россия һәр җирдә көндәш була алырлык булса да, татарлар мондый мохитнең читендә кала. Шәһәрләрдә мөселман хатын-кызлары арасында укый-яза белмәүчеләр юк дәрәҗәсендә.

Тышкы яктан татарлар консерватив. Каралты-куралары тәртип белән заманча төзелсә дә, кием-салымнары бик иске кебек күренә. Россиянең иң зур шәһәрләрендә, иң мәшһүр кунакханәләрендә, казино-

Сулдан уңга: Г.Исхакый, З.Шамил, М.Бигиев

ларында официантлык бу милләтнең монополиясендә булганлыктан, аларда заманча униформа кигән, мыеклары киселгән, европалылардан, америкалылардан берничек тә аерылып тормаган татарларны да күрергә мөмкин.

Шималь төрекләренең матди халәте безнең төрекләрнекеннән өстен. Аларда табиб, адвокат кебек белгечләр безнекеннән күп. Шималь төрекчәсе (*татар теле – ред.*) безнең төрекчәгә караганда катырак. Бу тупас тел белән хат язу файдалырак, чөнки халык госманлы телен бик авыр аңлый. Безнең төрекчәбез өйрәтелергә теләнсә дә, аннан баш тарту ихтималлары бик көчле. Моның белән бергә татарча тагын бик күп сүзләргә, китапка, фикергә, теләк-хисләргә ихтыяҗ тойганлыктан, һәр ике төрекчәнең әдәби теле бер көн тулысынча берләшеп бетмәсә дә, бик якынлашачак. Шималь төрекләре госманлы төрекләренең нәзакәтлелегенә, китапларына, бәян итү ысулларына, әдәби һәм гыйльми әсәрләренә мохтаҗ.

Россия хөкүмәте мөселманнарның кәсепләрен һәм табышларын тартып алмый, әмма мәгарифләренең киң массага таралуына, җәелүенә бик тискәре карый. Хөкүмәт мөселманнар хәрәкәтен сүндерергә һәвәслек күрсәтә.

Татарлар русларның сәясәтенә башка милләтләргә караганда ныграк каршы килә. Араларында диннәрен алмаштыручылар юк дәрәҗәсендә. Россия татарларны бәлки руслаштыра да алыр иде, фәкать мөселманнарның ныклыгы сәбәпле, аларны рус идарәсенә кертү мөмкин түгел. Татарларның ихтыярлары нык, чыдам.

Руслар татар илен яу белән басып алды, хәзер анда хакимлек итәләр. Ләкин татарлар милли үзенчәлекләрен

саклап калдылар, саклый һәм саклаячаклар» [15].

Хөсәен Хилми паша 1910 елның 12 гыйнварында тәмамланган садрәгъзәмлык [16] вазифасыннан соң, якынча 8 ай дәвам иткән Европа сәяхәтенә чыга. Бу сәяхәте кысаларында Франция, Англия, Германия, Россия, Австрия һәм Италия кебек төрле илләрне гизә. Паша, гайре рәсми зат буларак, үз теләге белән Европа һәм Россия сәяхәтенә чыгучы беренче Госманлы дәүләт эшлеклесе санала. Аның 1910 елның 25 мартында Петербургтан башланган Россиядәге сәяхәтенең бернинди рәсми максаты булмаса да, дәүләт тарафыннан игътибар күрсәтелә. Хилми паша сәфәре вакытында Петербург, Мәскәү, Казан һәм Самара кебек шәһәрләрдә гомер сөрүче татарлар белән күрешә, анда аңа зур игътибар күрсәтелә. 1910 елның 15 апрелендә Казанга бара. Казанда аны губернатор урынбасары Георгий Болеславович Петкевич, жандармерия идарәсе башлыгы Константин Иванович Калинин, Казан шәһәре хакимияте җитәкчесе Сергей Андреевич Бекетов, полиция идарәсе мөдире Алексей Иванович Васильев, Казан матбугат бүлегеннән Николай Иванович Ашмарин, Казан университеты профессоры Николай Фёдорович Катанов каршылыйлар. Пашаны каршыларга килүчеләрдән мөселманнар булмый, чөнки аның Казанга килүенең төгәл датасы турында хәбәр ителми. Полиция идарәсе мөдире А.И.Васильев, Н.И.Ашмарин һәм Н.Ф.Катанов Хилми пашаны Казанда үткәргән өч көне дәвамында бер минутка да ялгыз калдырмыйлар. Казан губернаторы Михаил Васильевич Стрижевский 16-17 апрель көннәрендә Хилми пашаның Казандагы бөтен очрашулары вакытында янында була [17].

Хилми паша кунакханәдәге бүлмәсенә урнашкач, Н.Ф.Катанов белән Н.И.Ашмарин аннан Казанның кайсы урыннарын гизәргә, нәрсәләр күрергә теләгәнен сорыйлар. Паша завод-фабрикаларны, Благовещенский чиркәвен, Сөембикә манарасын, музейларны, татар мәхәлләсе һәм мәчетләрен күрергә теләвен белдерә. Фикер алышканнан соң, 15 апрельдә шәһәр үзәгендәге урыннарны, 16-17 апрель көннәрендә завод-фабрикаларны, шәһәрдәге татар мәхәлләләрен, мәдрәсә һәм мәчетләрне карап йөрергә килешәләр. Полиция идарәсе начальнигына план аңлатылып, кирәкле чараларның алдан хәстәрен күрүе боерыла. Н.Ф.Катанов Хилми пашага Казан каласының тарихын һәм кызыклы урыннарын тасвирлаган дүрт китап бүләк итә [18].

Паша шәһәр белән танышуын Казан университеты китапханәсеннән башлый. Бу бай китапханә аның игътибарын яулый. Андагы мөселман кабере ташын *(хәзерге вакытта бу таш Н.Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең диварына беркетелгән һәм «Казан: үткәне һәм бүгенгесе» дип аталган стенд артында саклана. — Ред.)* һәм 50 кисәк тирегә иврит телендә язылган, цилиндр рәвешендәге «Тәүрат»ны җентекләп карый. Китапханәдән университет музеена үтәләр. Анда пашаны уку йортының ректоры һәм урынбасарлары каршылый. Паша борынгы рус һәм Сасанид акчаларын якыннан тикшерә. «Фикер белдерүләр дәфтәрен»нә, университетта булуыннан канәгать калганын белдереп, берничә җөмлә яза. Фәкать университетта укучы мөселман шәкертләренең азлыгы пашаны бик гаҗәпләндерә, рус мәктәпләре һәм университет ишекләренең мөселманнар өчен дә ачык булуына карамастан, бу мөмкинлектән файдаланмауларына борчылуын белдерә.

Шәһәр музее, Благовещенский чиркәве һәм Сөембикә манарасында булганнан соң, губернаторның өендә каһвә эчеп, кунакханәгә кайталар. Паша кунакханәдә үзен күпсанлы

мөселманнарның күтеп торуын күрә. Алар арасында Юнысовлар гаиләсе тарафыннан төзелгән ятим балалар йорты мөдире Рәхим Юнысов, сәүдәгәрләр Бәдретдин Апанай һәм сәүдәгәр Исмәгыйль Үтәмеш, «Йолдыз» газетасының баш мөхәррире Һади Максуди була. Алар 16 апрель кичендә Сәүдәгәрләр клубына пашаны ашка чакырырга теләгәнлекләрен бәян итә, паша бу тәкъдимне кабул итеп, рәхмәт белдерә. Бәдретдин Апанай паша хөрмәтенә 15 апрельдә зур табын җыярга теләсә дә, паша бу тәкъдимне, сәфәренең рәсми булмаганлыгын белдереп, кире кага. Шулай да Бәдретдин Апанай пашаны 16 апрель көнне сәгать икедә өйлә ашына чакыра, паша тәкъдимне кабул итә. Һади Максуди пашага үз нәширлегендә басылган 20ләп китап бүләк итә. Паша, әсәрләрне җентекләп тикшереп, кайбер грамматик хаталарны төзәтә һәм Максудине язган әсәрләре өчен тәбрик итә. Төрек һәм татар телләрендәге якынлык турында фикерләрен белдерә. Әңгәмә соңрак җәдитчелек белән кадимчелек арасындагы көрәш мәсьәләсенә борыла. Паша бу төр проблемаларның Төркиядә дә дәвам иткәнлеген, вакытлар узу белән, кадимчеләрнең әлеге көрәштән баш тартачаклары турындагы фикерне әйтә.

16 апрельдә Хилми паша губернатор М.В.Стрижевский, полиция идарәсе мөдире А.И.Васильев, Н.И.Ашмарин, ахун Шәрәфетдин Абызов, Н.Ф.Катанов, Һади Максуди, Исмәгыйль Кәримов белән бергә мөселман мәхәлләләрендә йөрергә чыга. Әүвәл «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә булалар. Хилми паша башлангыч сыйныфларның беренчесеннән дүртенчесенә чаклы, урта сыйныфларда — дүртесен, югары сыйныфларның икесен — җәмгысе 10 сыйныфны карап чыга. Һәр сыйныфта укучыларны сынап карый, җавапларыннан канәгать кала, гыйлем алу һәм фәндә югары дәрәҗәгә ирешү турында кыска нотык сөйли. Губернатор, полиция идарәсе начальнигы, Н.Ф.Катанов һәм Н.И.Ашмарин да паша белән бергә бөтен сыйныфлар белән таныша. Биредә кадим-җәдит мәсьәләсе дә телгә алына. Һади Максуди бу нисбәттән кадимчеләрнең хөкүмәткә шикаять белдергәнлеген әйтеп уза. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең оештыручысы һәм хуҗасы Галимҗан Баруди бу вакытта мәдрәсәдә булмый. Полиция начальнигы Г.Барудины чакыртып китерә һәм паша белән таныштыра [19]. Паша «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән зур канәгатьлек белән аерыла. Мәдрәсәдән соң «Борадарән Кәримовлар» матбагасына сәяхәт кыла. Матбагадагы хәрефләрне һәм басылып чыккан әсәрләрне карый. Шәһәрнең мөселманнар яши торган урамнары пашаны күреп калырга теләүче халык белән тула. Казанның мөселман мәхәлләләре беренче тапкыр бу чаклы күп халык җыелуга шаһит була.

Паша Әҗем мәчетенә дә керә. Мәчет пашаны күрергә теләгән халык белән тула. Аннан соң паша Арслановларның сабын заводына бара. Казан мөселманнарының иң иске фабрикасы — сәнәгать оешмасын игътибар белән тикшерә. Җомга вакыты якынлашканлыктан, паша, намаз уку өчен, Печән базары мәчетенә керә. Губернатор, полиция начальнигы, Н.Ф.Катанов һәм Н.И.Ашмарин мәчеттә үзләренә махсус аерылган бүлмәдә пашаның намаз укып бетергәнен көтәләр. Намаздан соң Бәдретдин Апанайның өенә өйлә ашына юнәләләр. Анда паша киләчәктә Россия-Госманлы дуслыгын үстерүгә тырышлык куячагын бәян итә. Тагын берничә завод-фабрикага кереп чykkаннан соң, Юнысовларның ятим балалар йортында булалар һәм Мөхәммәдрәхим Юнысовның өендә чәй эчәләр. Аннан губернатор сараена баралар. Кичке сәгать сигездә Сәүдәгәрләр клубында Казан мөселманнары тарафыннан паша хөрмәтенә оешты-

рылган ашка юнәләләр. Сый-хөрмәт мәҗлесе төнге сәгать унбергә чаклы дәвам итә. Икенче көнне паша һәм губернатор «Шәрык» клубына, бертуган Кәримовларның йортына, ахун Шәрәфетдин Абызовның өенә бара.

Пашаның Казанда үткәргән бу өч көнендә ул яшәгән кунакханә алды һәрвакыт халык белән тулы була. Алар пашаны кунакханәгә кергәндә яки чыкканда күреп калырга телиләр. 16 апрель кичендәге ашта телгә алынган иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе — Казан шәһәре хакимияте белән татарлар арасындагы якын мөнәсәбәтнең моннан соң да өзелмәү теләге чынга аша. Хилми паша рәсми очрашулардан тыш та бик күп кешенең өендәге чәй мәҗлесләрендә катнаша. Бәдретдин Апанай, бертуган Кәримовлар, Шәрәфетдин Абызов һәм тагын берничә кеше пашаны кунак итү бәхетенә ирешә. Очрашуларның барысында да губернатор белән Н.Ф.Катанов катнаша. Кунакханәгә килүчеләр арасында бер төркем яшь кызлар да була [20].

Паша 16 апрельдә, кичке аштан соң кунакханәсенә кайткач, Н.Ф.Катановтан кайбер мәсьәләләр буенча мәгълүмат алырга теләвен белдерә. Алар: 1) Татар телендә һәм аның диалектларында сөйләшүче Идел һәм Себер халыкларының саны, диннәре һәм яшәгән урыннары; 2) Казан университетындагы дүрт факультетның, бигрәк тә төрек-татар бүлегенең дәрес программасы; 3) Казан, Кырым һәм Алтын Урда ханнарының Чыңгыз хан белән булган нәсел чыбыклары; 4) Татар теле диалектларының охшашлыклары һәм аермалары. Н.Ф.Катанов пашаның бу теләкләрен икенче көнгә башкарырга тырышачагын вәгъдә итә. Паша үзенең Истанбулдагы сәркатибенең бик яхшы русча белгәнен, рус телендәге документларны төрекчәгә тәрҗемә иттерәчәген әйтә. 16 апрельдә иртәнге сәгать 9 тулып 30 минутта Н.Ф.Катанов һәм Н.И.Ашмарин кунакханәгә килә. Н.Ф.Катанов пашага «Чыңгыз хан һәм углы Җучинең шәҗәрәсе», «Борынгы һәм яңа татар сөйләмнәренең чагыштырмалы фонетик тезмәсе (кагыйдәләре)», «Идел буе болгарларының эпиграфик һәйкәлләре», «Казан университетының 1909-1910 елгы академик белешмәсе» кебек китапларны бүләк итә. Шулай ук, «Бәянелхак» газетасы мөхәррире Әхмәтҗан Сәйдәшев тә пашага Гайнетдин Әхмәровның «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» исемле әсәрләрен тапшыра.

Хилми пашаның Казанга килүе үзенә күрә бөек вакыйга була, халык атналар буе бу турыда сөйләшә [21]. Казан үз тарихында беренче тапкыр Госманлы пашасын кунак итә. Пашаны Казанда булган өч көне дәвамында даими рәвештә меңнәрчә татар күзәтеп тора. Бу Казанда гомер итүче татарлар һәм рус дәүләт җитәкчеләренең бер-берләре белән беренче мәртәбә очрашуында да сәбәп була. Аннан алда рус җитәкчеләре белән татарларның алдынгы затлары беркайчан да болай якыннан күрешмәгән була. Паша белән бергә губернаторның да ияреп йөрүе мөселманнарны бик канәгать калдыра. Сәяхәтнең җомга көнгә туры килүе һәм мөселманнар ул көнне эшләмәү сәбәпле, урамнарда ирләр һәм тәрәзәләрдән карап торучы хатыннар пашаны «мәрхәбә» дигән сүзләр белән сәламләп кала.

Паша 17 апрель көнне сәгать бердә Казаннан Самарага юл тота. Пашаны озатырга килүчеләр арасында губернатор, шәһәр башлыгы, жандармерия начальнигы, полиция идарәсе җитәкчесе, матбугат вәкилләре, шәһәр имамнары һәм каланың алдынгы затлары була.

Мәхмүт Әсад әфәнде 1913 елның 13 июлендә Истанбулдан кузгалып, Одесса, Киев, Акмәчет, Бакчасарай, Севастополь, Ялта, Новороссийск, Царицын, Самара, Оренбург, Уфа, Казан, Түбән Новгород, Мәскәү, Петербург

шәһәрләренә озын сәяхәтен тормышка ашыра. Финляндия, Швеция, Норвегия, Алмания илләреннән үтеп, кире Истанбулга кайта. Без Мәхмүт Әсад әфәнде сәяхәтенең бары тик Россия өлешен, бигрәк тә Идел-Урал татарлары турындагы хатирәләрен генә бәян итәчәкбез. Татар матбугатында урын алган хәбәр һәм мәкаләләр дә күбрәк шул хакта.

Мәхмүт Әсад әфәнденең Россиягә сәяхәт максаты — Россия һәм шималь төрекләре белән якыннан танышу. Ул Истанбулдагы татар дуслары Йосыф Акчура, Габдерәшит Ибраһим һәм Троицки каласыннан килгән Әхмәт Таҗетдиннән шималь төрекләре турында шактый мәгълүмат туплаган була. Россия мөселманнарының тормышын яктырткан «Мөселманнарны таныштыру» журналы редколлегиясе әгъзасы булу сәбәпле, шималь төрекләре аңа чит булмый. Икенче максаты — сәяхәт итүне бик өнәп бетермәгән Госманлы дәүләт эшлеклеләре һәм зыялыларына юл күрсәтү [22]. Мәхмүт Әсад әфәнденең бу сәяхәте жандармерия хисапларында да чагылыш тапкан, анда Мәхмүт Әсад әфәнденең Идел-Урал якларына килүенең төп сәбәбе — төрекләргә бу төбәккә сәяхәт итү юлын ачу, аларны бу җирлек белән таныштыру, анда гомер итүче мөселманнарның Төркия һәм төрек халыкларына симпатияләрен арттыру, кирәк булганда, мөселман кардәшләреннән иганә җыю. Ә яшьләр һәм эшкуарлар белән тыгыз элемтәдә булуы аларның милли рухын өйрәнү өчен, дип теркәлгән [23].

Мәхмүт Әсад Одесса, Киев, Акмәчет, Бакчасарай, Севастополь, Ялта, Новороссийск, Царицын һәм Самарада ике атналап сәяхәт иткәннән соң, 29 июль иртәсендә Оренбургка килеп төшә. Русча белмәгәнлектән, юлда шактый кыенлык кичерә, чөнки ул бары тик француз һәм инглиз телләрен генә белә. Россиядә бу телләрне белүчеләрнең саны шактый аз була. Мәхмүт Әсад әфәнде Оренбургта Фатих Кәрими белән бергә иң әүвәл «Хөсәения» мәдрәсәсенә керә. Мәдрәсә җитәкчеләре шул көнне җыелыш җыйган була. Шул нисбәтле Мәхмүт Әсад әфәнде күп татар зыялылары белән күрешү бәхетенә ирешә. Мәдрәсәдән соң «Шура» журналының мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин белән очраша. Ике галим процент, банк, риба, иминият оешмасы кебек шул чорда мөселманнар зиһенен мәшгуль иткән мәсьәләләр хакында сөйләшәләр. Мәхмүт Әсад әфәнде Ризаэддин Фәхреддингә түбәндәгеләрне бәян итә: «Сезнең диндәге җитешсезлекләр турында язганнарыгыз белән тулысынча килешәбез. Дин үзе җанлы булсын һәм аны тотучыларны рухландыру өчен, һәрвакыт акыл һәм фикер бергә булу кирәк. Диндәге реформаларга каршы килү — исламны һәм мөселманнарны юк итәргә теләү дигән сүз. Ләкин без әкрен-әкрен хәрәкәт итү тарафында. Халыкка кинәт кенә аңлату кыен, алар кайчак юк кына нәрсәләрдән дә өркеп кала, бөтен нәрсәне әкрен-әкрен тормышка ашыру яхшырак» [24].

Мәхмүт Әсад әфәнденең Оренбургта булган урыннарның берсе — кадимчеләрнең иң әһәмиятле матбугаты — «Дин вә мәгыйшәт» журналы була. Фатих Кәрими Мәхмүт Әсад әфәндене «Дин вә мәгыйшәт» редакциясенә алып баруының сәбәбен шулай ачыклый: «Шәригать телибез диючеләрнең саны Истанбулда да аз түгел, әмма бездәгеләрне дә күреп китсен, дидем». «Дин вә мәгыйшәт» журналының нәшире Мөхәммәдвәли әфәнде, Мәдинәдә белем алган һәм бераз Истанбулда яшәгәнлектән, бик яхшы төрекчә белгән. Бу җәһәттән ул Мәхмүт Әсад әфәнде белән төрекчә сөйләшә. «Дин вә мәгыйшәт» журналы Мәхмүд Әсад турында: «Җанаплары Төркиянең иң абруйлы һәм талантлы галимнәренең берсе булып, «Дәүләт

хокукы», «Ислам дине», «Ислам дине тарихы», «Ислам дине тарихы һәм икътисады» һәм «Күпхатынлылык» кебек әсәрләр авторы» [25], — дип язган була. Галимнең журнал сәхифәләрендә, Оренбургка килгәнче үк, «Күп хатынлылык» әсәреннән өзекләр бастырылган. Әмма Мәхмүт Әсад әфәнденең «Вакыт» газетасында Фатих Кәрими белән әңгәмәсе басылгач, «Дин вә мәгыйшәт» журналы аны динне бозуда гаепләп, ул чаклы ук бөек галим булмавын яза [26].

1913 елның 30 июлендә Оренбургтан киткән Мәхмүт Әсад әфәнде 31 июльнең иртәсендә Уфа вокзалында мөселманнар тарафыннан тантаналы рәвештә каршы алына. Арада мәшһүр тарихчы һәм казый Хәсәнгата Габәши, ахун Җиһангир Абызгилдин, Нәҗип Хәкимов, Хәсән Кәримов, Салих Хәбиров кебек Уфаның алдынгы карашлы шәхесләре була [27].

Мәхмүт Әсад әфәнде әүвәл казый Хәсәнгата Габәши белән бергә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының мөфтие Мөхәммәдьяр Солтановта була. Соңыннан беренче мәхәллә мәчетенә кереп чыгалар. Аннары губернатор белән очрашалар, Мәхмүт Әсад әфәнде белән бер сәгатьләп гәпләшкәннән соң, бергә шәһәр музеен карыйлар. Кич белән губернатор һәм полиция чиновниклары Мәхмүт Әсад әфәндене Казанга йөзә торган пароходка утыртып озатып калалар [28]. Мәхмүт Әсад әфәндегә Уфада иң нык тәэсир иткән әйбер — 20 ел элек шәһәрдә бер генә мөселман гыйбадәтханәсе булса, ул килгән чорда мәчет-мәдрәсәләрнең шактый күп булуы. Бу хәл — Уфа мөселманнарының үсештә булуын исбатлаучы иң зур дәлил. Мәхмүт Әсад әфәнде үзе танышып чыккан «Галия», «Госмания», «Хөсәения» мәдрәсәләренең дәрес программаларыннан да канәгать кала.

Мәхмүт Әсад әфәнде шималь төрекләренең мәдәни хәрәкәтенең чишмә башы итеп Казанны күрә. Чөнки сәяхәт итеп чыккан Самара, Оренбург, Уфа, Түбән Новгород, Мәскәү һәм Петербург шәһәрләрендәге сәүдәгәр һәм мөгаллимнәрнең Казан белән тыгыз элемтәсенә шаһит була. Казанда бер генә көн торуына карамастан, әһәмиятле тәэсирләр ала. Көне буе журналистлар белән бергә булганлыктан, бөтен фикерләре, әңгәмәләре матбугатта урын ала.

3 августта Казанга килеп җиткән Мәхмүт Әсад әфәндене полиция начальнигы урынбасары Зadановский, мөселманнардан Шәһәр Шәрәф, Мөхәммәтҗан Кәримов һәм Зәкәрия Садретдинов каршылый. Килгән көнне шәһәрнең төрле истәлекле урыннарын һәм газета редакцияләрен «Кояш» газетасының нәшире һәм мөхәррире Зәкәрия Садретдинов белән йөреп чыга. «Кояш» газетасының мөхәррире Фатих Әмирхан белән ике сәгатькә якын әңгәмә үткәрелә, анда ул төрек һәм ислам дөньясының проблемалары турында фикерләре белән уртаклаша. Мәхмүт Әсад әфәндене Россиягә сәяхәте вакытында аеруча рус халкының әдәпле мөгамәләсе, шималь төрекләренең алгарыш галәмәтләре һәм кунакчыллыгы тәэсирләндерә [29].

Мәхмүт Әсад әфәнденең Бакчасарай, Оренбург, Уфа, Казан кебек мөселман мәркәзләрендә йөрүе Россия мөселманнары өчен гаять зур вакыйга була. Россия мөселманнары аны һәр җирдә ифрат зур хөрмәт белән каршылыйлар. Гыйльми матбугат битләрендә еш искә алынган бу галимнең Петербургка килүен ишетеп алган «Мир Ислама» журналы редакциясе аның белән озын гына әңгәмә үткәрә. Истанбулга кайткач, үзе белән әңгәмә оештырган «Сабах» газетасы мөхәрриренә шималь төрекләренә сәяхәтеннән алган тәэсирләрен болай дип аңлата: «Бик яхшы, канәгать калдым, шималь төрекләренең алгарышын күреп сөендем [30]. Россиянең зур калаларындагы бөтен вокзалларда

диярлек буфет касыйм татарлары кулында, мин булган барлык шәһәрләрдә татар сәүдәгәрләре һәм кибетчеләре бик күп. Оренбург, Самара, Уфа һәм Казанда дин, икътисад, сәүдә тармакларында көчле үсештә булган куәтле ислам әһелләрен очраттым. **Казан һәм аның тирә-ягы Кытайга чаклы сузылган төбәкләрдәге бөтен ислам әһеленә мәгариф нуры чәчә.** Һәр җирдә Казаннан чыккан галим, мөгаллим һәм сәүдәгәр очрап тора. Бөтен җирдә халыкта алгарышка зур теләк һәм гаять җитди караш күзәтелә. **Казан һәм аның тирә-ягы — ислам дөньясының киң үсешкә ирешкән мәдәни мәркәзе.** Кызганыч ки, без моның әһәмиятен бүгенгә кадәр тиешенчә аңлый алмаганбыз. Шималь төрекләре сәүдә һәм сәнгатьтә көньяк төрекләренә караганда шактый алда тора. Бигрәк тә Казан мөселманнары! Безнең Истанбулда зур мөселман байларын һәм фабрикаларын очрату кыен, ә Казанда исә берничә миллионер бар!» [31].

Истанбулда чыга торган «Сабах» газетасы мөхәррирләренең берсе булган Бәдри Кәмал бәй Мәхмүт Әсад әфәнденең Россия сәяхәтен менә ничек бәяли: «Мәхмүт Әсад әфәнденең Россиянең Европа өлешендәге мөселман шәһәрләренә булган сәяхәте ике аерым мәмләкәттә яшәүче мөселманнар арасындагы аралашу дигән фикердән бигрәк, бәлки, Госманлы һәм Россия дәүләтләре арасындагы сәяси һәм иҗтимагый бәйләнышлар, дип бәяләнергә хаклы. Адәм баласының табигате шундый: кайчак иң якын җирләрне, иң кулай эшләрне онытып, чит җирләргә бәйле, мәнфәгатьләренә туры килми торган эшләр белән мәшгуль булалар. Бервакыт японнарның ислам динен кабул итәчәкләре турындагы әкиятләр газета битләрен тутырган иде. Шул ук вакытта Россиядә яшәүче миллионлаган ислам әһелләренең нәрсә эшләгәнен, нинди үсешләргә ирешкәнен, ихтыяҗлары нәрсәдән гыйбарәт булуын беркем дә искә алмады. Хәлбуки, төрекләр белән Россия мөселманнары арасында, дини бәйләнештән бигрәк, кавем һәм тел уртаклыгы да бар. Россиядәге ислам әһелләре дә төрек. Аларның алгарышы — төрекләрнең алгарышы дигән сүз. Тормышлары — төрек тормышының бер өлеше. Бу җәһәттән Госманлы мохитендә шималь төрекләренең тормышына, башка милләтләрнең иҗтимагый һәм әдәби дөньясына караганда, күбрәк игътибар бирү кирәк. Чөнки Россиядәге ислам әһелләренең мәдәни тормышы төреклекнең киләчәгенә мөһим йогынты ясый. Соңгы вакытларда газеталарыбыз Россиядәге ислам әһелләре хакында әзләп-әзләп мәгълүмат бастыра башлады. Иң зур теләк — Россиянең мөселман төбәкләреннән — Төркиягә, Төркиядән Россиягә сәяхәт төркемнәрен оештыру. Мондый сәяхәтләр төреклекнең ике мөһим як арасындагы мәдәни һәм иҗтимагый бәйләнышларын куәтләндерер» [32].

Мәхмүт Әсад әфәнде Россиядә үзенә булган игътибардан бик канәгать кала. Барган һәр урында Россия хөкүмәте гаскәр, полиция, жандармнарның күзәтүе астында рәсми очрашулар оештыра. Мәхмүт Әсад әфәнде Россия мөселманнары тарафыннан күрсәтелгән хөрмәтне тасвир итәрлек сүзләр таба алмый. Бу самими ихтирам өчен аларга чиксез рәхмәтен белдерә [33].

Мәхмүт Әсад әфәнденең Россия мөселманнары иҗтимагый тормышында күргәннәре файдалы һәм уңышлы дип бәяләнә. Ул Россия мөселманнарының сәүдә, сәнгать, мәгариф кебек тармакларда югары үсешкә ия булуларын күреп, чын күңелдән сөенә. Шулай ук бу мөселманнарда фанатизм булмаганлыгын да сиземли, чын мәгънәсендә камил дин һәм милләтчелек барлыгын күрә [34]. Россия мөселманнарының Госманлы-Россия мөнәсәбәтләре хакындагы түбәндәге фикерләрен әйтә: «Рос-

сия мөселманнарының ихлас теләкләре — Төркия белән Россия арасында чын дуслык булдыру. Чөнки мөселманнар Төркияне һәм төрек дөньясын ярата. Алар Төркия белән мөмкин булганча тыгыз мәдәни һәм иҗтимагый мөнәсәбәттә торырга тели. Дин, милләт һәм тел уртаклыгыннан караганда, бу теләк гаять табигый. Россия дәүләте белән Госманлы дәүләте арасындагы мөнәсәбәт ничаклы яхшы булса, үзләре белән Төркия арасындагы бәйләнешләр дә шул дәрәҗәдә ирекле рәвештә үсәчәк дип уйлыйлар. Шуның өчен ике дәүләтнең дус булуын телиләр. Русларда да бик матур гамәлләр күрдем. Заман шактый үзгәргән, вакыт узу белән, эшләнгән кайбер гамәлләренең әһәмияте азайган…»

«Мир Ислама» журналы хәбәрчесенең пантюркизм, панисламизм, мөселманнар арасындагы консерватизм һәм тәрәккыйпәрвәрлек белән бәйле сорауларына Мәхмүт Әсад әфәнде менә ничек җавап бирә: «Панисламизмны, пантюркизмны сәяси мәгънәсе белән алсак, ягъни бөтендөнья мөселманнары яки бөтендөнья төрекләре үзләренә махсус сәяси бер хөкүмәт корырга телиләрме, дип сорасагыз, моның булуы мөмкин түгел. Мондый хыяллар белән маташу мөселманнарга, төрекләргә, Төркиягә бигрәк тә зарарлы. Мөселманнар һәм төрекләр үзләре арасында гыйльми, икътисади, мәдәни мөнәсәбәт оештырырга телиләрме, дисәгез, әлбәттә, телиләр. Моның беркемгә дә зарары юк, киресенчә, файдасы гына тиячәк. Болай да мөселманнар арасында мәгънәви тугандашлык әүвәлдән бирле яшәп килә. Ул дәвам итәчәк [35]. Рус һәм фарсы милләтләре, арага кереп, төрекләрне икегә аерды. Фарсылар һәм руслар төрек берлегенә каршы киләчәк. Икенчедән, төрек милләте бик таркау. Россия һәм Кытай кебек ике бөек хөкүмәт төрекләрнең бер йодрыкта берләшүенә мөмкинлек бирмәячәк… Әмма берләшүенең уртак юлы бар: мәгариф һәм мәдәният юлында бөтен төрекләр алга барырга, җанланырга тиешләр. Боларның гомуми теләгенә минем дә кушыласым килә. Барлык төрекләрнең мәгариф, сәнәгать һәм сәүдәдә алдынгы буласылары килә. Бу җәһәттән берләшүләренең бернинди дәүләткә һәм кешелек дөньясына зыяны юк, бәлки дә файдасы гына булачак» [36].

Мәхмүт Әсад әфәнденең панисламизм мәсьәләсе турындагы фикере дә кызыклы. Ул панисламизмның хөкүмәт тарафыннан хупланмавын, буш хыял булуын белдерә һәм аның христиан күршеләрне тынычсызландырудан башка эшкә ярамаганын әйтә. Моңа каршы «Мир Ислама» журналының мөхәррире: «Хөкүмәт газеталарында Шебһәндерзадә Хилми әфәнденең котыртуларына нәрсә дияргә кирәк?» — дигән сорау бирә. Мәхмүт Әсад әфәнде җавабында Шебһәндерзадәнең хыялларга чумган бер мөхәррир икәнен, андый хыялыйпәрвәр кешеләрнең һәр җирдә булуын, тәкъдимнәре һәм язулары өчен үзе генә җавап тотуын бәян итә.

Хилми паша һәм Мәхмүт Әсад әфәнденең Идел-Урал сәяхәтләре беренче һәм соңгысы булулары белән әһәмияткә ия. Бигрәк тә Идел-Уралга бу тарафтан башка зур сәяхәтләр оештырылмый. Җәләл Нури Иләринең — 1910, **Әхмәт Җәүдәтнең** 1914 елда әлеге төбәккә кылган сәяхәтләре ул чорның бер татар матбугатында да чагылыш тапмаган булса, Хилми паша белән Мәхмүт Әсад әфәнденең сәяхәтләренә татар һәм рус телләрендәге газета-журналларның зур игътибар бирүе тирән мәгънәгә ия. Хилми пашага һәм Мәхмүт Әсад әфәндегә күрсәтелгән игътибарны аларның җәмгыятьтә тоткан урыннарына һәм зыялылыкларына бәя дип шәрехли алабыз. Хилми паша Россия мөселманнары арасында танылган кеше түгел иде, шул сәбәпле аңа күрсәтелгән хөрмәтне «вазифасына»

һәм Госманлы дәүләтенә хөрмәт, дип бәяләү дөресрәк булыр. Ә Мәхмүт Әсад әфәнде Идел-Урал төбәгендә гомер итүче татар зыялыларының күбесенә үзе килгәнче үк мәшһүр булган. Аның «Ислам тарихы» исемле ике томлы китабы татарчага тәрҗемә ителгән [37]. Күпхатынлылык турындагы әсәреннән кайбер өзекләр татар журналларында дөнья күргән [38]. Мәхмүт Әсад әфәнде Истанбулда татар мөһаҗирләре нәшер иткән «Мөселманнарны тану» журналының редколлегия әгъзасы да булган. Гомумән, юлы Истанбул аша узган һәр татар зыялысы аның белән очрашырга тырышкан.

Татарларның Төркиягә күченүләре һәм андагы тормышлары турындагы мәкаләбез шуның белән тәмамланды. Татарлар 1552 елдан соң Россиянең төрле өлкәләренә, Төркестан, Кырым һәм Госманлы дәүләтенә күченә башлыйлар. Госманлы дәүләтенә тәүге күченгән татарлар турында әлегә кадәр документлар табылмады. Госманлы архивларындагы документларның иң борынгысы XVII гасыр ахыры — XVIII йөз башына нисбәтле. Бәлки, бу архивлардагы барлык документлар тулысы белән билгеле бер системага салынганнан соң, яңа чыганакларны ачыкларга мөмкин булыр. Шулай да Төркиядә яшәгән иң мәшһүр татар зыялылары, аларның иҗтимагый-мәдәни эшчәнлекләре, төрекләр һәм татарлар арасындагы багланышлар турындагы мәгълүматлар укучыга кызыклы булгандыр дип уйлыйм.

Искәрмәләр

1. OATP, DH. MKT, 1043/22.
2. OATP, Y.PRK.EŞA, 48/69.
3. OATP, DH. MKT, 1054/79,
4. OATP, DH. MKT, 1567/93, DH. MKT, 1560/89, DH. MKT, Y. PRK.DH. 10/51, DH. MKT. 982/87, DH. MKT, 618/48, DH. MKT, 2099/30, DH. MKT, 2091/22, İ.DH, 1108/86733
5. Пантюркизм — төрки халыкларны бердәмлеккә өндәгән иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. XIX гасыр ахырында Төркия һәм Кырымда барлыкка килә. Татар милли хәрәкәтендә пантюркизм киң мәгънәдә кабул ителә. Ул милли үзбилгеләнүгә ирешү, милли мәдәниятне һәм милли үзаңны үстерү, тугандаш төрки халыклар белән якынаю һәм аларның мәдәниятен өйрәнүдә чагылыш таба. (ТЭС, 2002. — Б.491.)
6. Панисламизм — мөселманнарның Алла каршында бертигез булуын, аларның бердәмлеге нигезендә бер дәүләткә берләштерү зарурлыгын алга сөргән дини-сәяси тәгълимат. Бу идея XIX йөзнең 70 нче елларында төрек мәгърифәтчесе Нәмык Кәмал (1840-1888) тарафыннан тәкъдим ителә, Җәмаледдин әл-Әфгани тарафыннан үстерелә. Татарларда панисламизм фикерләре киң таралмый. (ТЭС, 2002. — Б.490.)
7. OATP, ZB, 324/41.
8. Мәтин. — 1908. — 28 июль. — №1.
9. Муса Акъегетзадә хакында мәгълүмат бирелгән хезмәтләрнең барысында да бу газетаның исеме «Өч кардәш» дип язылган.
10. Мәхмүт Әсад әфәнденең килүе // Йолдыз. — 1913. — 2 август. — №1017.
11. Кәрим Сәид. Мәхмүт Әсад әфәнде // Кояш. — 1913. — 26 август. — №199.
12. Хөсәен Хилми паша (1855-1923) озак еллар төрле губерналарда төбәкләрнең җирле идарәсе җитәкчесе була. Габделхәмит II, Йәмәндә чыккан чуалышларны бастыру өчен Хилми пашаны 1898 елда Йәмән губернаторы итеп билгели. 1899 елда министр вазифасын башкара. Биш ел Йәмәндә эшләгән Хилми пашаны үтерергә телиләр. Ул каты яраланып исән кала, әмма вазифасыннан китәргә мәҗбүр була. Соңрак Румелиянең баш инспекторы булып эшли. II мәшрүтият игълан ителгәннән соң, эчке эшләр минстры итеп куела. 1909 елның февралендә Камил Паша җитәкчелегендәге Министрлар Кабинетының таралуы нәтиҗәсендә, 2 ай премьер-минстр була. 31 март вакыйгалары аркасында вазифасыннан китә. 1909 елның май аеннан тугыз айга сузылган икенче Премьер-министрлык чоры башлана. 1910 елның 12 гыйнварында бу вазифасыннан китә. Соңрак елларда Аян Мәҗлесе әгъзасы, суд эшләре министры вазифаларын башкара. Госманлы дәүләтенең илчелек тоту хокукы гамәлдән чыкканчыга чаклы, Вена илчесе булып тора. Илчелекләр гамәлдән чыгарылгач, кире иленә кайтмыйча, Венада яшәп кала һәм 1923 елда шунда вафат була. Җәсәде Истанбулга кайтарылып, Бешикташ районындагы «Яхъя әфәнде мәчете» нең бакчасына күмелә. (Кара: Маһир Айдын. Хөсәен Хилми паша // Төркиянең дин эшләре фонды энциклопедиясе. XVIII том. — Б.550-551.)
13. Мәхмүт Әсад әфәнде (1856-1918) галимнәр гаиләсендә туа, Истанбулда гимназия бетергәннән соң, «Фатих» мәдрәсәсенең хәрби сыйныфында дөньяви һәм дини фәннәр өйрәнә. Хәрби бүлектә офицерлар докторантурасында укып, математика укытучысы дипомы ала. Бер үк вакытта укуын хокук мәктәбендә дә дәвам итә һәм аны бик яхшы билгеләргә тәмамлый. Анадулы губернасында укытучы, суд җитәкчесе булып эшли. 1896 елда Истанбулга кайта һәм Хокук мәктәбендә укыта

башлый. II мәшрүтият игълан ителгәннән соң, милекләр акты һәм җир кадастры министры итеп куела. Бервакыт суд эшләре министры да булып ала. 1914 елда Ыспартаның халык депутаты булып сайлана. 1918 елда Истанбулда вафат була. Мәхмүд Әсад әфәндене хокук һәм ислам тарихы буенча язылган күпсанлы әсәрләре бар. (Кара: Мәхмүт Әсад әфәнде // Төрек энциклопедиясе. XIX том.)
14. Истанбулда чыккан «Умран» газетасында Сөләйман Каминең бу сәхәт белән бәйле хатирәләре «Ася-йы Шаркыя сәяхәте» исемле мәкаләләр җыентыгы итеп басыла (1887 ел) һәм шул ук исем белән Истанбулда (1891 ел) Әхмәт Ихсан тарафыннан китап булып нәшер ителә.
15. Җәләл Нури. Төньяк хатирәләре. — Истанбул, 1330 (һ). — Б.22-29.
16. Падишаһ исеменнән бөтен эшләрне йөртүче, премьер-министр.
17. Хилми паша Казанда // Йолдыз. — 1910. — 19 апрель. — №259.
18. ТРМА. 1 ф., 4 тасв., 4240 эш.
19.Хилми паша Мөхәммәдия мәдрәсәсендә // Йолдыз. — 1910. — 21 апрель. — №530.
20. Хилми паша Казанда // Вакыт. — 1910. — 22 апрель. — №607.
21. Хилми паша турында Казан халкы // Вакыт. — 1910. — 24 апрель. — №608.
22. Кәрим Сәид. Мәхмүт Әсад әфәнде // Кояш. — 1913. — 25 август. — №199.
23. ТРМА, 1 ф., 4 тасв., 5468 эш.
24. Кәрими Фатих. Мәхмүт Әсад әфәнде Оренбургта // Вакыт. — 1913. — 3 август. — №1266.
25. Абдуллаһ әл-Мази. Мәхмүт Әсад әфәнде бине Әмин әл-Сәйдишәһри // Дин вә мәгыйшәт. — 1913. — № 31. — Б.491-492.
26. Дин үзгәртү // Дин вә мәгыйшәт. — 1913. — №32. — Б.517-521.
27. Махмут Эсад эфенди в России // Мир Ислама. — 1913. — №7. — Б.471-472.
28. Р.Н.Мәхмүт Әсад әфәнде Уфада // Вакыт. — 1913. — 4 август. — №1267.
29. Фатих Әмирхан. Мәхмүт Әсад әфәнде белән «Кояш» сайфиясендә әңгәмә // Кояш. — 1913. — 5 август. — №188.
30. Кәрим Сәид. Мәхмүт Әсад әфәнде // Кояш. — 1913. — 15 сентябрь. — №217.
31.Мәхмүт Әсад әфәнде һәм Русия мөселманнары // Кояш. — 1913. —15 сентябрь. — № 217.
32. Безнең турыда ни диләр? // Тәрҗеман. — 1913. — 12 сентябрь. — №1913.
33. Шунда ук.
34. Мәхмүт Әсад әфәнде Финляндиядә // Тәрҗеман. — 1913. — 17 декабрь. — № 277.
35. Шунда ук.
36. Исламчылык, төрекчелек // Тәрҗеман. — 1913. — 28 сентябрь. — №213.
37. Мәхмүт Әсад. Ислам тарихы. I том. — Казан: «Миллият» тип., 1908. — 190 б.
38. Өйләнешү мәсьәләсенең фәлсәфәсе // Шура. — 1911. — №1. — Б.11-14.

Искәрмәләрдәге кыскартылма сүзләр

1. OATP — Төркия Җөмһүрияте Министрлар Кабинеты каршындагы Госманлы архивы.
2. A. MKT. MHM – Sadâret Mektubi Kalemi Mühimme Evrakı (Министрлар Кабинетының мөһим документлар канцеляриясе).
3. C. HR — Cevdet Hariciye (Җәүдәт тышкы эшләр министрлыгы (1553-1904 елларның документларын үз эченә алган архив бүлеге. Ул 1932-1937 елларда мөгаллим Җәүдәт җитәкчелегендәге документларны төркемләү комиссиясе тарафыннан оештырылган)).
4. C. MF — Cevdet Maarif (Җәүдәт Мәгариф министлыгы).
5. C. ML — Cevdet Maliye (Җәүдәт финанс министрлыгы).
6. DH. EUM. KLU – Dahiliye Nezâreti Emniyet-i Umumiye Müdüriyeti Kalem-i Umumî (Эчке эшләр министрлыгының куркынычсызлык буенча баш идарәсенең гомуми крнцелярия бүлеге).
7. DH. EUM. SSM – Dahiliye Nezareti Emniyet-i Umumiye Müdüriyeti Seyrü Sefer Kalemi (Эчке эшләр министрлыгы куркынычсызлык баш идарәсенең килүкитүчеләрне исәпкә алу бүлеге).
8. DH. EUM. THR – Dahiliye Nezareti Emniyet-i Umumiye Müdüriyeti Tahrirat Kalemi (Эчке эшләр министрлыгы куркынычсызлык баш идарәсенең сәркатиплек идарәсе).
9. DH. KMS – Dahiliye Nezâreti Kalem-i Mahsus (Эчке эшләр министрлыгы куркынычсызлык баш идарәсе хезмәткәрләренең канцелярия бүлеге).
10. DH. MKT — Dahiliye Nezareti Mektubi Kalemi (Эчке эшләр министрлыгының канцелярия бүлеге).
11. DH. SAİD – Dahiliye Nezreti Sicil-i Ahval İdaresi (Эчке эшләр министрлыгының чиновникларны теркәү идарәсе).
12. DH. SN. THR – Dahiliye Nezâreti Sicil-i Nüfus Tahrirat Kalemi (Эчке эшләр министрлыгының халыкны теркәү бүлеге).
13. HAT – Hatt-ı Hümayun (Падишаһ фәрманы).
14. İ. TAL – İrade Taltifat (Падишаһның бүләкләү турындагы боерыгы).
15. MV – Meclis-i Vükelâ Mazbataları (Министрлар Кабинетының стенографик хисаплары).
16. Y. MTV – Yıldız Mütenevvi Maruzat (Йолдыз фондында төрле гаризалар бүлеге)
17. Y. PRK. ASK – Yıldız Parekende Askeri Maruzat (Йолдыз фондында хәрби эшләрләр буенча гаризалар бүлеге)
18. Y. PRK. ESA – Yıldız Parekende Evrakı, Elçilik, Şehbenderlik ve Ateşemiliterlik (Йолдыз фонды, илчелекләр, консуллыклар һәм хәрби бүлекләр)
19. Y. PRK. KOM – Yıldız Perakende Komisyonlar Maruzatı (Йолдыз фондының гаризалар комиссиясе).
20. Y. PRK. TKM – Yıldız Perakende Tahrirat-ı Ecnebiye ve Mâbeyn Mütercimliği (Йолдыз фондының тәрҗемә һәм чит илләр белән язышу бүлекләре).
21. ZB – Zabtiye Nezâreti (Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы).

Төрекчәдән ***Рушания Алтай*** *тәрҗемәсе*

МИЛЛИ МАТБУГАТ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

«КЫЗЫЛ» СҮЗЕНДӘ БЕРНИНДИ СӘЯСӘТ ЮК...»

ШУШЫ КӨННӘРДӘ БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЧЫГА ТОРГАН «КЫЗЫЛ ТАҢ» ГАЗЕТАСЫНА 95 ЕЛ ТУЛА. ШУЛ УҢАЙДАН ГАЗЕТАНЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЕ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ КАНДИДАТЫ, БАШКОРТСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН МАТБУГАТ ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТ ХЕЗМӘТКӘРЕ ФАИЛ ФӘТХЕТДИНОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.

– Фаил әфәнде, Сезне һәм редакция хезмәткәрләрен чын күңелдән «Кызыл таң» газетасының 95 еллык юбилее белән котлыйбыз! Киләчәктә яңа иҗат уңышлары, абунәчеләрегезнең артуын телибез. 95 ел тулы бер дәверне, берничә буын укучыларны үз эченә ала. Сорауларыбызны да тарих битләреннән башлыйк әле.

Газета ул – җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне яктыртучы гына түгел, ә җәмәгатьчелек фикерен формалаштыручы, республика, халык тарихының аерылгысыз өлеше. Газетаның узган юлында нинди мөһим этапларны билгеләп үтәргә мөмкин? Басма үз тарихында эз калдырган кайсы шәхесләр белән горурлана?

— Иң тәүге сүз итеп журнал укучыларына «Кызыл таң»ның Башкортстан Республикасы Дәүләт җыелышы — Корылтай һәм Хөкүмәт органы буларак Уфада татар телендә чыга торган газета икәнлеген әйтәсе килә.

Ә инде тарихка кагылганда, Оренбург шәһәрендә 1918 елның 1 мартында газетабызның барлыкка килүен Башкортстан Республикасының тууы белән бәйләп карау урынлы булыр. Чөнки Башкортстан дәүләтчелеген юридик рәсмиләштерүгә вакытлы матбугат, шул исәптән «Кызыл таң» да (ул вакытларда «Башкортстан», «Башкортстан хәбәрләре», «Яңа авыл», «Коммуна» дигән исемнәр белән чыккан)

үз өлешен керткән. Авыр гражданнар сугышы, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы, тыныч тормыш елларында республика халкы газета битләреннән, төрле вакыйгалар турында мәгълүмат белән беррәттән, күпьяклы белем дә алган. Кыскасы, илебездә, республикабызда барган төрле үзгәрешләр, хезмәт казанышлары һәрвакыт газетадагы язмаларда чагылыш тапкан. «Кызыл таң» һәрчак дәверенә хас эчтәлекле публицистик мәкаләләре, очерклары, фельетоннары белән кыю рәвештә чыгыш ясаган. Ләкин ул бервакытта да үзенең төп кыйбласыннан — укучыларын Ватанга, туган җиргә, хезмәткә мәхәббәт, милләтара татулык, патрио-

тизм һәм батырлык идеяләре рухында тәрбияләүдән читләшмәгән һәм әле дә шушы традицияне дәвам итә. Шул ук вакытта һәрбер чор үзе дә газета хезмәткәрләре язмышына хәлиткеч йогынты ясаган. Мәсәлән, безнең тәүге мөхәррирләребезнең өчесе — Муса Йосыпов (соңрак ул Казан педагогия институты директоры, Татар академия театры директоры да була), Гайса Габбасов, күренекле язучы Имай Насыйри, 1937 елда репрессиягә дучар булып, юк ителәләр. Редакциянең дистәләгән хезмәткәре, каләмне штыкка алыштырып, Бөек Ватан сугышында катнашкан.

Ә инде «Кызыл таң» газетасы коллективында тәрбияләнеп, иҗади чыныгу үткән, башкорт һәм татар җәмәгатьчелегендә киң танылу алган дистәләрчә журналист, әдипләр, шагыйрьләр, фән кешеләре, дәүләт эшлеклеләре бихисап. Башкортстанның халык шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Әнгам Атнабаев, Абдулхак Игебаев, Башкортстанның халык язучылары Нәҗип Асанбаев, Суфиян Поварисовларның исеме газетабыз елъязмасында алтын хәрефләр белән язылган. Шулай ук Гариф Гомәр, Динис Исламов, Гайнан Әмири, Әнвәр Бикчәнтәев, Әсгать Мирзаһитов, Хәсән Сарьян, Вазих Исхаков, Якуп Колмый кебек күренекле язучыларны да телгә алмый мөмкин түгел. Яшьлегендә бездә журналист булып эшләп, фән дөньясына кереп киткән Үзбәк Гыймадиев, Суфиян Поварисов, Радик Сибәгатов, Рөстәм Кузеев, Марсель Бакиров, Илдар Низамов, Камил Гыйрфанов кебек профессорлар белән дә горурланабыз.

Безнең газета редакциясе әүвәлдән үк Башкортстанда матбугат, мәгариф, мәдәният кадрлары әзерләү үзәге дә булып саналган. Китап нәшрияты һәм радиокомитет оештырылгач та, анда җитәкчеләр булып безнең элекке хезмәткәрләр эшләгән. Хәтта Татарстанга да өлеш чыккан. Муса Йосыпов турында әйтеп үттем инде. «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарының җаваплы мөхәррире булган Сафа Борһанны да безнеке санныйбыз. «Кызыл таң»да тәүге журналистлык чыныгуы алган Мөнир Әһлиуллин туксанынчы елларда «Ватаным Татарстан» газетасына җитәкчелек итте.

Бүген укыгыз!
Кызыл таң
№ 37 (24151), чәршәмбе, 26 февраль, 2013 ел
Республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни басмасы
Президент маршрутлары
Баектыру комбинаты төбәкне ник баетмый?
ВЛАДИМИР ПУТИН КОТЛАУ ЮЛЛАДЫ
БАР ЯКЛАП ТА ӘЗЕРБЕЗ
Бүген Уфада Халыкара балалар уеннары башлана
Җиңү паркында тантана
Уфада Интеллиада уткару мөмкинлеге тикшерелә
ОЛИМПИЯ РЕЗЕРВЫНДАГЫ ЯҢА МӘКТӘП АЧЫЛДЫ
ЛАЕКЛЫ АЛМАШ ТӘРБИЯЛӘНӘ
КАРТАСЫ БАР ДА БИТ...
Социаль мохит
Җайсыз җайланмалар
Киләсе санда

– Совет елларында Татарстанда «Кызыл», «Совет», «Социалистик» исемнәрдә чыккан күләмле газеталар, журналлар биграк тә «үзгәртеп кору» елларыннан соң исемнәрен капылт үзгәрттеләр. Сезнең коллектив 1944 елда бирелгән «Кызыл таң» исеменә тугры калган. Моның сере нәрсәдә?

— Без моңардан бернинди сер дә ясамыйбыз. «Кызыл таң» исемен алыштырыгыз, инде заман үзгәрде, коммунизм төзү чоры узды, шулай булгач, «кызыл» дигән сүзне алып ташларга кирәк, дип киңәш бирүчеләр дә бар. Ләкин мондый фикер белән бер дә килешәсе килми. Халкыбызда, кызарып

аткан таң көннең аяз, кояшлы булачагын хәбәр итә, дигән сынамыш та бар бит. Шулай ук, «таң» сүзе ул үзе метафорик мәгънәгә ия. Мәсәлән, әдәбиятта «таң җиле», «саба җиле» дигән образлар бар. Борынгы шагыйрьләребез Кол Гали, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал иҗатында, XIX, XX гасыр әдәбиятында бу образлар гаиләгә яхшы хәбәр китерүче буларак символик мәгънәгә ия. Ә «Кызыл таң»ны без гаилә газетасы итеп чыгарырга тырышабыз. Димәк, бүгенге редакция коллективы газетабызны алдыручы һәрбер кешегә бары тик яхшылык, изгелек, иминлек һәм гаилә күгенең һәрвакыт аяз булуын тели. Шулай булгач, газетабызның исеме җисеменә туры килә, монда бернинди сәясәт тә юк.

– Сезнең редакция коллективы «Тулпар» – яшьләр, «Әллүки» балалар журналлары кебек яңа басмалар нигезләп, аларга фатиха биргән. Сезнең карамакта нәшер ителә торган бу яңа басмаларның мәсләкләре нинди? Сезнең үзара хезмәттәшлек нинди формаларда тормышка ашырыла, уртак проектларыгыз бармы?

— Бу сорауда төгәлсезлек бар. 1991 елда чыга башлаган «Өмет» яшьләр газетасы да, 1994 елда нигезләнгән «Тулпар» да — тәүдән үк дәүләт карамагындагы үзаллы басмалар. Әмма шунысы бар: алар оештырылу белән, «Кызыл таң»ның егәрле, яшь, сәләтле берничә журналисты анда эшкә күчте. «Тулпар»ның беренче баш мөхәррире Римат Кашапов та, «Өмет»нең әлеге баш мөхәррире Рәдис Ногманов та — элекке «Кызыл таң»чылар. Бераздан инде «Өмет»тән кадрлар «Кызыл таң»га килә башлады. Әйткәнебезчә, «Өмет»нең беренче җитәкчесе Марат Муллакаев — 1994 елда, икенче җитәкчесе (мин) 2001 елның башында «Кызыл таң»ның баш мөхәррире итеп үрләтелдек.

Югарыда сүз барган ике басманың мәсләгенә килгәндә, алар безнекенә охшаш. Нинди дә бер уртак рәсми проектларыбыз булмаса да, тыгыз хезмәттәшлектә, үзара ярдәмләшеп яшибез, эшлибез. Башкача булуы мөмкин дә түгел.

«Әллүки» журналының гамәлгә куючысы (учредителе) — «Кызыл таң» газетасы редакциясе» дәүләт унитар предприятиесе. Ул Башкортстан Президенты Указы һәм Хөкүмәт карары нигезендә 2004 елның гыйнварында нәшер ителә башлады. Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен тәгаенләнгән бу журнал аена бер тапкыр татар телендә чыга. Аның баш мөхәррире вазифасы да миңа йөкләтелгән. Хезмәткәрләр «Кызыл таң» редакциясендә утырып эшлиләр.

– Бүген барлык матбугат чаралары өчен иң катлаулы проблема — тиражны киметмәү, абунәчеләр санын арттыру, даими укучылар даирәсен киңәйтү. Бу яктан караганда, сезнең хәлләр ничек? Базар шартларына яраклашуның нинди яңа юлларын барлыйсыз!

— Газета-журнал, китапка халкыбызның мәхәббәте кимү — Башкортстанга да, Татарстанга да, тоташ илгә дә хас бәла инде ул. Бу турыда әллә ни сүз озайтып торасы да килми. Тиражны киметмәү, укучылар даирәсен бер тирәдәрәк тоту мәсьәләсендә республикабыздагы башкортча, русча басмалар белән чагыштырганда артта калмыйбыз, кайбер пунктлар буенча алга да чыгабыз.

Базар шартларына яраклашуга килгәндә... Реклама эшчәнлеген киңәйтергә тырышабыз. Финанс чыгымнарын киметүдә кайбер нәтиҗәләргә ирешәбез. Үткән елның февралендә без «Кызыл таң»ның җырлы кичләре» дигән яңа проект башлап җибәрдек. Аның асылы: аерым бер районнан чыккан сәхнә осталарын җыеп, үзешчәннәрне дә катнаштырып, Уфа «Нур» татар дәүләт театрында айга бер тапкыр түләүле концерт күрсәтәбез. Тәтешле, Илеш, Дүртөйле, Бакалы, Борай, Балтач, Туймазы, Яңавыл,

Миякә районнары белән бу чара бик матур үтте. Район көне, якташлар очрашуы буларак уза мондый кичәләр. Аларны редакция журналистлары оештыра. Безгә аның финанс яктан файдасы да бар.

– Даими укучыларыгызның мәхәббәтен нинди ысуллар белән яуладыгыз? Редакция кайсы темаларга күбрәк игътибар бирә? Укучылар нинди язмаларга битараф түгел?

— Бу сорауларның беренчесенә уңай мисал итеп «Кызыл таң»ның җырлы кичләре»н телгә алырга мөмкин. «Кызыл таң» ул рәсми сәяси-иҗтимагый басмадан тыш элек-электән гаилә газетасы буларак та билгеле. Халыкның үзәгенә үткән проблемаларны һәм аларны хәл итү юлларын күрсәтергә омтылабыз. Мондый кыска язмалар беренче биттә «Әйтер сүзем бар» дигән сәхифә астында урнаштырыла. Ярты гасыр элек үк барлыкка килгән сатирик һәм юмористик бүлек (хәзер ул «Чирен яшергән — үлгән...» дип атала) аеруча популяр. Аның геройлары Гаделҗан белән Тетәбикә үткен каләмнәре ярдәмендә тормыштагы кимчелекләрне гадел рәвештә тетеп килә. Ун ел чамасы элек туган «Дөнья бу...» сәхифәсе бер генә саннан да төшеп калганы юк. Аның язмаларына укучылар битараф түгел. Татар халкының тарихи шәхесләре, күренекле замандашларыбыз турында материаллар яратып укыла.

– Татар, рус, инглиз телләрендә газетагызның сайтын булдырып, сез бөтендөнья мәгълүмат челтәрендә Башкортстан яңалыкларын, республикада яшәүче татарлар тормышын бик киң даирәгә җиткерүгә ирешкәнсез. Сезнең коллектив уңышлары белән хаклы рәвештә горурланырга була. Сез – безнең өчен үрнәк.

Сайттан күренгәнчә, татарча вариантта 22 сәхифә (шул исәптән видеоматериаллар да), русча вариантта – 8, инглизчә вариантта 4 сәхифә бар. Сайтка көнгә уртача ничә кеше керә, татарча, русча, инглизчә текстларны укучылар саны нык аерыламы? Киләчәктә сайтны камилләштерү буенча нинди планнарыгыз бар? Язмаларның астына «Фикереңне әйт» («комментарий») кертергә уйламыйсызмы?

— Сайт мәсьәләсендә Сезнең сорауның үзендә үк җавап бар. Сайтка көненә уртача 1000 кеше керә. Табигый ки, зур күпчелекне татарча текстларны укучылар тәшкил итә. Планнар бар, ләкин алар турында әлегә әйтмәү хәерлерәктер.

– Татарстан газета-журналларында эшләүче коллегаларыгыз белән нинди өлкәләрдә хезмәттәшлек итәсез? Татарстанда «Кызыл таң» газетасын күп кеше алдырамы? Алар кайсы төбәкләрдән?

— Коллегалар белән хезмәттәшлек рәсми-эшлекле диярга мөмкин. Аратирә телефон аша сөйләшәбез. Казанда һәм Чаллыда яшәүче байтак якташларыбыз газетабызны алдырып укый.

– Юбилей чаралары турында сөйләп үтсәгез иде.

— «Кызыл таң»ның туган көне һәр биш ел саен Уфада зурлап, матбугат бәйрәме буларак үткәрелә. Бер куанычыбыз белән дә уртаклашасым килә. 90 еллыкка «Кызыл таң»ның кыскача энциклопедиясен һәм менә шушы көннәрдә фотоальбомын эшләп чыгардык. Алар — яхшы кәгазьдә төсле итеп басылган югары зәвыклы һәм зур күләмле белешмә әсбаплар.

Юбилей кичәсен үзенчәлекле итеп әзерләдек. Аның программасы «Кызыл таң»да эшләгән һәм әле эшләүче шагыйрьләр сүзләренә язылган җырлардан тора. Аларны Башкортстанның һәм Татарстанның танылган җырчылары башкарачак. Кичә 23 мартта Уфаның иң зур һәм зиннәтле сәхнәләренең берсендә — «Нефтьче» мәдәният сараенда булачак.

– Әңгәмәгез өчен рәхмәт!

*Әңгәмәдәш — **Илдус Заһидуллин***

«МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫНА 100 ЕЛ

БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

ГАБДЕЛХАК ШӘМСЕТДИНОВ,
«Мәгариф» журналының баш мөхәррире, тарих фәннәре кандидаты

МОННАН НӘКЪ 110 ЕЛ ЭЛЕК 1903 ЕЛДА ҖАЕК (УРАЛЬСК) ШӘҺӘРЕНДӘГЕ «МОТЫЙГИЯ» МӘДРӘСӘСЕНДӘ «ГЫЙЛЬМИ МӘҖЛЕС» ДИГӘН МӘДӘНИ-ӘДӘБИ ТҮГӘРӘК БАРЛЫККА КИЛӘ. ХӘЛФӘ КАМИЛ МОТЫЙГЫЙ-ТӨХВӘТУЛЛИН, ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ТАГЫН БЕРНИЧӘ ШӘКЕРТ ШӘҺӘР ХАЛКЫ ӨЧЕН ӘДӘБИ-МӘДӘНИ КИЧӘЛӘР УЗДЫРАЛАР; КУЛЪЯЗМА «МӘГАРИФ» ГАЗЕТАСЫ ҺӘМ «ӘЛГАСРЕЛҖӘДИТ» («ЯҢА ГАСЫР») ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ЖУРНАЛ ЧЫГАРЫП ТАРАТАЛАР.

Татар матбугаты тарихында «Мәгариф» атамасы беренче тапкыр шунда кулланылгандыр, мөгаен…

Әлбәттә, кулдан язып таратылган бу газета-журналлар матбугат ирегенә сусаган, укыту-тәрбия системасын үзгәртеп кору идеясе белән янып йөргән алдынгы карашлы хәлфә-мөгаллимнәрнең һәм шәкертләрнең чарасызлыктан күргән гамәле генә була.

Йөз ел дәвамында патша хөкүмәтеннән татар телендә вакытлы басма матбугат чыгарырга рөхсәт сорап интеккән татар зыялылары, халыкның мәгърифәткә омтылышын сүндермәс өчен, әнә шулай кулдан язып, газета-журналлар таралар; календарьлар, альманахлар бастыралар, халык авыз иҗатын саклап калу чараларын күрәләр. Ә инде 1905 елгы революциядән соң, ниһаять, татарларга да матбугат иреге бирелгәч, Россия империясенең милләттәшләребез күмәкләшеп яшәгән төрле төбәкләрендә, яңгырдан соң чыккан гөмбәләр кебек, күп санда татарча газета-журналлар нәшер ителә башлый. Кем тарафыннан чыгарылса да, нинди мәсләкне алга сөрсәләр дә, ул басмаларда уку-укыту, халыкны аң-белемле итү, мәгариф системасын үзгәртеп кору проблемалары үзәккә куела, шул идея кызыл җеп булып сузыла. Без моны беренче гомумтөрки газета булган «Тәрҗеман»да да, татар



“Мәктәп”
1913-1914

Шиһаб
ӘХМӘРОВ

1913 ел башында Казан губернаторы канцеляриясе “Сабах” нәшриятында **Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров**ның җаваплы редакторлыгында **“Мәктәп”** дигән педагогик журнал чыгарырга рөхсәт бирә.

Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров 1882 елның 30 декабрендә Сембер губернасы Буа өязенә караган Чүпрәле волостеның Яңа Задур авылында крестьян гаиләсендә туган. Буа мәдрәсәсендә белем алгач, Әлмәттә мөгаллим булып эшли.

1908 елда ул Казанга күчеп килә. “Болгар” кунакханәсе номерларына урнаша. Бертуган **Габделвәли** һәм **Мөхәммәтвәли Әхмәдуллиннар** 1902 елда оештырган “Сабах” нәшриятының китап кибетендә эшли.

Өйләнгәнче, Ш. Әхмәров “Болгар” кунакханәсендә Г. Тукай белән янәшә бүлмәдә гомер кичерә. 1912 елда ул Салих Сәйдәшевнең апасы Әминәгә өйләнә һәм квартирага күчә. Г. Тукай кунакханәдә яшәп кала. Әмма ул Шиһаблар квартирасына еш килә. Булачак мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев белән дә шунда очраша, аның гармоньда бик матур итеп уйнавына соклана. Салих унбер-унике яшеннән шушы җизнәсе тәрбиясендә үсә (аның әтисе Салих туарга 15 көн кала үлеп киткән була).

...Әхмәдуллиннар башта журналның программасын төзиләр. 28 бүлектән торган ул программада педагогик тәрбия мәсьәләләре, урта һәм түбән классларда укытыла торган фәннәрне укыту методикасы, мәктәп-мәдрәсәләргә карата руханилар һәм җәмәгатьчелекнең тоткан урыны, аларда гомуми белем бирү һәм аны дәүләт гимназиясе программасына яраштыру, мөселманнарга техник белем бирү, мөселман балаларына мәҗбүри башлангыч белем бирү, хатын-кызларны укыту кебек пунктлар була.

“Мәктәп”нең 1 нче саны 1913 елның 21 февралендә (яңа стиль белән 6 мартта) дөнья күрә. 1914 елның октябрендә, Беренче бөтендөнья сугышы бару сәбәпле, чыгудан туктый.

Әмма бу журнал татар педагогика фәне тарихында зур әһәмият казанып өлгерә, галим-педагогларда вакытлы матбугат белән кызыксынуны көчәйтә. Аның авторларыннан Галимҗан Ибраһимов, күренекле галим Мөхетдин Корбангалиев, язучы һәм педагоглардан Нәҗип Думави, Фатих Сәйфи-Казанлы, тарихчы Газиз Гобәйдуллин һ. б. шундый күп кенә атаклы шәхесләрне санап узарга мөмкин.

“Мәгариф” ельязмасы



90 Мәгариф

Безнең максат, безнең юл

- Алдынгы педагогик фикер, мәгариф һәм мәдәният сәясәте булдыру
- Мәгариф һәм мәдәниятнең иң мөһим мәсьәләләрен хәл итүдә катнашу һәм аларны журнал битләрендә яктырту
- Белем һәм тәрбия бирүнең өр-яңа методикасын, технологияләрен, алдынгы педагогик тәҗрибәне киң тарату
- Журнал укучыларына фән һәм әдәбият үсеше турында бай мәгълүмат бирү
- Дәүләт теле буларак, татар теле һәм рус теле үсеше мәсьәләләре
- Татарстанның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында сөйләү Дәүләтчелегебезне яклау, ныгыту
- Яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә халык педагогикасын киң куллану, халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын саклау
- Мәгарифне мәгълүматлаштыру Укытучыларның һәм укучыларның сәламәтлеген саклау, ныгыту мәсьәләләре

Журналның һәр санында:

- Татарстанда, Россиядә мәгариф үсеше. Мәгърифәтчеләребезнең, күренекле педагог галимнәребезнең педагогика һәм психология фәне үсеше турындагы фикерләре
- Татарстан Республикасының дөнья күләмендә, Россиядә тоткан урыны, икътисады, промышленносте, авыл хуҗалыгы, мәгарифе, мәдәнияте, татар теле, әдәбияты үсеше турында дәүләт, хөкүмәт җитәкчеләре, фән эшлеклеләре, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар белән әңгәмәләр
- Мәгарифне модернизацияләү һәм реструктуризацияләү мәсьәләләре
- Чит илләрдә һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез балаларына, рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына, рус балаларына, татар мәктәбендә белем алучы балаларга татар теле һәм әдәбияты укыту
- Рус теле һәм әдәбиятын, чит телләрне заманча укыту турында мәшһүр галимнәр, танылган мөгаллимнәр мәкаләләре
- Башлангыч мәктәпне үзгәртеп кору, анда белем бирү, яңа укыту системалары, укучыларның фикерләү сәләтен үстерү турында язмалар
- Биология, химия, физика, математика, тарих укыту мәсьәләләре
- Иҗади эшләүче укытучылар тәҗрибәсе

“Мәгариф” ельязмасы

матбугатының башлангычы саналган «Нур»да да, XX гасыр башында дөнья күргән башка газета-журналларда да ачык күрәбез.

Биредә шунысын да әйтеп үтү урынлы булыр: инде гасыр башында ук «Мәгариф» исеме белән чыккан басмалар да булган. Мәсәлән, 1909 елның гыйнварыннан 1910 ел башына кадәр Әстерхан шәһәрендә «Мәгариф» исемле журнал нәшер ителүе билгеле. (Нәшире — Г.Галиев, мөхәррире — М.Рәхимкулов.) Әмма ул дини журнал булган һәм анда, нигездә, дини темага язылган материаллар гына урын алган.

Шул ук елда Оренбургта да татар телендә фәнни-педагогик «Мәгариф» журналы чыгара башлыйлар. Ләкин ул да төрле сәбәпләр аркасында озак яши алмый.

Әмма бу өлкәдә проблемалар шундый күп тупланган була ки, җәмәгатьчелек игътибарын шуларга юнәлтү, аларны хәл итү юлларын билгеләү өчен, махсус басма булдыру зарурлыгы килеп туа. Менә шул ихты-яҗларны канәгатьләндерү максатыннан, 1913 елның 21 февраленнән (яңа стиль белән 6 марттан) «Мәктәп» журналы чыгарыла башлый. Нәшире һәм мөхәррире Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров булган бу журнал тулысы белән укыту-тәрбия мәсьәләләренә багышлана. Ш.Әхмәров журнал тирәсенә татарның танылган әдипләрен, галимнәрен, күренекле

җәмәгать эшлеклеләрен, педагог-мөгаллимнәрен туплый. Тәҗрибәле мөгаллимнәр Ш.Бикколов, С.Кәмал, Г.Баттал, Н.Хуҗа, Р.Хәнәфи; русча-татарча мәктәпләрдә «учитель»ләр булып эшләгән М.Корбангалиев, Т.Мәхмүдев, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ф.Агиев һәм башкалар журналда үз мәкаләләре белән актив катнашалар. Авторлар арасында М.Акчурина, Ф.Сөләймания, М.Мозаффария кебек мөгаллимәләр дә була.

Әлбәттә инде, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Һ.Атласи, З.Вәлиди, Һ.Максуди кебек әдипләр, галимнәр дә «Мәктәп»не хуплап каршы ала, беренче саннарыннан ук аның белән хезмәттәшлек итә башлый.

Журналны оештыруда мәртәбәле дин галимнәре, мәдрәсә мөдәррисләре дә актив катнаша.

Журнал иң әүвәл киң җәмәгатьчелекнең игътибарын мәктәпләрдә фәннәрне заманча укытуга, укыту программаларын камилләштерүгә, мәктәп-мәдрәсәләр тарихын, сәнәгать һәм һөнәр мәктәпләре эшен яктыртуга һәм укыту-тәрбия эшенә кагылышлы башка бик күп проблемага юнәлтә, татар халкының тарихына, мәдәниятенә, диненә, иҗтимагый хәленә кагылышлы мәсьәләләрне күтәреп чыга.

Кызганыч, «Мәктәп» журналының нибары 25 саны гына чыгып кала. Әмма ул үзенең шул саннары белән дә татар мәгариф системасын тамырдан үзгәртеп кору юнәлешләрен күрсәтергә, алдынгы карашлы мөгаллимнәрнең, педагогларның, әдипләрнең фикерен киң катлам халыкка җиткерергә өлгерә.

«Мәктәп»нең башлангычы Россия империясенең башка төбәкләрендә яшәгән милләттәшләребез өчен дә яхшы үрнәк була. Шул ук 1913 елның октябрендә Оренбург шәһәрендә айга ике тапкыр татар телендә әдәби һәм фәнни-тәрбия журналы «Мөгаллим» чыга башлый (нәшире һәм мөхәррире — Х.Гали). Алардан соң дөнья күргән «Укытучы» (1918 елда Казанда чыккан айлык иҗтимагый-педагогик, әдәби журнал), «Мәгариф эшләре» (1920 елда Стәрлетамакта чыккан), «Мәгърифәт» газетасы (1925 елда Финляндиянең Кеми шәһәрендә нәшер ителә. Мөхәррире — Х.Хәмидулла), «Мәгариф эшчесе» (1926 елдан 1931 елга кадәр Мәскәүдә чыккан педагогик һәм психологик журнал), «Мәгариф җитәкчесе» (1927-1928 елларда Оренбургта нәшер ителгән педагогик һәм психологик журнал), «Мәгариф эшләре» (1928 елда Свердловскида чыга), «Уралда мәгариф» (1928-1931 елларда шунда ук басыла) һәм башка бик күп басмалар «Мәктәп» журналын үрнәк итеп алалар, үз төбәкләрендә татар мәгарифен, мәгърифәтен җайга салу өчен күп тырышлык куялар.

«Мәктәп» журналының беренче саннарыннан ук үз мәкаләләре белән актив катнашкан Галимҗан Ибраһимов «Мәгариф» дигән журнал чыгара башлый. Тик «Мәктәп»нең дәвамчысы булган «Мәгариф» тә озак яши алмый. Илдә барган гражданнар сугышы, икътисади таркаулык чорында мәгариф, укыту-тәрбия мәсьәләләре арткы планга күчә. Гражданнар сугышыннан соң, 1921 елның апреленнән журнал Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының айлык гыйльми-педагогик журналы буларак нәшер ителә. Аннан соң да журналның атамасы берничә тапкыр үзгәртелә. Ул төрле елларда «Башлангыч мәктәп», «Совет мәктәбе» исеме белән дөнья күрә. 1990 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр «Мәгариф» исеме белән чыгып килә.

Хәзер 10-12 мең тираж белән басылып, Татарстанда гына түгел, Россиянең татарлар күпләп яши торган утызга якын төбәгендә таралучы «Мәгариф» журналы да үзенең

элгәре булган «Мәктәп»нең, татар телендә чыккан башка педагогик журналларның матур традицияләрен дәвам итә, бүген илебез, республикабыз мәгариф системасы алдында торган мөһим бурычларны хәл итүдә үзеннән лаеклы өлеш кертергә омтыла. Журналның һәр санында мәктәп, гимназия, лицейларның укыту программаларындагы фәннәр буенча тәҗрибәле педагогларның дәрес үрнәкләре, алдынгы укытучыларның, тәрбиячеләрнең эш алымнарын күрсәткән язмалар, илебез, республикабыз мәгариф системасында булган яңалыклар биреп барыла. «Заман һәм мәгариф сәясәте», «Туган тел һәм әдәбият», «Мәктәпкәчә тәрбия», «Башлангыч мәктәп», «Гыйлем дөньясында», «Тәрбия һәм өстәмә белем» бүлекләренә, «Тел дәрьясы», «Русское слово» кушымталарына, сәхифәләргә яңалары өстәлә, темалар диапазоны колачлырак була бара.

Югары һәм махсус урта белем бирүче уку йортлары да игътибардан читтә калмый. Аларда булган яңалыклар, алдынгы эш алымнары шулай ук журнал битләрендә оператив чагылыш таба. Журналда укучыларның һәм студентларның сәламәтлеге, наркоманиягә каршы көрәш мәсьәләләре, тәрбиягә бала алган гаиләләрнең матур үрнәге һәм башка бик күп тема күтәрелә. «Мәгариф» укучыларыбызны төрле өлкәдә эшләүче танылган галимнәребезнең, әдипләребезнең ирешкән уңышлары, иҗат казанышлары белән дә даими таныштырып барырга тырыша.

Социаль һәм иҗтимагый әһәмияткә ия темалар һәрдаим журналның игътибар үзәгендә тора. Һәр санда «Мәгариф» дәүләт проектын тормышка ашыру буенча республикабыз мәктәпләрендә һәм барлык төр уку йортларында тупланган алдынгы тәҗрибәне яктыртуга киң урын бирелә, «ТР Дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында»гы Законны үтәү йөзеннән, журналда, татар һәм рус телләреннән тыш, чуваш, мари, мордва, удмурт телләрендә дә дәрес үрнәкләре басыла.

Халкыбызның классик язучысы, татар мәгарифен үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән Галимҗан Ибраһимов әле XX гасыр башында ук безгә үз кабыгыбызда гына бикләнеп ятмаска, Европага йөз белән борылырга кирәк, дип искәртә. Бездә чит илләрдә укуукыту проблемаларын өйрәнеп язылган материаллар, Болонья процессы таләпләрен тәфсилләп аңлаткан язмалар әледән-әле дөнья күрә. Журнал битләрендә инде күп еллардан бирле инглиз, француз, немец телләрендә дәрес үрнәкләре басыла.

Бернинди матбугат чарасы да бүгенге көн белән генә яши алмый. Алга карап, киләчәкне күздә тотып эш иткәндә генә, уңышка ирешергә мөмкин. Журналда студентлар өчен махсус сәхифә булдыруыбыз да шул максатлардан чыгып эшләнде. Анда студентлар тормышына, иҗатына багышланган язмалар урын ала.

Кыскасы, үткән гасыр башында дөньяга килеп, данлы юл үткән «Мәгариф» журналының бай мирасы, халкыбыз мәгърифәте һәм матбугаты тарихында тоткан лаеклы урыны бар. Шуңа күрә дә без бүген, журналыбыз узган олы юлны күздән кичереп, шагыйрьчә: «Без тарихта эзлебез», — дип горурланып әйтә алабыз. Бу хис безгә алга таба да дәртләнеп һәм рухланып эшләргә, иҗат итәргә көч бирә, куәт өсти. «Мәгариф» журналы киләчәктә дә яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә, республика мәгариф системасы алдында торган катлаулы да, мактаулы да бурычларны хәл итүдә алгы сафта булыр. Татар халкы булганда, татар теле яшәгәндә, иншаллаһ, «Мәгариф» тә яшәр. ■

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

ГАИЛӘ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ ТОТКАСЫ

ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ ӨЧЕН КӨРӘШНЕҢ ОЕШКАН ФОРМАСЫ, БИЛГЕЛЕ БУЛГАНЧА, 1908 ЕЛДА НЬЮ-ЙОРК ШӘҺӘРЕ ХАТЫН-КЫЗ СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТЛАР ОЕШМАСЫ ТАРАФЫННАН ИРЛӘР БЕЛӘН ТИГЕЗ ХОКУК ТАЛӘП ИТКӘН МИТИНГТАН БАШЛАНА. 1910 ЕЛДА КОММУНИСТ КЛАРА ЦЕТКИН II ИНТЕРНАЦИОНАЛНЫҢ VIII КОНГРЕССЫНДА ХАТЫН-КЫЗЛАР ПРОБЛЕМАЛАРЫНА ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕКНЕҢ ИГЪТИБАРЫН ЮНӘЛТҮ ӨЧЕН КӨН БИЛГЕЛӘҮ ТӘКЪДИМЕ БЕЛӘН ЧЫГА.

Нәтиҗәдә, күп кенә илләрдә аерым көннәр хатын-кыз оешмалары тарафыннан митинглар рәвешендә билгеләп үтелә башлый. Ирләр белән бертигез хокуклар өчен көрәш бигрәк тә 1910-1920 елларда киң яңгыраш таба. СССРда бу көнне 8 мартта билгеләп үтү гадәте урнаша. 1966 елда илдә 8 март ял һәм бәйрәм көне дип игълан ителә. Шулай итеп, хатын-кызларның тигез хокуклары өчен көрәш буларак башланган хәрәкәт тирән үзгәреш кичерә. Җир шарында исә 8 март, Берләшкән Милләтләр Оешмасының 1975 елда кабул ителгән карары нигезендә, Хатын-кызларның хокуклары өчен көрәш һәм халыкара тынычлык көне буларак билгеләп үтелә.

Бүген Россия Федерациясе парламентының Түбән палатасы булган Дәүләт Думасында хатын-кызлар барлык депутатларның 13,5 % (61 кеше), Югары палатасы булган Федерация Советында 6,7 % (11 вәкил), Татарстан Дәүләт советында 13% (13 хатын-кыз), Башкортстан Корылтаенда 6 % (7 депутат) тәшкил итә. Россия хөкүмәтендә бүген 2 хатын-кыз, 40 кешелек Башкортстан хөкүмәте вәкилләре арасында 7 хатын-кыз эшли, Татарстан Министрлар Кабинеты составында бер хатын-кыз да юк.

«Чын мирас» журналы редакциясе 8 март бәйрәме — Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан республикабызның күренекле шәхесләренә өч сорау белән мөрәҗәгать итте.

1. Әгәр дә Берләшкән Милләтләр Оешмасы карары нигезендә 8 мартны хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклары өчен көрәш көне дип билгели башласак, бу көнне Татарстанда һәм Россиядә, беренче чиратта, нинди социаль һәм сәяси мәсьәләләргә игътибар итәргә кирәк дип саныйсыз?

2. Соңгы елларда Россия хөкүмәте демография мәсьәләсенә махсус игътибар юнәлтте. Чөнки кеше ресурслары кимү дәүләтнең милли нигезләренә куркыныч янау дәрәҗәсенә җитте. Хөкүмәт тәкъдим итә торган чаралар арасында беренче урынны финанс ярдәме алып тора. Сезнең фикерегезчә, гаиләнең ныклыгын һәм балалар күпләп тууны гарантияли торган нинди кыйммәтләр әһәмиятле? Дәүләт тарафыннан бу юнәлештә, беренче чиратта, нинди карарлар кабул ителергә тиеш дип саныйсыз?

3. Сезнең гаиләдә 8 мартны бәйрәм итү традицияләре нинди?

ИЛДАРХАНОВА Флюра Әмир кызы, *социология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең «Гаилә һәм демография» фәнни тикшеренү үзәге җитәкчесе*

1,2. Беренчедән, миңа «көрәш», «хатын-кызларның хокуклары өчен көрәш» кебек сүзләр һич тә ошамый. Без инде бик күп еллар «Коммунистлар партиясе эше өчен», «Ленин эше өчен» көрәштек. Һәм нәрсәгә ирештек?

Чынбарлыкта хатын-кыз көрәшергә түгел, ә үзенә бирелгән хокуклардан түбәндәгеләргә нигезләнеп файдаланырга тиеш:

1) Үзенә табигать биргән сыйфатларга (хислелек, киң күңеллелек, нык рух, ана инстинкты).

2) Конституциягә (канун белән гарантияләнгән белемгә, сайлауларда катнашуга, үз һөнәре буенча үсүгә хокук һ.б.).

Мин 8 мартны бәйрәм итү традициясен туктатыр идем. Ул бәйрәм хәзер бүләкләр бирешүгә, бүләкләр алышуга гына кайтып калды. Ә менә Аналар көнен югары күтәрер идем. Бездә, кызганычка каршы, бу көн турында әле аз беләләр. Илебездә әле бу көн дәүләт бәйрәменә әверелмәде. Бу көн барлык әниләрне дә — кешегә тормыш, мәхәббәт, яхшылык бирүчеләрне — хөрмәтләү көне булсын иде. Ил күләмендә, милләт дәрәҗәсендә һәрбер кеше, үз әнисе алдында тез чүгеп, чәчәкләр бүләк итсен (бүләк түгел) һәм тормышта аларга китергән кыенлыклар өчен гафу үтенсен иде.

Икенчедән, ир-ат хатын-кызны хөрмәтләргә, сакларга һәм аңа юл куярга тиеш. Чөнки ул — көчле, миһербанлы, ул — яклаучы. Тормышның нигезе шундый.

Өченчедән, гаилә. Кешеләрдәге рухи көчнең символы булып гаилә тора. Бары тик сәламәт, югары әхлаклы, рухи яктан бердәм гаилә генә милләтне саклап кала ала. Мәгърифәтчебез Р.Фәхретдинов гаиләне милләтнең иң зур кыйммәте дип атаган.

Америка — символлар иле (флаг, кока-кола һ.б.).

Инаугурация вакытында АКШ Президенты Барак Обама үзенең гаиләсе янәшәсендә басып тора. Бу — гаилә тотрыклылыгы символы. Сайлаулар алдыннан ул үзенең әбисе янына бара — Ана кешегә хөрмәтен күрсәтә. Бөтен дөнья алдында инаугурация вакытында хатыны белән бии. Монысы да — хатын-кызга хөрмәт символы.

Дүртенчедән, балалар. Алар — тормышның иң кадерле рухи кыйммәте. Алар дөньяга мәхәббәт җимеше булып, Аллаһы Тәгалә кодрәте белән киләләр. Балаларыбызга якты һәм хөрмәтле мөнәсәбәт тәрбиянең нигезен тәшкил итә.

Безнең илдә хатын-кызлар, әниләр, гаилә, балалар көннәре бар. Барысы да дәүләт тарафыннан билгеләнгән. Бу көннәрдә якыннарны искә төшерәбез, мактыйбыз һәм... онытабыз. Ә бит бөтен ил күләмендә дәүләт ярдәме белән

әлеге кыйммәтләрне торгызу эше алып барылырга, бу өлкәдә дәүләт ярдәме зур булырга тиеш. Шул вакытта гына дәүләтнең уңай мөнәсәбәте күренәчәк.

3. 8 март көнне без бөтен гаилә белән — балалар, оныклар — безнең өйдә җыелабыз. Бу очрашу безнең гаиләнең традициясе. Бүләкне фәкать ир-атлар гына бирә: ир, эти кеше, бабай. Илдус Гәрәй улы бүләк сайлауга бик иҗади һәм уйланып якын килә. Һәм бүләк кешенең характерын, кызыксыну өлкәсен, теләкләрен исәпкә алып сайлана. Аннары без таба ризыклары белән сыйланып, чәй эчәбез.

ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗан кызы,
«Казан Кремле» тарихи-архитектура һәм сәнгать дәүләт музей-тыюлыгы директоры, фәлсәфә фәннәре кандидаты

1. Быел хатын-кызлар хәрәкәте өчен зур юбилей, түгәрәк дата: Россиядә беренче тапкыр 8 мартны хатын-кызлар көне буларак бәйрәм итүгә 100 ел тула. Узган гасырларда хатын-кызларың ирләр белән тигез хокукы өчен көрәш демократик күтәрелешнең бер өлеше булган. Димәк, хатын-кызлар азатлыгы — социаль һәм сәяси инкыйлабның бер чагылышы. Җәмгыятьтәге тәрәккыят тә, икътисади үсеш тә хатын-кызларның актив катнашуыннан башка мөмкин түгел. Төрле катлаулы проблемаларны чишкәндә, хатын-кызларның үзенчәлекле карашы, кешелеклелек һәм шәфкатьлелек критерийлары читтә кала алмый. Чөнки хатын-кызлар куйган таләпләр аларның үзләренә түгел, ә бөтен җәмгыятькә кирәк булган шартлар тудыруны күз алдында тота. Баланы дөньяга китерүче, тәрбияләүче шәхес җәмгыять өченниләр мөһим булуын яхшы белә дип уйлыйм.

Бүгенге Россиядә һәм Татарстанда хатын-кызлар әһәмиятле роль уйный дип саныйм. Сәясәттә, социаль тармакларда, эшкуарлыкта, мәдәният-сәнгатьтә хатын-кызның тоткан урыны бик зур. Татарстан хакимиятендә һәрвакыт хатын-кызлар күренекле урынны тотты. Кайчакта хатын-кыз министрлар саны белән мактана алмасак та, зур оешмаларда җитәкче вазифалар башкаручылар, министрлыкларда урынбасар, аерым идарә, бүлек җитәкчеләре сыйфатында хәлиткеч өлеш кертүчеләр аз түгел. Зур әзерлек һәм сабырлык таләп иткән иң мөһим вазифаларны, агымдагы четерекле һәм «кара» эшне ханымнар, апалар, туташлар башкара. Республикада эшләүче федераль структура җитәкчеләре арасында алар шактый. Мәдәният-сәнгать, мәгариф тармакларын әйтеп тә торасы юк. Хатын-кызлар җигелеп тарта! Шуның өстәвенә социаль функция, гаилә, балалар тәрбияләү… Бу миссия зур әзерлек, тырышлык, энергия таләп итә. Менә шуларны аңлау, кирәкле чакта аңлату өчен кирәктер әлеге матур бәйрәм.

Министрлар, депутатлар арасында хатын-кызларны арттыру файдалы, әлбәттә. Әйтәсе килгән фикерем шул: эш берничә хатын-кызны түр башына утыртып куюда, президиумны бизәүдә генә түгел. Безнең республикада иң четерекле, шактый авыр катлаулы

вазифалар — район администрациясе башлыгы урынбасарлары, Башкарма комитетның төп бүлек һәм идарәләрен хатын-кызлар тарта.

Әйтергә кирәк, ана булу, бала табып үстерү, гаилә тормышы, иҗтимагый эшләр, аз бюджетлы гуманитар оешмаларда көч кую — болар барысы да чамадан тыш көч һәм вакытны алып тора.

Иң беренче чиратта, табиблар, шәфкать туташлары, укытучылар, китапханәчеләр, радио, телевидение, газета-журнал редакцияләрендә, идарә аппаратында эшләүчеләр, сәнгать әһелләре, клубларда, көнкүреш хезмәтендә, сәүдә тармагында хезмәт куючылар арасында күбрәк хатын-кызлар очрый. Алар эшләгән тармакларга игътибар, акча чыгымнары, алдынгы технологияләр күбрәк бирелү — гомумән, көчле социаль сәясәт алып бару дигән сүз. Бу исә шунда ук икътисади һәм сәяси тәрәккыяткә китерә. Безнең «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы җәмгыятьтә шушы балансны булдыру өчен күп көч куя. Аның тарихы, шушы оешмада эшләгән еллар, уникаль «Азат хатын» — «Сөембикә» журналы, хатын-кызлар хәрәкәте ветераннары, билгеле һәм булдыклы ханымнар минем өчен бик газиз, күңелгә якын. Без үткәргән чараларда булдыклы ирләрнең кешелекле гамәлләре дә зурлана, иң фидакарь ханымнар лаеклы бәя ала. Республикада кабул ителә торган мөһим карарларга, федераль программаларга хатын-кызлар тәкъдим иткән гамәлләр кертелсен өчен алып барылган эш күзгә ташланып тормаса да, нәкъ менә алар иң мөһим юнәлеш дип уйлыйм.

2. Демографик вазгыятьнең катлаулануы очраклы хәл түгел. Сәбәпләре дә мәгълүм. Илдәге икътисади торыш, урбанизация, тормыш стандартларының үсеп, таләпчәнләнеп китүе, чыгымнарның артуы бер баланы үстерүнең күпмегә төшкәнен яхшы аңлатып тора. Элекке чорлардагы 7-10 балалы гаиләләр хәзер юк инде. Һәр йортта 3-4 баланың сабый килеш дөньядан китүе дә күзәтелми хәзер. Дәвалауга күбрәк игътибар бирелә.

Ана капиталын өләшү балалар саны артуга уңай тәэсир ясады. Федераль үзәкнең мондый стимулы яхшы нәтиҗәгә китерде. Ләкин акча белән генә тотрыклы демографик вазгыять тудырып булмый. Бала үстерү таләп иткән игътибар, көч һәм чыгымнар 300-400 мең сумлык кына түгел шул. Беренче чиратта, социаль катламнар арасындагы аерма артык зураймасын өчен, чаралар күрелергә тиеш. Россиядәге тотрыклылык шуңа бәйләнгән. Базар икътисады байлар катламын китереп чыгарды. Ләкин бу катлам сан ягыннан артык зур түгел. Ә демографик вазгыять, балаларның күбрәк тууы, матур итеп үсүе урта хәлле һәм аннан түбәнрәк керемле гаиләләрдән тора. Монда химаячелек тә, социаль сәясәт тә зур тәэсир ясый ала.

Демографиягә, гаиләгә тәэсир иткән гаять зур эшләрнең асылы күптән билгеле. Россия Федерациясе хакимияте, республикабыз җитәкчелеге социаль инфраструктураны үстерү юнәлешен эзлекле алып барырга тиеш. Республикабызның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә, хәзерге Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та шушы социаль аспектка бик зур игътибар бирә. Икътисадны үстерү өчен, инновацион чаралар күрү җиңел түгел. Ләкин җитештерү арбасы тәгәрмәчләре, бигрәк тә авыл җирендә, эш хакларын да, социаль ярдәмне дә тартып барырга тиеш, гуманитар һәм социаль тармакларны үстерүне һич кичектереп булмый. Татарстан җитәкчелегенең менә шуны аңлавы мөһим.

Бүгенге тормышта социаль сәясәт, гаиләләргә гомуми таяныч булу һәм конкрет ярдәм күрсәтелү демографиягә тәэсир итәргә тиеш. Бу нәкъ шулай

килеп чыга да. Соңгы елларда Татарстанда, Казанда балалар тууның артуы, үлем-китемнең кимүе, гомер озынлыгының арта башлавы демографик «көянтәнең» уңай якка авышуына китерде. Бу тенденция шулай дәвам итсен өчен, башкарасы эшләр бихисап.

3. Безнең гаиләдә 8 март бәйрәме Яңа ел кебек каршылана. Гадәттә, 8 март алдыннан үтә торган рәсми мәшәкатьләрдән котылгач, өйдә оныклар, якын кардәшләр белән мәҗлес корабыз. Тәм-томнар, кечкенә бүләкләр, оныкларның «иҗади» хисаплары. Нәкъ 7 мартта тормыш иптәшемнең туган көне булу да шуңа кушылып китә, үзе әйтмешли, нурга «күмелеп кала».

Менә шундый матур язгы бәйрәм барыгызны да бер генә көнгә булса да нурга күмсен иде! «Чын мирас» журналы укучыларын, бигрәк тә рухи тормышка җан кертүче хатын-кызларны бәйрәмебез белән котлыйм!

ЮНЫСОВА Ләйсән Рәфикъ кызы,
шагыйрә, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире

1. Тигез хокуклылык турында сүз кузгатабыз икән, беренче нәүбәттә, әлбәттә, шуңа игътибар итәргә мәҗбүр булачакбыз: хатын-кызларның һәм ирләрнең хокуклары әлегә чын тигезлектән ерак. Гасыр буена барган көрәш хатын-кызларның мөмкинлекләрен арттыру белән беррәттән, яңа эш кыры булдырды, өстәмә җаваплылык йөкләде. Әни, ир хатыны, хуҗабикә булу өстенә, ул хәзер эш кешесе. Ир кешеләр исә үзләренә яңа функцияләр алмады, киресенчә, аларның роле — акча табу, гаиләсенең иминлеген саклау, балаларга ата тәрбиясе бирү, киләчәген кайгырту — кимеде генә. Моңа кадәр ата җилкәсендә генә булган җаваплылыкның бер өлешен җәмгыять үз өстенә алса, икенче өлешен ирләр хатыннары белән бүлеште. Һәрьяктан да булдыклы булырга өйрәнгән хатын-кызлар барысына да өлгерергә тырыша һәм күп очракта хокук биргән мөмкинлекләрдән дә баш тартырга мәҗбүр. Мәсәлән, сәясәттә катнашудан. Ата-ана җыелышларын бик өнәп бетерми торган ир-атларыбыз парламент җыелышларында күпчелекне тәшкил итә. Гәрчә Дәүләт Думасында, Татарстан парламентында ир һәм хатын-кыз делегатлар арасында сан ягыннан тигезлек урнашса, ягъни тавыш бирүдә ике җенеснең дә вәкилләре бертигез катнашса, күп кенә проблемаларга караш башка булыр иде. Табигате буенча ир кеше — яулаучы, ә хатын-кыз яклаучы бит, шуңа күрә яклауга мохтаҗ даирәләргә (ә алар бездә, кызганычка каршы, әле җитәрлек) ярдәм күрсәтү, хатын-кыз нечкәлеген, зирәклеген таләп иткән четерекле мәсьәләләрне (гаилә, бала үстерү проблемалары) чишүгә юнәлтелгән законнарны кабул итүдә хатын-кызларның катнашы бик тә мөһим. Инвалидлар, ятимнәр, пенсионерлар, җәберләнгән балалар һәм хатыннар белән эшли торган җәмәгать оешмаларын алыгыз — барысында да даими риясыз хезмәтне хатын-кызлар башкара. Ир-атлар, гадәттә, бу игелеккле эштә вакыт-вакыт спонсор ярдәме күрсәтеп кенә «күренеп» ала.

Әйткәнемчә, мәшәкате баштан аш-

кан хатын-кызларның күбесе сәяси, җәмгыяви аренага чыгарга ашкынмый, югары постларга да омтылмый. Ә бит бик булдыклы хатыннар бар — аларга юл гына бирәсе! Тарихында Сөембикә ханбикәсе булган Татарстанда министр булырлык бер ханым да юкмыни? Җаваплы эшләрне бик теләп һәм өеп тапшыралар, әмма түр башында ир-ат утыра (район башлыклары арасында берсе генә хатын-кыз, ә мең мәшәкатьле кара эшне башкаручы урынбасарлар — безнең кавемнән). Җитәкче урынын биләгән ханымнардан еш кына шундыйрак зар ишетәбез: «Ирләр белән бер дәрәҗәдә саналыр өчен, безгә өч тапкыр күбрәк көч куярга, ике карышка шәбрәк булырга кирәк». Гендер проблемалары бер бездә генә түгел. Гөмбәз биек һәм ачык кебек күренсә дә, хатын-кызны өскә җибәрми торган «пыяла түшәм» теориясе дә киң таралган. Әмма татарда эштә үрләр яулаучы ханымнарга кимсетебрәк, ә кайчак «ярар, йөргән булсын инде безгә иш булып», дип мыскыллабрак карау бигрәк нык сизелә. Уңышка ирешкән хатыннар артында һаман берәр ир кеше тормыймы дип күзлиләр: үзе булдыргандыр, димиләр, бу кемнеңдер сөяркәсе түгелме, диләр.

Әйе, гаиләдә безнең урын түрдән: аналарны хөрмәтлиләр, хатыннарны кадерлиләр, кызларны иркәлиләр. Әмма гаиләдән тыш хатын-кызга кадер кими: шул ук эшне башкарса да, кимрәк акча ала, үсеш ягыннан да ирләргә һәрчак өстенлек бирелә: пүчтәк булса булсын, ир затыннан гына булсын, ә акыллы хатын, муен булып, аны, кешегә сиздерми генә, кирәкле якка борып утырсын... Шулай итеп, хокук тигезлеге ягыннан безгә әле Американы да, Европаны да куып җитәсебез бар.

2. Бүген илебездә демография мәсьәләсенә, чыннан да, зур игътибар бирелә. Гаилә ныклыгы турында сөйләгәндә, иң элек, без балаларны күз алдында тотабыз. Баласыз гаилә — ул канатсыз, тәрәксез, киләчәксез гаилә. Хөкүмәтебезнең шуны истә тотып кабул иткән карарлары, шул исәптән гаиләгә зур матди ярдәм булырдай Ана капиталы илдә демографик хәлне уңай якка үзгәртүгә шактый этәргеч бирде. Ләкин бүгенге вазгыятьне Ана капиталы гына хәл итә алмый. Элек хатын-кызның сайлау мөмкинлеге булмаган — Ходай ничә бала бирсә, барысын да тапкан. Бүген яшь гаиләнең «без бала үстерергә әзерме-юкмы», дип уйланырга мөмкинлеге бар. Бу сорауга күпчелеге «юк әле», дип җавап бирә: тотрыклылык юк, акча юк, фатир юк. Гаилә корып җибәргән яшь парларның күбесенең сыеныр почмагы, яшәү урыны юк бит. Хезмәт хакы уртачадан түбән ир белән хатында бала кайгысы булмый. Гаилә ныклыгы — ул, иң әүвәле, фатир мәсьәләсен хәл итүгә кайтып кала. Минемчә, яшьләрнең барысына да фатирны (аның кайда эшләвенә карамастан) социаль ипотека буенча бирү җаен карарга кирәк.

Аннары, икенче баласын тапкан әниләр турында кайгыртабыз кайгыртуын. Шул ук вакытта күпбалалы гаиләләр хәле игътибар үзәгеннән читтә кала бирә. Мондый гаиләләргә пособие-ташламалар юк дәрәҗәсендә. Баланы тормыш куйган бөтен мөмкинлекләрдән файдаланып үстерү әти-әни өчен җитди проблемага әверелә. Ә бит, иң беренче чиратта, без әнә шул гаиләләрнең мәнфәгатен кайгыртырга, аларга ярдәм кулы сузарга тиеш. Башкалар аларга «хәерче үрчетәләр» дип түгел, ә бәлки кызыгып карарлык булсын. Хөкүмәтебез мәсьәләнең бу ягына аеруча зур игътибар бирергә тиеш дип саныйм.

3. 8 мартмы? Безнең гаиләдә мин аның зур бәйрәм икәнен бала чактан белеп, аңлап, көтеп үстем. Беренчедән, ул көн яраткан әбиемнең туган көне иде. Димәк, бүләк әзерләү хәстәре, күңелле мәшәкатьләр үзеннән-үзе

бәхетле ыгы-зыгы алып килә торган иде. Бәләкәй булсам да, үзем дә хатын-кыз бит әле мин. Мин дә бүләк көтәм. Алам да. Без үскәндә, иң затлы чәчәк лалә чәчәге иде. Роза гөле кебек затлы чәчәкләр — минем яраткан чәчәкләрем — кышын соңрак кына кибетләрдә күренде. Ә безнең өйгә бәйрәм исен мимозалар алып килә иде. Чынында мимоза әрем икән бит ул. Хатын-кыз шулай инде ул, әллә тормыш шулаймы: аның дөньясына шатлык-куаныч гөлләре-әремнәре белән килеп керә. Ә, гомумән, без хатын-кызларга Яз бәйрәме бүләк иткән өчен, егерменче гасыр башындагы актив затларга, Клара Цеткинга бик рәхмәтле мин.

ЙОСЫПОВ Рифкать Рәшит улы,
тарих фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты ректоры

1. Язның бу матур бәйрәме үзенең тарихы белән бик тирәнгә, борынгы Рим гореф-гадәтләренә үк барып тоташа. Элек-электән үк язгы бәйрәмнәрнең хуҗасы булып гайрәтле Юпитерның хатыны — зур хакимияткә ия данлы алиһә Юнона саналган. Римлылар аңа кешеләргә яхшы табигать шартлары, иген уңышы, эштә уңыш китерүче алиһә буларак табынганнар, ләкин барыннан да бигрәк борынгы римлылар һәммә хатын-кызларның яклаучысы булган Луцияне («якты») хөрмәт иткәннәр. Аңа һәр йортта, гаиләдә хөрмәт зур булган, никахлашканда һәм бала тугач, бүләкләр «биргәннәр». Борынгы чорда да март ае якты һәм куанычлы вакыт булган: шәһәр халкы бизәнгән, бәйрәмчә киенгән хатын-кызлар Юнона храмына чәчәк бәйләмнәрен алып килгән, дога кылган, алиһәдән үз гаиләләрендә бәхет булуын сораган. Шуны да әйтеп китү мөһим: әлеге заманнардан ук ирләр март аенда хатыннарына бүләкләр биргән, хәтта кол хатыннарын да игътибардан читтә калдырмаган.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының 8 мартны — Хатын-кызларның халыкара бердәмлеге көнен — аларның хокуклары өчен көрәшү көне итеп билгеләвенә килгәндә, минемчә, чыннан да, бүген чишелеп бетмәгән мәсьәләләр бар. Беренче чиратта, инде гадәти күренешкә әверелгән, хатын-кыз җилкәсендә күтәреп булмаслык вазифалар йөкләүне туктатырга кирәк. Үзенең төп вазифасыннан — ана булу, гаилә учагын тергезү һәм саклаудан тыш, ул гаиләнең матди хәлен төп тәэмин итүчегә әверелде. Бүген инде чиста ир-ат хезмәте, физик эшләрдә хатын-кызлар булуы беркемне дә гаҗәпләндерми. Шуңа бәйле рәвештә, минем уемча, җәмгыятьтә хатын-кызга булган мөнәсәбәтне кискен үзгәртергә кирәк.

Бу өлкәдә эшне төрле юнәлештә башкарырга мөмкин: иң элек уңай эш шартлары тудыру, мөмкин кадәр хезмәт хакын арттыру, хатын-кызны социаль яклау. Берәүгә дә сер түгел: зур мәшәкатьләр аркасында хатын-кызның үзен, сәламәтлеген кайгыртырга вакыты да калмый.

Ләкин мин, ир-ат буларак, шуны ассызыклап үтәсем килә: хатын-кыз һәрвакыт хатын-кыз булып калыр-

га, үз асылын югалтмаска тиеш. Ул һәрвакыт сизгер, нәзакәтле, нечкә күңелле, сылу, күңелне җилкендерүче һәм йөрәкне дулкынландыручы булып калсын иде!

Нәкъ менә хатын-кыз ир-атка үзен көчле, гайрәтле итеп тоярга мөмкинек бирә, аны яклау, саклау һәм ярату теләге уята. Шуңа күрә бүген 8 март бәйрәмен яз, яктылык, чәчәкләр, җылылык бәйрәме буларак кабул итү нәкъ менә хатын-кызның төп вазифасы — ана, хатын, тормыш юлдашы булуын искәртергә тиеш.

2. Соңгы елларда Россия Федерациясе хөкүмәте демографик мәсьәләләрне чишүдә кабул иткән чаралар, әлбәттә, бик заманча һәм әһәмиятле. Бүген яшь гаилә матди яктан тәэмин ителмәгән очракта, үз баласына тиешлечә белем һәм тәрбия бирә алмас иде, мөгаен. Бәлки, шуңа күрә дә илебез XX гасырның соңгы 10 елында демографик фаҗигага халәтенә керде.

Шул ук вакытта дәүләтебезнең милли нигезен ныгыту өчен, күп кенә чишелмәгән мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. Һәр җәмгыятьнең төп бурычы — милләтнең киләчәге турында кайгырту, ягъни үсеп килүче яшь буынның сәламәтлеген саклау, аны физик һәм рухи-әхлакый сәламәт итеп тәрбияләү. Моңа бәйле рәвештә, балаларыбызның киләчәген ышанып тапшыра торган кешеләр турында кайгыртуны арттырырга кирәк. Сүз, беренче чиратта, медицина белгечләре, мәктәпкәчә учреждение хезмәткәрләре, мәктәп һәм мәктәптән тыш сәнгать үзәге, спорт бүлеге укытучылары кебек балаларыбызны мәгърифәтле, һәрьяктан үскән, гармонияле шәхес итеп тәрбияләүчеләр турында бара.

Һәр кеше тормышының нигезе гаилә икәнен дә онытырга ярамый. Чөнки нәкъ менә гаиләдә балага шәхес сыйфатлары салына. Кызганычка каршы, XX гасырның фаҗигале вакыйгалары һәр халыкның диярлек борынгы гореф-гадәтләрен юкка чыгарды дисәк, ялгыш булмас. Бүген иң мөһим бурыч: гаилә кыйммәтләрен алгы планга куйган идеологияне яңарту, буыннарның дәвамлылыгын, гореф-гадәтләрнең кайтарылуын тәэмин итү сорала. Әйтеп үтелгәннәрнең барысы да гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызның тоткан мөһим урыны турында кабат сөйләргә мәҗбүр итә. Ана балада рухи кыйммәтләр дөньясын, җәмгыятькә мөнәсәбәт тәрбияли, аның үсеш юлларын билгели. Бу вазифаларны уңышлы башкаруда хатын-кызның ана булырга әзерлеге, җәмгыятьнең, дәүләтнең, якыннарының ярдәмен тою дәрәҗәсе бик мөһим урын алып тора. Шуңа күрә гаилә хокукын камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар турында уйларга вакыт җитте. Хокук өлкәсендә әлеге җаваплы эшне башкаруда иң яхшы сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләренең, хокук белгечләренең актив эшчәнлеге сорала.

3. Үземнең гаиләдә 8 март бәйрәмен үткәрүгә бәйле ниндидер традиция бар дип әйтә алмыйм. Бу көн, минем уеча, һәр гаиләдә бер үк канунга буйсындырылган — хатын-кызга үзен алиһә итеп тою мөмкинлеге бирү, аңа мөмкин кадәр җылылык, куаныч, елмаю һәм бәхет бүләк итү. Һәр гаиләдә шулай булуын телим, ләкин, кызганычка каршы, көндәлек мәшәкатьләргә батып, барлык теләк-омтылышларыбыз да чынга ашып бетми шул. Ир-атларга әйтәсе килгән бердәнбер теләк: үз якыннарыгызны, туганнарыгызны, сөйгән ярларыгызны игътибарсыз калдырмагыз, чәчәкләр бүләк итегез, мәхәббәтегездән мәхрүм итмәгез.

Форсаттан файдаланып, гаиләмдәге яраткан хатын-кызларны, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты хезмәткәрләрен әлеге гүзәл, якты, җылы яз бәйрәме белән котлыйм!

Илдус Заһидуллин
һәм ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

ГАИЛӘ – МИЛЛӘТНЕҢ НИГЕЗЕ ЯКИ ТАТАР ГАИЛӘСЕНДӘ БАЛА ТУУГА МӨНӘСӘБӘТ

ГҮЗӘЛ ГАЛИЕВА,
социология фәннәре кандидаты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ХӘЗЕРГЕ ДЕМОГРАФИК ВАЗГЫЯТЬНЕ КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК ДИП БӘЯЛӘРГӘ МӨМКИН. 2007 ЕЛНЫҢ 1 ГЫЙНВАРЫННАН «БАЛАЛАРЫ БУЛГАН ГАИЛӘЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕНЕҢ ӨСТӘМӘ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА»ГЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОН ҺӘМ ИКЕНЧЕ БАЛАНЫ ТАПКАН ГАИЛӘЛӘРГӘ АНА КАПИТАЛЫ СЕРТИФИКАТЫ ТАПШЫРУ ТУРЫНДАГЫ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КАРАРЫ ГАМӘЛГӘ КЕРҮ, ӨЧ ҺӘМ АННАН ДА КҮБРӘК БАЛАСЫ БУЛГАН ГАИЛӘЛӘРГӘ КҮПБАЛАЛЫ СТАТУСЫН БИРҮ УҢАЙ ВАКЫЙГА БУЛДЫ. 2012 ЕЛНЫҢ 1 ГЫЙНВАРЫННАН ӨЧЕНЧЕ БАЛА ТУГАН ГАИЛӘЛӘРГӘ ТОРАК САЛУ ЯКИ ШӘХСИ ХУҖАЛЫК ЭШЛӘРЕ АЛЫП БАРЫР ӨЧЕН БУШЛАЙ ҖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕ БИРЕЛӘ БАШЛАДЫ. СОЦИАЛЬ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫНЫҢ УҢЫШЛЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛУЫ ТАТАРСТАНДА КҮЗӘТЕЛГӘН ДЕМОГРАФИК ҮСЕШТӘ ДӘ ЧАГЫЛЫШ ТАПТЫ.

2010 елда, Татарстан дәүләт гражданлык халәте актларын теркәү хезмәте мәгълүматларына караганда, 49 512 бала дөньяга килгән, 2009 елга караганда, 2 369 балага күбрәк. 1992 елдан соң, бары тик 2011 елда гына республикада халыкның табигый үсеше күзәтелә башлый һәм 2012 елда туучылар үлүчеләрдән 9 426 кешегә артып китә (56 005 бала туа).

Болары — республика буенча күрсәткечләр. Ә татар гаиләсенең репродуктив максаты һәм халәте нинди? Бу мәкаләдә, 2008-2009 еллардагы тикшерү нәтиҗәләренә нигезләнеп, без шушы сорауга җавап бирәбез [1].

Репродуктив максатны без «Гаиләдә барлыгы ничә бала булу яхшы?» (идеаль сан), «Барлык зарури шартлар үтәлгәндә, сез ничә балагыз булуын теләр идегез?» (теләгән сан), «Сез ничә бала табарга җыенасыз?» (көтелгән сан) кебек сораулар ярдәмендә ачыкладык [2].

Сораштыру нәтиҗәләре буенча, татар гаиләләре идеаль сан дип ике баланы саный (60,4%). Бу сорауга җавап кешеләрнең, бернинди тормыш халәтен һәм шәхси мәнфәгатьләрне исәпкә алмыйча, үзләре өчен иң кулай балалар саны турындагы күзаллавын бирә.

Респондентларның (ата-аналарның) гаиләдәге балаларның идеаль саны турында җаваплары

Гаиләдә барлыгы ничә бала булуы яхшы (идеаль сан)	%
Бер бала	3,7
Ике бала	60,4
Өч бала	27,6
Дүрт һәм аннан да күбрәк	5,9
Әйтергә кыенсынам	2,2
Барлыгы	100,0

Мәктәп укучылары да балаларның идеаль саны турында шундый ук фикердә тора (59,1% — татар, 52,1% — рус). Мәктәп балаларын сораштыруда кызыклы тенденция күзәтелә: татар балаларында икенче урында өч балалы гаилә булса (17,9%), русларда — бер балалы (17,6%). Бу киләчәктә татар халкының сан ягыннан үсәчәге турында оптимистик прогноз ясарга нигез бирә.

Яшьләребезнең репродуктив максаты турындагы тикшеренүләргә караганда, татарлар урта санда (ике) һәм күпбалалылыкка (өч һәм аннан да күбрәк) йөз тота.

Мәктәп яшендәге рус һәм татар укучыларының гаиләдә баланың идеаль саны турындагы җаваплары

Гаиләдә ничә бала булуы яхшы?	Рус	Татар
Өч	9	17,9
Дүрт һәм аннан да күбрәк	4,8	3,5
Мин әле бу турыда уйламадым	8,5	7,4
Әйтергә кыенсынам	6,9	5,1
Җәмгысе	100	100
Берәү дә	1,1	0,4
Бер	17,6	6,6
Ике	52,1	59,1
Өч	9	17,9
Дүрт һәм аннан да күбрәк	4,8	3,5
Мин әле бу турыда уйламадым	8,5	7,4
Әйтергә кыенсынам	6,9	5,1
Җәмгысе	100	100

Мәктәп укучыларының һәм студентларның идеаль бала саны турындагы фикерләре бөтенләй тәңгәл килми. Ике балага бер үк сандагы студентлар һәм мәктәп балалары йөз тота (56,2%ка — 59,1%). Әмма татар студентларының өч бала турында хыялланулары (30,9%) мәктәп балаларыныкыннан (17,9%) 2 тапкырга югарырак. Бер бала турында уйлаучы студентлар (4,8%) мәктәп укучыларыннан (6,6%) азрак.

Татар гаиләсенең репродуктив максаты гомумроссия күрсәткечләренә караганда шактый югары. Барлык тикшеренүләрдә дә россиялеләрнең яшенә, җенесенә, гыйлем дәрәҗәсенә һәм матди халәтенә карамастан, гаилә эталоны булып ике бала саналуы күренә. Мондый гаилә тибын респондентларның яртысыннан артыгы өстен күрә (54% — рус, 60,4% — татар). Икенче урынны өч бала алып тора (23% — рус, 27,8% — татар), бер бала булуын 12% Россиядә һәм 3,7% Татарстанда яшәүче респондент өстен күрә. Шулай ук өч һәм аннан да күбрәк бала булуын республикабызда яшәүче 9% гаилә, Россиядә яшәүче 5,9% гаиләләр тели.

«Теләгән» бала саны — индивидның шәхси теләгеннән чыгып, әмма төгәл яшәү шартларын һәм шәхси тормыш юлын исәпкә алмыйча, үз гаиләсендә булдырырга теләгән бала саны. Бу күрсәткеч респондентларның репродуктив мәнфәгатьләре турында төгәлрәк бәяләмә бирә.

Сораштырылган татар студентларының күбесе (55,8%) гаиләдә ике бала булуын яхшы дип саный, 30,1% респондент — өч бала, 5,2% — бер, 4% дүрт һәм аннан да күбрәк бала булуын тели.

Идеаль сандагы кебек үк, күпчелек татар гаиләләре — ике бала (55,8%), икенче урында өч бала (30,8%) тели. Өченче урында бу күрсәткеч (4,6%) тигез бүленгән, ягъни кайбер респондентлар бер бала тели, ә кайберләре — дүрт һәм аннан да күбрәк.

Татар гаиләсендәге мәктәп балаларының, студентларның һәм ата-аналарның идеаль бала саны турындагы фикерләре

Гаиләдә ничә бала булуы яхшы?	Мәктәп балалары	Студентлар	Ата-аналар
Берәү дә	0,4	–	–
Бер	6,6	4,8	3,7
Ике	59,1	56,2	60,4
Өч	3,5	30,9	27,8
Дүрт һәм аннан да күбрәк	7,4	3,3	5,9
Мин әлегә бу турыда уйламадым	–	–	–
Әйтергә кыенсынам	5,1	4,8	2,2
Барлыгы	100	100	100

Гаиләнең матди хәленә мөнәсәбәтле татар студентларының теләгән бала саны

Төрле матди хәләттә Сез ничә бала булуын теләр идегез?	Без көчкә көнне-көнгә ялгап барабыз, акча хәттә азык-төлеккә дә җитми.	Азык-төлеккә акча җитә, әмма кием-салым сатып алу финанс кыенлыкларын тудыра.	Акча азык-төлеккә һәм кием-салымга җитә, әмма озак кулланылыштагы әйберләрне сатып алу безнең өчен мөмкин түгел.	Без берниндИ мәшәкатьсез озак кулланылышта булган әйберләрне сатып ала алабыз, әмма кыйммәтле әйберләрне сатып алу шактый кыен.	Без фатир, дача кебек кыйммәтле әйберләрне сатып ала алабыз.	Җавап бирергә кыенсынам	Нәтиҗә
Бер		14,3		5,5		18,8	5,2
Ике	100	71,4	59,5	55,2	50	50	55,8
Өч		14,3	33,3	30,7	35	18,8	30,1
Өчтән күбрәк			4,8	3,1	10	6,3	4,0
Балалар булуын теләмим				0,6			0,4
Бу турыда уйлаганым юк				3,1		6,3	2,4
Әйтергә кыенсынам			2,4	1,8	5		
Нәтиҗә	100	100	100	100	100	100	100

Күрүебезчә, бу репродуктив максат депопуляциядән котылуда гаиләләрдә бала тудыруның галимнәр исәпләгән эффектив санынннан ерак. Шулай да татар гаиләсе нигезенә җәмгыятьтәге демографик проблемаларны, һичшиксез, хәл итәрдәй күбрәк бала алып кайту теләге салынган.

Татар һәм рус студентлары ике бала булуын тели, әмма беренчеләрендә күпбалалылыкка омтылу теләге өчтән бер өлешкә күбрәк (татарларда — 30,1%, русларда — 19%) һәм бер балалылыкка ике тапкыр кимрәк (татарларда — 5,2 %, русларда — 9,8%).

Рус һәм татар студентларының теләгән балалар саны турындагы чагыштырма җаваплары

Теләгән балалар саны	Руслар	Татарлар
Бер бала	9,8%	5,2%
Ике бала	55,7%	55,8%
Өч бала	19%	30,1%
Дүрт һәм аннан да күбрәк	5,2%	4%
Балалар булуын теләмим	2,3%	0,4%
Бу турыда уйламыйм	5,2%	2,4%
Әйтергә кыенсынам	2,8%	2,1%
Җәмгысе	100%	100%

«Көтелгән» балалар саны — гаиләнең репродуктив чоры азагына кадәр планлаштырылган балалар хисабы. Бу төгәлрәк күрсәткеч, әмма реаль тормышта ул чынбарлыктагы күрсәткеч белән тәңгәл килми. Р.И.Зиннуров, Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендәге (Татарстан Республикасы, Удмуртия Республикасы һәм Түбән Новгород өлкәсе) хатын-кызларның репродуктив халәтен өйрәнеп, көтелгән балалар санының теләгән балалар санына якын икәнлеген ачыклады [3].

Безнең татар гаиләләрен тикшерүебез Р.И.Зиннуров нәтиҗәләрен өлешчә раслый. Күпчелек татар респондентлары (53%) өчен беренче урында теләгән һәм көтелгән балалар саны — ике. Төрле шартларда респондентларның 31,5% — өч бала, 10,3% дүрт һәм аннан да күбрәк бала булуын тели. Әмма көтелгән балалар саны теләгән балалар санынннан шактый ким. Шулай итеп, 22,4% респондент бер бала булдырырга җыена, бары тик 8,3% өч бала тудырырга теләк белдерә һәм 3,6 % — өч һәм аннан да күбрәк.

Ата-аналарның телəгəн һəм көтелгəн балалар саны турындагы җавабы

Балалар саны	Телəгəн	Көтелгəн
Бер бала	5,2	22,4
Ике бала	53	53
Өч бала	31,5	8,3
Дүрт һəм аннан да күбрəк бала	10,3	3,6
Əйтергə кыенсынам		12,7
Җəмгысе	100	100

Репродуктив максатны өйрəнеп, без гомуми күрсəткечлəр буенча корреляция генə үткəреп калмадык, ə гаилəнең матди кереме, хатын-кызның гыйлем дəрəҗəсе, гаилəдəге халəте белəн бəйлелеген дə тикшердек. Болар безгə гаилəлəрдə аз балалылыкның сəбəплəрен һəм репродуктив максатка тəэсир иткəн факторларны ачыклау мөмкинлеген бирде.

Безнең тикшерү барышында гаилəнең матди хəле буенча гына шактый аермалар булуы ачыкланды.

Татар гаилəлəрендə шундый закончалык күзəтелə: никадəр матди халəт түбəн, шулкадəр көтелгəн балаларның саны күбрəк. Керемнең барлык категориясе өчен дə респондентларның ике балалылыкка ориентлашулары ачыкланды. Иң зур керемле гаилəлəр (20 мең сумнан күбрəк) бер балалылыкка ориентлаша. Матди яктан аз тəэмин ителгəн, айлык кереме 10 мең сумнан да ким булган гаилəлəр өч бала булдырырга тели.

Гаилəнең айлык матди керемене бəйле рəвештə көтелгəн балалар *(таблица 1)*

Татар гаилəсенең репродуктив халəтен өйрəнгəндə, аеруча зур игътибар репродуктив мотивларны тикшерүгə бирелде. Демография фəнендə репродуктив мотивларны икътисади, социаль һəм психологик төркемнəргə бүлү кабул ителгəн.

Мəскəү тикшеренүчелəренең нəтиҗəлəре күрсəтүенчə, хəзерге вакытта психологик мотив (50,2%) хəлиткеч роль уйный, икенче урында — социаль мотив (27%), һəм иң азакта икътисади (19,4%) мотив тора [4].

Безнең тикшеренүлəрнең дə күрсəткече мотивларның əһəмиятлелеге буенча Мəскəү демографлары ачыкланган нəтиҗəлəр белəн тулысынча диярлек тəңгəл килə. Əмма сайланган мотивларның процент чагыштырмаларында аермалар бар: психологик — 47,1%, социаль — 43,6%, икътисади 9,1% тəшкил итə.

Тикшеренүлəребездə түбəндəге психологик мотивлар аеруча ачык чагылыш тапты: гаилə мөнəсəбəтлəрен ныгыту (49,3%), үз гомереңне балалар аша озайту (48,5%), балалар — яңалык һəм шатлык чыганагы (34,3%). Шулай ук гаилəдə баланың энесе яки сеңлесе булуын телəве (9,7%), əти-əнилəрнең һəм туганнарның телəклəрен исəпкə алу (6%), берденбер баланың үлемкитем очрагы булганда, баласыз калу куркынычы (3%) кебек мотивлар да сайланылган.

Күпчелек ата-аналар балалар тууда түбəндəге социаль мотивларны сайлап ала: яртысыннан күбрəге нəсел калдыру идеясен алга сөрə (50,7%), респондентларның өчтəн береннəн артыграгы (36,6%) бала тəрбиялəү чын гаилə тормышы белəн яшəү дип саный, респондентларның өчтəн береннəн кимрəге (29,9%) бала табу кешенең мораль бурычы дип фикер йөртə. Тагын түбəндəге вариантлар да сайланган: балалар мин ирешмəгəнгə ирешəчəк, дигəн ышаныч (14,9%), тирə-юньдəгелəр арасында дəрəҗəне һəм хөрмəтне арттыра (4,5%), кайчагында тормыш күңелсезлеклəреннəн качарга ярдəм итə (3%).

Икътисади мотивлар арасында балаларның тууы бəхетле картлыкка гарантия (7%) дигəн фикер өстенлек итə. Тормышны ныгыту (4,5%), йорт хуҗалыгында булышчы булу (1,5%), төрле ташламалар бирү (0,7%) кебек

Таблица 1

Сез ничә бала табарга җыенасыз (булганнарын кертеп), (көтелгән сан)	1501-2000 сум	2001-3000 сум	3001-5000 сум	5001-7500 сум	7501-10 000 сум	10 001-20 000 сум	20 001-50 000 сум	Әйтергә кыенсынам	Җәмгысе
Берне дә					4,5		4		1,7
Бер бала		33,3		14,3	13,6	19	33,4	50	23,9
Ике бала	83,3	33,3	66,7	71,4	59,1	71,4	58,7	50	60,7
Өч бала	16,7			14,3	22,7	9,5	3,9		9,4
Дүрт һәм аннан да күбрәк бала		33,3	33,3						11,2

икътисади мотивлар бик аз респондентлар тарафыннан сайлап алынган.

Ата-аналар нинди сәбәп белән бала тудыруын күрсәткән җаваплар *(таблица 2)*

Татар гаиләсендә балалар тууда икътисади мотивлар югары әһәмияткә ия түгел, беренче урынны эмоциональ-психологик мотивлар алып тора. Күпчелек респондентлар өчен татар милләтенең гореф-гадәтләренә хас булганча, үзеңне балаларда күрү, нәселеңне озайту кебек психологик һәм социаль мотивлар зуррак кыйммәткә ия. Традицион булган мотивка «балалар туу — бәхетле картлыкка гарантия» кебек икътисади мотивны да кертеп карарга мөмкин.

«...Татарлар бала картлык көнендә өметем һәм яклаучым булачак дигән фикердә» (53% — татар, 40% — рус), дип язган Н.В.Богачёваның тикшеренү нәтиҗәләре дә кызыклы. Бу — татар менталитетына хас булган күренеш. Балалар — эшләүче гаилә әгъзаларына өстәмә йөк (24% — рус, 16% — татар) һәм өстәмә тынычсызлык, стресс чыганагы (18% — рус, 11% — татар) дип, руслар, татарларга караганда, тормыш авырлыкларыннан ешрак зарлана. Шул рәвешле, Н.В.Богачёва фикеренчә, татар гаиләсендә бала образы уңайрак кабул ителә.

Хәзерге гаилә, традицион гаиләдән аермалы буларак, бала тудыруны, аларның санын, яшь аермасын алдан планлаштыра. Моның өчен балага узудан саклану чаралары яки йөклелекне кисәтә торган методлар кулланыла.

Безгә ир белән хатынның балага узудан саклану чаралары куллану турындагы фикерләре дә кызыклы булды: 51,6% респондент йөклелекне кисәтү чараларыннан файдалана, 48,4% файдаланмый.

Йөклелекне кисәтә торган чаралардан файдалану, бер яктан — матди кыенлыкларга (торак шартлары начар — 20%, күп бала үстерергә акча юк — 11,3%), икенче яктан, сәламәтлек начар булуга бәйле (20%). Шулай ук кайбер респондентлар (12,5%) йөклелекне кисәтә торган чараларны куллануны күп бала тәрбияләргә вакыт һәм көч булмауга бәйләп аңлата.

Гаиләнең матди хәле никадәр яхшырак булса, шуның кадәр респондент көтелмәгән балага узудан саклана. Әйтик, күп респондентларның гаилә кереме 20 001-50 000 сум булса — 66,7% гаилә һәм 10 001-20 000 булса, 57,7% гаилә балага узудан саклана торган чаралардан файдалана. Матди ягы кыенрак гаилә йөклелекне кисәтә торган чараларны азрак куллана. Шулай итеп, алда ук билгеләнгәнчә, күпкеремле гаиләләр аз балага йөз тота. Әлеге сорауга җаваплар янәдән бер тапкыр бу нәтиҗәне дәлилли.

Сораштырылган күп кенә татар хатын-кызларының (30,6%) бар

Таблица 2

Репродуктив мотивациянең төре	Мотивлар	%
Икътисади мотивлар	тормыш-көнкүрешне яхшырта	1,4
	йорт хуҗалыгында ярдәмче	0,5
	төрле ташламалар алу мөмкинлеге бирә	0,2
	матур картлыкка гарантия бирә	7
Икътисади мотивлар буенча нәтиҗә		9,1
Социаль мотивлар	нәсел калдыруны тәэмин итә	15,9
	кешенең мораль бурычы	9,3
	тулы гаилә тормышы белән яшәү мөмкинлеге бирә	11,4
	балалар мин ирешмәгәнгә ирешерләр дигән ышанычны ныгыта	4,7
	тирә-юньдәгеләр арасында дәрәҗәне һәм хөрмәтне күтәрә	1,4
	кайчагында кайбер тормыш күңелсезлекләреннән качарга мөмкинлек бирә	0,9
Социаль мотивлар буенча нәтиҗә		43,6
Психологик мотивлар	ата-аналар һәм туган-тумачаларның теләкләренә җавап	1,9
	балалар гаилә җепләрен ныгыталар	15,4
	беренче бала үлгән очракта, баласыз калу куркынычы	0,9
	булган баланың эне яки сеңел теләвен искә алабыз	3
	балалар – шатлык, яңалык, кайгыртучанлык чыганагы	10,7
	үзеңне балаларда күрү мотивы, тормыш мәгънәсе	15,2
Психологик мотивлар буенча нәтиҗә		47,1
	барлыгы	100

гомерләре буена 2 йөклелек очрагы булган, 20,1% — өч йөклелек, 13,4% — дүрт йөклелек, 8,9% — биш һәм аннан да күбрәк йөклелек.

Гомер буена йөклелекнең саны

Сезнең гомер буена ничә йөклелек булды?	%
Бер	18,7
Ике	30,6
Өч	20,1
Дүрт	13,4
Биш һәм аннан да күбрәк	8,9
Белмим	8,2
Җәмгысе	100

Респондентларның беренче йөклелеге күп очракта исән бала тудыру белән тәгәлләнгән (82,1%). Әмма бала төшү белән тәмамланган очраклар да бар (8,1%), үле бала туу очрагы — 3,3%. Бер өлеш респондентлар өчен беренче балага узу көтелмәгән булган һәм ясалма аборт белән төгәлләнгән (2,4%).

Икенче балага узу, беренчесе кебек үк, күпчелек респондентларның (63,3%) исән бала туу белән төгәлләнгән, әмма шактый респондентлар (20,4%) төрле сәбәп аркасында ясалма аборт ясаткан. Бала төшү очрагы — 6,1%, үле бала туу 1% теркәлгән.

Гаиләнең кереме һәм балага узудан саклану чараларыннан файдалану

Сез хәзер йөклелекне кисәтә торган нинди дә булса чаралардан файдаланасызмы?	1501-2000 сум	2001-3000 сум	3001-5000 сум	5001-7500 сум	7501-10 000 сум	10 001-20 000 сум	20 001-50 000 сум	Әйтергә кыенсынам	Нәтиҗә
Әйе	28,6	100	50	40	30,4	57,7	66,7	33,3	51,6
Юк	71,4		50	60	69,6	42,3	33,3	66,7	48,4
Җәмгысе	100	100	100	100	100	100	100	100	100

Өченче йөклелек күп респондентлар өчен исән бала туу белән тәгәлләнгән (59,6%), әмма ясалма абортның саны алдагы күрсәткечләрдән шактый югары (24,6%). Бала төшү очрагы — 7%, үле бала туу 1,8% теркәлгән.

Нәтиҗәдә, йөклелек никадәр күбрәк булган саен, ясалма абортның да шул дәрәҗәдә күп булуы күренә. Дүртенче йөклелек күп респондентлар өчен (53,3%) аборт белән тәгәлләнгән, бары тик дүрттән беренең (26,7%) генә исән баласы туган, 6,7% бала төшкән.

Шулай итеп, диннең тыюына да карамастан, күпчелек татар хатын-кызлары һәм ирләре йөклелекне өзү яклы һәм, балага узудан саклана торган чаралардан файдаланып, бала тууны көйли. Болар татар гаиләсендә дини традицияләрнең үтәлмәве турында сөйли.

Респондентларның гаиләләрендәге балалар саны да демографик тикшеренүләрдә шактый әһәмияткә ия. Р.И.Зиннуров башкарган тикшеренүләрдән күренгәнчә, Түбән Новгородта бер татар гаиләсендәге балаларның реаль саны — 1,24. Татарстанда бу күрсәткеч — 1,65, Удмуртиядә — 1,52.

Гомумән, Россия буенча бер гаиләгә туры килгән бала саны 1,34кә тигез. Безнең тикшеренүләребез буенча, татар гаиләсендәге уртача бала саны 1,87гә тигез. Шулай итеп, татар гаиләсендәге балаларның реаль саны, гомумроссия күрсәткечләренә караганда, шактый югары. Хәтта Мордовия Республикасында да күпбалалы гаиләләр татар гаиләләре икәнлеге ачыкланды.

Без тикшергән шактый респондентларның (59%) гаиләсендә ике бала бар, 29,9% бер бала тәрбияли, 7,5% гаиләнең — өч баласы, 2,2% гаиләнең өч һәм аннан да күбрәк баласы бар. Бары тик 1,5%ның гына баласы юк.

Гаиләдә балалар саны хатын-кызларның гыйлем дәрәҗәсенә дә бәйле. Хатын-кызның гыйлем дәрәҗәсе никадәр югары булса, аның гаиләсендәге бала саны шулкадәр аз. Урта һәм урта махсус белемле хатын-кызларның (64%) гаиләсендә ике бала, 6%ында өч бала, 2%ында дүрт һәм аннан да күбрәк бала. Бер бала тәрбияләү

Татар гаиләсендәге балаларның реаль санының хатын-кыз гыйлеме дәрәҗәсенә бәйлелеге

Гаиләдә балаларның реаль саны	Урта һәм урта махсус белеме	Тулы булмаган югары белеме	Югары белеме	Гыйльми дәрәҗә	Җәмгысе
Бер бала	41,6	14,9	29,0	21,1	22,4
Ике бала	50	59,6	51,6	52,6	53
Өч бала	8,3	6,4	6,5	10,5	8,2
Дүрт һәм аннан да күбрәк		19,1	12,9	15,8	2,9
Балалар юк					12,7
Җәмгысе	100	100	100	100	100

югары белемле хатын-кызларда күбрәк күзәтелә (34,6%).

Шулай итеп, югары белемле хатын-кыз азрак бала таба, чөнки аңа гаилә эшләре белән генә шөгыльләнү икътисади яктан файдалы түгел.

Бүгенге шартларда милли гаилә институты, гаилә әгъзалары сөйләшә торган туган тел, яшәп килгән милли һәм дини традицияләр, милли рухтагы тәрбия, туган-тумачалар белән аралашу — болар барысы да татар милләтен саклауга хезмәт итә. Милләт яшәеше һәм үсеше өчен иң мөһим шартларның берсе булып татарларның саны арту тора. Без укучыларга тәкъдим иткән мәкаләдә демографик торыш белән бәйле кайбер факторларны ачыкладык. Бер яктан алганда, татар гаиләләре хәл итә торган күптөрле һәм катлаулы мәсьәләләр башка милләт гаиләләрендәге кебек үк, әмма шул ук вакытта кайбер аерымлыклар да күзәтелә. Безнең ачышларның иң әһәмиятлеләреннән берсе — республикабызда көн итүче милләттәшләребез арасында балаларның саны артуга уңай караш яшәү.

Гаиләләре булган күпчелек респондентның ике балага йөз тотканлыгы билгеле булды, икенче урында өч бала алып кайтып, аларны тәрбияләргә теләүчеләр тора. Гомумән алганда исә, күпчелек татарлар урта һәм азсанлы гаиләләрне өстен күрә. Ләкин билгеле шартлар тудырылганда, алар милли аңда салынган күбрәк бала алып кайту потенциалын тормышка ашырырга мөмкин. 2012 елда республикада балалар тууның артуы шушы уңай үзгәрешләрнең мөһим чагылышы, дип әйтергә була. Шунысы да мөһим: татар гаиләләрендә беренче планда матди факторлар түгел, ә хисси факторлар мөһим урын алып тора. Респондентлар балаларында үзләренең дәвамчыларын күрә, аларны милли рухта, милли традицияләргә нигезләнеп тәрбияләргә, балаларына тормыш тәҗрибәсен тапшырырга омтыла. Димәк, илдә алып барылган демографик сәясәт матди шартларны кайгырту белән генә чикләнмәскә, яшь буында күпбалалы гаиләләр булдырып яшәү теләген үстерү, кешеләр аңында баланың чыннан да иң югары кыйммәт булуын ныгыту мәсьәләләрен күз уңына куярга тиеш була.

Искәрмәләр

1. 2008-2009 елларда татар гаиләсен тикшерү берничә этапта узды. Беренче этапта (2008 елда) яшьләрдән сораштыру үткәрелде (Татарстан Республикасындагы мәктәп һәм гимназияләрнең югары класс укучылары). Сораштыруда Казан каласының 9, 51, 72, 139 нчы мәктәп һәм 2, 4 нче татар гимназияләре, шулай ук Татарстан Республикасының Әлмәт шәһәре, Алабуга, Мамадыш, Саба, Югары Ослан районнары мәктәп укучылары катнашты (447 кеше). Икенче этапта (2008 ел) студент яшьләр өйрәнелде (Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы район һәм шәһәр югары уку йортлары студентлары). Сораштыруда хәзерге Казан федераль университеты составында булган В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, аның Яр Чаллы филиалы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт һәм муниципаль идарә академиясе һәм Әлмәт дәүләт нефть институты студентлары катнашты (447 кеше). Өченче этапта 18-35 яшьләр аралыгындагы Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Яшел Үзән, Алабуга калаларында һәм төрле район авылларында яшәүче парлар өйрәнелде (450 кеше). 2009 елда үткәрелгән дүртенче этапта Казан шәһәрендәге татар гаиләләре анкета ярдәмендә өйрәнелде (450 анкетадан 397 се калды). Тикшерү өчен бер һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр сайлап алынды.
2. Социология семьи: Учебник / Под ред. проф. А.И.Антонова. М: ИНФРА-М, 2007. — С.377.
3. Зинурова Р.И. Этнокультурные и конфессиональные особенности репродуктивного поведения женщин в регионах Российской Федерации (Республика Татарстан, Республика Удмуртия, Нижегородская область) // Этносоциологические исследования в Республике Татарстан: Сб.науч. статей / Сост. и ред. Р.Н.Мусина, Л.В.Сагитова. — Казань, 2008. — С.241-259.
4. Антонов А.И., Медков В.М. Условия жизни и линии репродуктивного поведения городской семьи // Фамилистические исследования. Том 2: Миллион мнений о семье и о себе: сборник / Отв. ред. А.И.Антонов. — М.: КДУ, 2009. — С.60.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе

Кушымта

2012 елда 1 нче һәм аннан соң туган балалар — процентларда



2011 елда 1 нче һәм аннан соң туган балалар — процентларда



Соңгы елларда Татарстан Республикасында яшәүче гаиләләрдә ике һәм аннан да күбрәк бала тууның артуы күзәтелә.

Татарстан Республикасы Гражданлык актларын теркәү идарәсе эшчәнлегенең статистик күрсәткечләре

Еллар	Туу	Никах	Аерылышу	Үлем	Туу һәм үлем саннары арасында аерма
1991	51068	31872	11923	37336	+13732
1992	44589	27091	13225	38290	+6299
1993	41871	28533	14798	44178	-2307
1994	42286	26954	14976	48575	-6285
1995	39644	26197	14536	48432	-8788
1996	38349	21631	12051	45812	-7463
1997	37742	23357	12280	46332	-8590
1998	37563	20352	11108	45220	-7657
1999	35378	21544	11394	46638	-11260
2000	35606	21480	12820	49637	-14031
2001	36151	24138	15921	50050	-13899
2002	38603	25139	21020	51681	-13078
2003	39472	26471	17867	52637	-13165
2004	39523	24350	12842	51440	-11917
2005	37613	26969	14279	52030	-14470
2006	37787	27997	15245	49277	-11096
2007	41239	32795	15416	48961	-7722
2008	44926	29497	15671	49250	-4324
2009	47143	29392	14669	48073	-930
2010	49512	31435	13960	49909	-397
2011	51391	36103	14 750	47138	+ 4253
2012	56005	33172	15457	46579	**+9426**

Татарстан Республикасында 2011 елда 1992 елдан соң беренче тапкыр туу үлем саныннан артып китә, ягъни демографик вазгыять уңай якка үзгәрә.

2012 елда туу, никах һәм аерылышуны теркәгән актлар саны, туу һәм үлем күрсәткечләре арасындагы аермалар

	ТР районнары, шәһәрләре	Туу	Никах	Аерылышу	Үлем	Туу һәм үлем күрсәткечләре арасында аерма
1	Азнакай	832	476	233	890	- 58
2	Аксубай	313	163	65	448	-135
3	Актаныш	334	208	68	502	- 168
4	Алабуга	1282	1056	341	850	+432
5	Алексеевск	304	180	83	398	-94
6	Апас	183	108	56	352	-169
7	Арча	652	381	122	702	-50
8	Әгерҗе	515	259	141	556	- 41
9	Әлки	204	107	47	322	-118
10	Әлмәт	3162	1726	808	2308	+854
11	Әтнә	122	77	30	207	-85
12	Балтач	437	271	70	410	+27
13	Балык Бистәсе	247	159	59	449	-202
14	Баулы	467	232	149	506	-39
15	Биектау	437	200	111	592	-155
16	Бөгелмә	1417	856	472	1691	-274
17	Буа	517	272	123	710	-193
18	Зәй	700	440	291	810	-110
19	Кайбыч	116	59	25	262	-146
20	Кама Тамагы	134	95	52	271	-137
21	Кукмара	776	444	103	698	+78
22	Лаеш	340	173	96	502	-162
23	Лениногорск	1104	657	376	1179	-75
24	Мамадыш	470	299	118	634	-164
25	Менделеевск	384	221	98	409	-25
26	Минзәлә	379	215	104	484	-105
27	Мөслим	278	164	44	354	-76
28	Нурлат	653	411	204	821	-168
29	Питрәч	252	202	105	373	-121
30	Саба	428	285	52	399	+29
31	Сарман	429	247	124	503	-74
32	Спас	173	122	49	345	-172
33	Тәтеш	193	138	64	441	-248
34	Теләче	124	88	22	211	-87
35	Түбән Кама	4110	2593	1400	2451	+1659
36	Тукай	552	198	115	529	+2
37	Чирмешән	211	118	35	323	-112
38	Чистай	1082	646	283	1261	-179
39	Чүпрәле	209	112	46	445	-236
40	Югары Ослан	147	74	47	311	-164
41	Ютазы	315	171	117	381	-66
42	Яңа Чишмә	145	66	31	230	-85
43	Яшел Үзән	1637	1119	564	2372	-735
	Районнар буенча	**26766**	**16088**	**7543**	**28892**	**-2126**
	Яр Чаллы	8660	4718	2753	4192	+4468
	Казан	20579	12366	5161	13495	+7084
	Республика буенча	**56 005**	**33172**	**15 457**	**46 579**	**+9426**

Кушымтада тәкъдим ителгән мәгълүматлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык актларын теркәү идарәсеннән алынды.

Кызганыч ки, районнар буенча әлеге уңай вазгыятьнең киресе күзәтелә, ягъни авылларда үлүчеләрнең саны туучыларныкына караганда артыграк булып кала бирә. Бары тик Алабуга, Әлмәт, Балтач, Кукмара, Саба, Түбән Кама районнарында гына (таблицада кызыл төс белән бирелгән) демографик хәл берникадәр яхшы.

МИЛЛИ МӘГАРИФ КАҺАРМАННАРЫ

ГАСЫРЛАРДАН КИЛГӘН ХӘЗИНӘ

Татар педагогик фикере нигезендә халык педагогикасы тора. «Халык педагогикасы ул — халыкта яшәп килгән тәрбия өлкәсендәге карашлар, аның тәҗрибәгә нигезләнгән тәрбияләү, укыту алымнары һәм чаралары, буыннан-буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәре, халык өйрәтүләре, кыскасы, аның тәрбия тәҗрибәсе»*. Бүген шул бай тәҗрибәне туплап, аның, Тукайча әйтсәк, «тутыкмас җәүһәрләрен» җыеп, бербөтен итеп күрсәтү, шул рәвешчә, халык педагогикасының, гомумән, татар педагогик фикере формалашуга керткән өлешен һәм анда тоткан урынын ачыклап, халыкка, хәзерге буын тәрбиячеләргә җиткерү зур әһәмияткә ия.

Безнең педагогикабызның гасырлардан килгән тарихы бар. Төрле чорларда аның үсешенә дөнья диннәренең әхлакый нормалары һәм кануннары, шулай ук татарлар борынгы заманнардан ук аралашып, үзара тәэсир итешеп яшәгән күрше дәүләт һәм халыкларның (Кытай империясе, Һиндстан, Урта Азия, Иран, гарәп дөньясы, Төркия, Россия, Европа халыклары) тәрбия өлкәсендәге карашлары, укыту һәм тәрбия системалары нык йогынты ясаган.

Тарихи яктан караганда, татар педагогик фикере үсешенә бигрәк тә исламның рухи-әхлакый кыйммәтләренең тәэсире көчле булган. Бу очраклы гына түгел, чөнки татар мәдәнияте һәм татар мәгариф системасы нәкъ менә гарәп-мөселман цивилизациясе йогынтысында зур үсеш кичергән, чәчәк аткан. Дәүләтчелекне югалтканнан соң, җирле гореф-гадәтләр һәм мөселман уку-укыту системасы гына татар халкының рухи асылын һәм мәдәниятен саклап калырга ярдәм иткән.

Хәзерге тиз үзгәрүчән җәмгыять шартларында бу карашлар үзләренең әһәмиятен югалтмаганмы соң? Һичшиксез, әйтергә мөмкин: юк! Киресенчә, татар педагогларының хезмәтләрен җентекләп тикшергәннән соң, аларның укытуга һәм тәрбиягә карата карашларының бүгенге шартларда тагын да актуальрәк яңгыраш алуын күрәбез.

Яңа Федераль Дәүләт белем бирү стандартлары, «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика» дигән яңа курс кертелү янәдән татар халкының әхлак һәм дини тәрбия өлкәсендәге күпгасырлык тәҗрибәсенә — дини мәгариф өлкәсендә тупланган белемгә генә түгел, ә бәлки, халыкара, милләтара багланышлар, төрле милләт һәм дин вәкилләре белән дустанә һәм тыныч яшәү тәҗрибәсенә дә мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Шул бай тәҗрибәбезне бүгенге күпмәдәниятле җәмгыять шартларында дөрес файдалана белү мөһим.

Бу бай хәзинәнең иң кыйммәтле, иң файдалы үрнәкләре Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге хезмәткәрләре тарафыннан берничә ел дәвамында эшләнгән «Татар педагогик фикере антологиясе»ндә тупланган.

Антология сүзе грек телендә «чәчәкләр бәйләме», «гөл бакчасы» төшенчәсен аңлата. Шул «чәчәкләрне» «Чын мирас» журналы редакциясе белән берлектә «Милли мәгариф каһарманнары» дип аталган сәхифәдә тәкъдим итә башлыйбыз.

Марат Гыйбатдинов,
педагогика фәннәре кандидаты,
ТФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге мөдире,
Ләлә Мортазина,
педагогика фәннәре кандидаты

* Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре. — Казан: Мәгариф, 2003. — Б.5.

МАҺРУЙ МОЗАФФАРИЯ

МӘШҺҮР ХАТЫННАР

Риза казый язган «Мәшһүр хатынлар» бар,
Анда гали зат зур хатынлар бар.
Әдиблек, табиблек, философлык,
Тәдрис (укыту), шигырь берлән мәшгуль хатынлар бар.

Ул заманда нигә алай, инде болай
Кыйлды нигә (сөаль илә) безне ходай?
Ходай мәгъйүб[1] түгел, монда иректә эш,
Ирек булса, без дә булыр идек шулай.

Ул заманда хатын-кызлар кысылмаган,
Һәрбер эшкә мулла килеп кысылмаган;
«Хатынларның сачы озын, гакылы кыска», —
Дигән сүзләр аять булып тотылмаган.

Вакыт инде: без дә торыйк, ирек алыйк,
Ирекләнер чаклар җитте, иреклəник;
Нигә төшсә төшсен, куркып юлдан кайтмыйк,
Ни китсә дә китсен, шуны биреп алыйк.

Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,
Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.
Бер милләтнең там яртысы без булгачдыйн,
Карап карыйк: ирәнләрдән ничек ким без?!

Мөгаллимә һәм шагыйрә Маһруй Мозаффария.
Казан, XX йөз башы

Ирләр Галим булса, бездә Галимә бар,
Ирләр Заһид[2] булса, бездә Заһидә бар,
Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар,
Мөршид[3] булса, Мөршидә бар, Камилә бар.

Алар Сәмин[4] булса, бездә Сәминә бар,
Алар Әмин[5] булса, бездә Әминә бар.
Мөселманда булмаса да булмас, әмма
Башкаларда «бог»ка каршы «богиня» бар!

(Әл-ислах, 1907, №10. — Б.8.)

Шигырьне басмага ***Альта Мәхмүтова*** *әзерләде.*

[1] Мәгъйүб — гаепле
[2] Заһид — диндар, дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче
[3] Мөршид — туры юл күрсәтүче, хаклыкка өндәүче
[4] Сәмин — кыйммәтле
[5] Әмин — ышанычлы, куркусыз

«...ИРЕКЛӘНЕР ЧАКЛАР ҖИТТЕ, ИРЕКЛӘНИК»

АЛЬТА МӘХМҮТОВА,
тарих фәннәре кандидаты

УКУЧЫЛАР БАШЫНА, МӨГАЕН, «КЕМ СОҢ УЛ МАҺРУЙ МОЗАФФАРИЯ?» ДИГӘН СОРАУ КИЛЕР. 1873 ЕЛДА КАЗАН ГУБЕРНАСЫ ТӘТЕШ ӨЯЗЕ ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛЫНДА ГАБДЕЛВӘЛИ МУЛЛА ГАИЛӘСЕНДӘ ДӨНЬЯГА КИЛГӘН КЫЗ БАЛА XX ГАСЫР БАШЫНДА МӘШҺҮР МӨГАЛЛИМӘ, ШАГЫЙРӘ, МӘГЪРИФӘТЧЕ БУЛАРАК ТАНЫЛГАН, ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНДА БЕЛЕМ, ИРЕККӘ ОМТЫЛЫШ, МИЛЛИ РУХ УЯНУГА ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ШӘХЕСЛӘРНЕҢ БЕРСЕ БУЛГАН.

Маһруй һәм Хуҗаәхмәт Мозаффаровлар. Казан, XX йөз башы

Әнисе — Зөя өязе Кече Кайбыч авылы мулласы Төхфәтулла хәзрәт кызы, ягъни Уральскидагы «Мотыйгия» мәдрәсәсе мөдәррисе, Габдулла Тукайның остазы Мотыйгулла хәзрәтнең апасы булган. Әнисе үлгәндә, бары ике яшь кенә булган Маһруйга үги ана кулында тәрбияләнергә туры килгән. Кечкенәдән үк зирәк, белемгә тартылучан булган ятимә кызчык башта апасыннан хәреф танырга өйрәнгән. Әтисе, кызының укуга һәвәслеген күреп, аңа үзе дәрес бирә башлаган. Шулай Маһруй әтисеннән яхшы тәрбия алган, төрки, гарәп, фарсы телләрендә уку-язуга өйрәнгән, үз өйләрендә авыл кызларын җыеп укыта да башлаган. 18 яше тулганда, гүзәл Маһруй тормышында кискен үзгәреш булган. 1891 елның 20 сентябрендә аны Казандагы Печән базары мәчете мулласы — илле ике яшьлек Хуҗаәхмәт Мозаффарига (1838-1907) икенче хатынлыкка кияүгә биргәннәр. Маһруйдан шактый өлкән булган хәзрәтнең өендә авыру хатыныннан кала, ике баласы һәм карт әнисе дә булган.

Маһруй абыстай һәм Хуҗаәхмәт хәзрәт балаларының — кызы Мәхмүдә (шагыйрә, мөгаллимә) һәм улы Мансур (күренекле композитор) гаиләләрендә бу никах хакында әниләре сөйләгән хатирәләр сакланган. Үсмер кыз Маһруй белән аның авылдашы, Казанның атаклы Күл буе мәдрәсәсе шәкерте Зияэддин арасында дуслык—мәхәббәт чаткылары барлыкка килгән. Шәкерт авылга кайткан арада яшьләр хат алыша башлаган. Зияэддиннең чәчәкләр белән алтынлап бизәкләгән хатында:

Исемең синең Маһруй,
җисемең синең маһруй,
Миңа килми, ятка барсаң,
гомреңдә тапма абруй,

кебек шигъри юллар да булган. Хатларны, беркемгә белдермичә генә, бер-берсенә тапшыру юлларын да уйлап тапканнар: өй почмагындагы бүрәнә ярыгына яшерә торган булганнар. Әлбәттә, бу «почта ящигы» аларга озак хезмәт итә алмаган — бер көнне хатларның берсе Маһруйның әтисе Габделвәли хәзрәт кулына килеп кергән. «Мине каеш белән бәйләп, аркамнан кан чыкканчы кыйнадылар. Атна буе урынымнан тора алмый яттым», — дип язып калдырган Маһруй истәлекләрендә. Бу вакыйгадан соң хәзрәт яшьләрне аеру хәстәрен күргән һәм кызын үзенең чордашы Хуҗаәхмәт муллага икенче хатынлыкка биргән. Ә Маһруй моң-зарын җырга күчергән:

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
кыр казыннан моңлы бар микән?
Беренче мәхәббәтен җуйган
кыз баладан моңлы бар микән? [1].

Үз вакытына күрә шактый яхшы белем-тәрбия алган ачык фикерле яшь абыстай төшенкелеккә бирелмәскә тырышкан, «язмыштан узмыш юк» дип, авыру көндәшен, карт каенанасын тәрбияләгән, әлбәттә, йортны алып бару да аның өстендә булган. Хуҗаәхмәт мулланың «әүвәлге хатыны зәгыйфә булып, әнкәсе дә бик картаю сәбәпле, сабак шәкертләрен укыту һәм барча мәхәллә эшләрен карау Маһруй ханымның үзенә калган», — дип күрсәтелгән М.Мозаффариянең 1914 елда «Сөембикә» журналында басылган тәрҗемәи хәлендә. Юанычны ул эштә, китапларда табарга тырышкан. Маһруй ханым белемен арттыруны да дәвам иткән. «Мин үзем милли мәктәпләрдә укымадым. Ул вакытта мәктәпләр дә юк иде. Мин әүвәл әткәм Габделвәли хәзрәттән, соңра имам Хуҗаәхмәт хәзрәттән, аннан соң бер мөгаллимнән укыдым», — дип аңлаткан ул 1915 елда үзенең ничек белем алуы хакында.

Яшь абыстай үз вазифаларын башкаруга күнегеп барганда, гаиләсенә кайгы-борчулар килгән. Яше җитмәгән бер кызга никах укыганы өчен, 1893

елда Хуҗаәхмәт хәзрәтнең указы алынган, аңа күпмедер вакыт төрмәдә утырырга да туры килгән. Шул ук елда Мәһруйның каенанасы вафат булган. Озакламый, каты авырудан соң, аның көндәше Нәгыймә дә дөнья куйган. Шулай Хуҗаәхмәт хәзрәтнең өлкән балалары Мәхмүт һәм Җәмиләне тәрбияләү дә тулысынча яшь абыстайга калган. XIX гасыр азагы — XX йөз башында Мозаффарилар гаиләсендә тагын өч бала дөньяга килгән: Мәхмүдә (1893-1969), Габбаса (1898-1921) һәм Мансур (1902-1966).

«Мәһруй ханымның хәятендә бөтенләй башка дәвер башланган, чөнки өй тулы балалар тәрбиясеме, мәхәллә эшләреме дисең, бар да үз башына калган. Хәлбуки, бу елларда ысуле җәдидә тавышлары да чыга башлаган иде, Шөбһәсез, Мәһруй ханым да һәркемнән әүвәл моңа рәгъбәт (үрнәк) иткән. Вә бу тугърыда нинди фидакарьлекләр кирәк булса, барсын да көлә-көлә эшләгән. Менә шушы гайрәт сәмәрәсе (җимеш) уларак, Казанда ысуле җәдидә тәгълиме шәрәфе, икенче уларак, Мәһруй ханымга төшмештер», — дип күрсәткән аның биографы.

Чыннан да, Мәһруй ханым тормышка ныклап аяк баскан вакыт татар җәмгыятендә яңарыш чаткылары күренгән, милли аң уянган дәвергә туры килгән. 1937 елның 7 августында язган автобиографиясендә ул үзе дә: «Мин тормыштан артта калмаска тырыштым, беренчеләрдән булып чапанны ташладым һәм 1901 елдан матбугат белән таныша башладым», — дип искә алган. Күрәсең, яшь абыстай, ачык фикерлелеге, зирәклеге өстенә, хөр күңелле, кыю ханым да булган. Ул үзенең шул чорда ук И.Гаспринскийның «Тәрҗеман» газетасын алдыра башлавын да күрсәткән. Шулай бу газета һәм мәгърифәтчел рухтагы җәдид татар әдәбияты, яңа вазгыять йогынтысында Мәһруй абыстай үз өендә кыз балаларны яңача укыта, тәрбияли башлаган. Әгәр дә Казанда кызларны җәдид ысулы белән укырга-язарга өйрәтүне 1891 елда Мәһруй Барудия башлаган булса, бу юлда икенче адымны Мәһруй Мозаффария ясаган.

Төрле төбәкләрдә оештырыла башлаган җәдид кызлар мәктәпләрендә укытучы мөгаллимәләргә күп кенә авырлыкларны җиңәргә туры килгәнен дә искәртик. Ул үз «мәптекләре» булган абыстайларның яңа ысулга каршы килүе дә, укыту методикасы, программасы, дәреслекләр булмау да... Әлбәттә, башлангыч белем бирүдә мөгаллимәләр ирләр мәктәпләре өчен дөнья күрә башлаган әлифба-хисап дәреслекләреннән файдаланган. Ләкин кызлар өчен махсус дәреслек-уку китаплары да кирәк ич! Тәвәккәл мөгаллимәләр бу эшкә дә алынган. Әсәрләре аерым китап булып басылган беренче мөгаллимә — Хәнифә Гыйсмәтуллина. 1895 елда аның «Гакыйдәтел әһле-хак (Хаклык әһелләренең иманы)», 1897 елда — «Тәгъзия (Юату)», 1898 елда — «Тәргыйб (Кызыксындыру)», 1900 елда «Мәгъдәнел-мәсаил (Мәсьәләләр чыганагы)» әсәрләре басылган. Китаплары бу елларда басылып чыккан «беренче карлыгачлар»дан Галимәтелбәнат Биктимерия, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрияне дә искә алыйк. 1901 елда үзенең «Нәсыйхәтнамә»се* белән Мәһруй Мозаффария дә бу зыялы ханымнар рәтенә баскан.

Әлеге мөгаллимәләрнең үгетнәсыйхәт белән тулы китапларында кызларга нинди белем кирәклеге хакында фикер алышырга теләү дә, үз тәҗрибәләре белән бүлешү дә булган. «Гыйлем ысул җәдидтәнме, ысул кадимнәнме, максуд — язу танымак. Әмма минемчә, ысул җәдиднең укырга һәм язарга өйрәтүдә асатлыгы, кыска

*«Нәсыйхәтнамә лиәһли заманиһи» китабы белән мәкалә азагында танышырга мөмкин.

гына заманда язу таныр өчен файдасы бар, — дип аңлаткан, мәсәлән, Маһруй ханым үз адымнарын. — Хәзерендә тәҗрибә итәбез, үзебездә сабыя һәм балига (балигъ булган) шәкертләрем бар. Ысул җәдидә илә укып бер елда яхшы гына сәвад танып (укыйяза белеп), Кәляме шәрифне әхкяме (кагыйдә) илә укучы сабыйларым бар. Аз-аз язу һәм язалар, рәсем хатлары (каллиграфия) булмаса да, мәмләкәт халкыбызның рәсме (гади язу) илә язалар вә һәм балигәләре гыйльме хисаптан да беләләр».

Үзләренең биш баласын заманча тәрбияләүгә дә күп игътибар биргән Маһруй ханым. Ул аларның сәләтләрен үстерергә, һәрвакыт ярдәмгә килергә тырышкан. Мәсәлән, кызы Мәхмүдәнең музыкага тартылуын күреп, ул аңа башта мандолина, аннан гармун алып биргән. Кеше-кара юкта, әтисеннән яшереп кенә бу коралларда уйнарга өйрәнүен Мәхмүдә апа үзе тәфсилләп сөйләгән иде... Шулай беркөнне, үсмер Мәхмүдә чарлакта онытылып гармун уйнап утырганда, аны әтисе ишеткән. Хуҗаәхмәт мулла, кызының уйнавын озак кына тыңлап торганнан соң: «Бәрәкалла, кызым, бәрәкалла, бигрәк матур уйныйсың, кулларыңа күзләр генә тия күрмәсен», — дип, аның уйнавын ошатканын белдергән. Шул көннән соң мулла, җае чыккан саен, кызының гармун уйнавын яратып тыңлап утыра торган булган.

1901 елдан Маһруй ханым татар кызлары өчен дәүләт хисабына ачылган беренче рус-татар мәктәбендә [2] укыта башлаган. Бу адымы да аннан зур кыюлык таләп иткән. Мәктәп Казан татар укытучылар мәктәбе директоры мәрхүм Шаһбазгәрәй Әхмәревнең хатыны Шаһиморат Алкин кызы Хәдичәбикә җитәкләгән бер төркем татар хатын-кызлары тырышлыгы белән эшләп киткән. Алар Казан уку-укыту округы идарәсенә дәүләт хисабына татар кызлары өчен рус-татар мәктәбе ачуны сорап мөрәҗәгать иткәннәр.

Бу могҗиза кебек кабул ителгән үтенеч нигезендә 1901 елның 1 июленнән Казанда татар кызлары өчен рус-татар мәктәбе ачарга рөхсәт бирелгән һәм мәктәп чыгымнары өчен еллык 470 сум акча да билгеләнгән. Мәктәпнең попечителе (җитәкчесе) итеп Хәдичә Әхмәрева, рус телендә укытыла торган дөньяви фәннәр укытучысы — аның кызы Маһипәрвәз, дин сабагын (һәм татар телен) укытучы итеп Маһруй ханым билгеләнгән. Мәктәптә дәресләр 1901 елның 5 сентябрендә Захарьевская (хәзерге Каюм Насыйри) урамы Шәмсетдинев йортында 25 укучы белән башланган.

Дәүләт хисабындагы рус-татар мәктәбендә төп игътибар, әлбәттә, укучы кызларга русча башлангыч белем һәм дөньяви, Европа мәдәниятенә нигезләнгән тәрбия бирүгә юнәлтелергә тиеш булган. Ләкин дини-милли тәрбия һәм белем бирелмәсә, ата-аналар кызларын бу мәктәпкә бирмәсләр иде. Мәктәп яшәешенең беренче елларында анда укучылар саны азлыгын халыкта нәкъ шундый шөбһәләр булуы белән аңлатырга мөмкин. Дини-милли тәрбия Маһруй ханым кулында булган. Һәм ул, мәктәп программасында дин дәресләре өчен билгеләнгән вакыт белән генә чикләнмичә, кызларга динне дә, татар телен дә үз йортында өстәмә дәресләрдә дә өйрәткән. Маһруй абыстай үз кызларын да шунда укыткан, үз мәктәбе укучыларын да бу мәктәпкә керергә күндергән.

1904 елның 1 гыйнварына бирелгән мәгълүматларда, ягъни мәктәпнең өченче ел яшәешендә дә, монда ике бүлектә барлыгы 30 укучы күрсәтелгән. Ләкин революция елларында кызларын бу мәктәптә укытырга теләүчеләрнең саны күзгә күренеп арткан (1906/07 уку елында — 53 укучы). Укучылар саны арткач, мәктәп зуррак йортка — Екатерининская (хәзерге Габдулла Тукай) урамында урнашкан Хәдичәбикәнең туганы Сәетгәрәй Шаһиморат углы Алкин йортына күчерелгән һәм

шушы бинада 1918 елга кадәр эшләгән. Ләкин бу бина да зурлардан булмаган. 1911 елның 1 гыйнварына монда 68 укучы исәпләнгән. Дөрес, мәктәптә укырга теләүчеләр саны күбрәк булган: халык мәктәпләре директоры күрсәтүенчә, бу мәктәпнең бинасы шуннан артык укучы сыйдыра алмаганга, 1910-1911 уку елы башында монда 20дән артык кыз кабул ителмичә калган [3].

Мәктәпнең халык арасында абруе үсүдә Мәһруй ханымның роле гаять зур булган. Ул бу мәктәптә ачылган көненнән алып 1918 елга кадәр эшләгән, мәктәпнең төп тоткасы булган дияргә дә ярый. Чөнки дөньяви фәннәрне укытучы яшь кызлар шактый еш алмашынып торган (кайсы укырга, кайсы кияүгә киткән). Мәсәлән, Мәһипәрвәз Әхмәрева монда бер ел ярым гына эшләп алган. Аны 1903 елның 1 гыйнварыннан Петербургта Елизавета патшабикә институтын тәмамлаган атаклы мәгърифәтче, галим Хөсәен Фәезханов кызы Әминә ханым алмаштырган. Мәктәпнең рәсми исеме «Беренче рус-татар кызлар мәктәбе» булса да, аны халык арасында Хәдичә Әхмәрева мәктәбе дип тә йөрткәннәр. Шулай да иң таралган исеме «Мәһруй ханым мәктәбе» булган. Хәер, беренче революция елларында тагын бер исем өстәлгән: аңа укучылары, заман таләпләренә туры китереп, «Әлиҗтиһад», ягъни «Тырышлык» дигән исем биргәннәр.

Остазларыннан яхшы тәрбия алган, рус телен өйрәнгән, белемгә омтылучы кызлар белемен рус мәктәпләрендә арттыру мөмкинлегеннән дә яхшы файдаланган. Бу мәктәпне тәмамлаган утыздан артык кызның рус гимназияләрендә укуларын дәвам итүләре хакында 1914 елда «Сөембикә» журналы хәбәр урнаштырган. Мәһруй ханым язып калдырган тәрҗемәи хәлендә үзенең укучылары арасында күп кенә укытучылар, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина, Гөлсем Сөләйманова, Мәрьям Рәхманкулова кебек артистлар булуын горурлык белән искә алган.

XX гасыр башында Мәһруй абыстай чын мәгърифәтче булып формалашып җиткән. Аның хатын-кызлар тәрбиясенә багышланган «Нәсыйхәтнамә» исемле беренче китабы, әйткәнебезчә, 1901 елда дөнья күргән. Татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч, ул «Казан мөхбире», «Бәянелхак», «Әл-ислах», «Сибирия», «Сөембикә», «Мәктәп» кебек газета-журналларда да шигырь һәм хикәя-мәкаләләрен бастырган. Аның хатын-кызларның шәхси ирекен богаулап килгән гореф-гадәтләргә каршы көрәшкә, белемгә өндәгән әсәрләрен җәмәгатьчелек, бигрәк тә яшь кызлар һәм егетләр, яратып укыган. Мәһруй ханымның 1906-1917 елларда татар матбугатында дөнья күргән әсәрләрендә хатын-кызлар арасында аң-белем тарату, гаиләдә һәм мәктәпләрдә гигиена кагыйдәләрен үтәү һәм бала тәрбиясе мәсьәләләре күтәрелгән. Кайбер хикәяләрендә ул шул чор татар хатын-кызлары кичергән фаҗигале тормышны да сурәтләгән.

Мәһруй ханымның иң танылган әсәре дип, мөгаен, аның «Әл-ислах» газетасында 1907 елның унынчы санында басылган «Мәшһүр хатынлар» исемле шигырен атарга кирәктер. Мәһруй Мозаффариянең бу әсәрендәге уй-фикерләре басылу белән үк татар җәмгыятендә киң яңгыраш тапкан. Казан абыстайларыннан беренче булып урамда ачык йөз белән йөрергә җөрьәт иткән курку белмәс мәгърур ханым шигъри юллар белән башкаларны да хәрәкәткә, уянырга чакырган. Ничек кенә чакырган әле! Аның бәгыреннән кайнап чыккан сүзләре XX гасыр башы хатын-кызларында гына түгел, хәтта бүген бездә, бер гасыр соңрак яшәүчеләрдә дә горурлык хисләре тудыра, күңелнең ниндидер бик нечкә кылларын кузгата кебек. Димәк, шигырь бүген дә үз актуальлеген югалтмаган *(шигырь мәкалә алдында тулысынча бирелә. — Ред.)*.

Шагыйрәнең әсәре Ризаэддин казый Фәхреддиннең 1903-1904 елларда

Оренбургта басылган «Мәшһүр хатынлар» исемле китабы йогынтысында язылган. Галим үз әсәрендә ислам дөньясында шөһрәт казанган хатын-кызларның биографияләрен сурәтләгән. Маһруй ханым исә: «Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без, гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без», — дип, XX гасыр хатын-кызларын алардан үрнәк алырга, эшкә тотынырга өндәгән.

Кызы Мәхмүдә сөйләвенчә, әнисенең шигыре язылу вакыты 1904-1905 елларда булырга тиеш. «Без, әнинең укучылары, бу шигырьне матбугатта басылганчы ук яттан белә идек, аны еш кына сөйли-көйли идек», — дип искә алган иде Мәхмүдә ханым. Шигырь тиз арада белемгә, милләт хакына хезмәткә омтылучы хатын-кызлар арасында таралган, аны мәҗлесләрдә яттан сөйләгәннәр, мөнәҗәт кебек көйләгәннәр, дуслары-туганнарына хат аша җибәргәннәр. Бубый һәм Ләбибә кызлар мәктәпләрендә һәр уку көне шушы шигырьне көйләүдән башлана торган булган.

Маһруй ханымның «Мәшһүр хатынлар» шигыренең роле хатын-кызларны уятуда гына түгел; аның, гомумән, татар җәмгыятенә тәэсире гаять зур булган. Бу хакта Сәгыйть Рәмиевнең шигырьне укыганнан соң язган «Юк, үлмим! Торам әле!» [4] дигән мәкаләсе ачык сөйли. Мәкалә «Әл-ислах»ның унберенче санында ук басылган. «Монда ничә йөз еллардан бирле изелеп килгән, мәзлумә мәҗбүр булган татар хатыннары үзләрен ничә йөз еллар буена каһәрләп-җәберләп-изеп килгән ирләргә каршы сугыш ачканнар иде. ... Ихтыярсыз җанландым. Яңадан торасым килә башлады. Кул селтәгән өмидләрем яңадан кайттылар. Мин тагы бик зур өмидләргә чумдым», — дип язган С.Рәмиев. Маһруй Мозаффариянең шигырен ул хатыннарның милләт өчен башкарган бөек хезмәте буларак кабул иткән. Шуңа күрә шагыйрь рәхмәтен барча хатыннарга юнәлткән: «Рәхмәт сезгә, хатынлар, мине тергездегез!» Һәм шигырьне укыганнан соң туган өметләрен дә билгеләгән: «Аллаһ теләсә, шушылай хатынларымыз җанланып, үз хакларын үзләре белә башлап, дөньяда кеше шикелле торырга тырыша башласалар, шөбһәсез, татарлар да кеше шикелле тора башларлар».

Ә Маһруй ханымның үзе һәм ишле гаиләсе өчен 1907 ел бик авыр булган. Хуҗаәхмәт хәзрәт вафат булган; биш балалы гаиләнең малсыз-акчасыз гына түгел, йортсыз да калганлыгы (йортлары күптән үк закладка салынган булуы) ачыкланган. Шулай да Маһруй абыстай төшенкелеккә бирелмәгән, теше-тырнагы белән тырышып-тырмашып, гаиләсенең көнкүрешен тәэмин иткән. Озакламый аның үги балалары да, үсеп җитеп, үз тормышларын корып җибәргәннәр, өлкән кызы уналты яшьлек Мәхмүдә дә 1909 елда ачылган Фатиха Аитованың кызлар мәктәбендә укыта башлаган.

Дәвамы киләсе санда

Искәрмәләр

1. Бу вакыйгалар хакында 1965-1966 елларда мәкалә авторына Мәхмүдә Мозаффария-Урманчиева сөйләгән иде. Шул вакытта ук мәкалә авторы бу очеркта китерелгән һәм алда кулланылачак башка истәлекләрдән алынган өзекләрне Мәхмүдә ханым рөхсәте белән күчереп алган иде.
2. Рус-татар мәктәбе дип татар балаларына рус телендә башлангыч белем бирүче уку йорты аталган. Бу татарлар тарафыннан шикләнеп кабул ителгән мәктәпләр 1870 елда расланган «Россиядә яшәүче рус булмаган халыкларны укыту чаралары» исемле кагыйдәләр нигезендә хөкүмәт хисабына ачыла торган булганнар. Кара: Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар. — Изд-во Казан. ун-та, 1982. — С.23-43.
3. Шунда ук. — Б.31-33.
4. Рәмиев С. Юк, үлмим! Торам әле! // Әл-ислах. — 1907. — №11. — Б.5-7. — Бу очерк 1980 елда шагыйрьнең җыентыгында да басылган. Кара: С.Рәмиев. Таң вакыты. — Казан, Татар.кит.нәшр., 1980. — Б.150-153.

«ӘЙ, ГАЗИЗӘ БИКӘЛӘР!»

Игътибарыгызга күренекле татар мәгърифәтчесе, мөгаллимә һәм шагыйрә Маһруй Мозаффариянең «Нәсыйхәтнамә лиәһли заманиһи» исемле әсәрен тәкъдим итәбез. 1901 елда дөнья күргән ошбу китабында Маһруй Мозаффария татар хатын-кызларын җәдидчә укырга, гыйлем алырга, рухи яктан агарырга һәм үзләренең гаиләдәге хокукларын якларга өндәп, «беренче карлыгачлардан» буларак, заманы өчен шактый кыю фикерләр әйтә. Әсәрдә әдибәнең үз тормыш юлыннан да кайбер мизгелләр бар.
Шул чордагы мөселман җәмгыяте өчен кулланма рәвешендә язылган бу китап хәзерге заман укучысы өчен дә тарихи, әдәби мирас буларак кызыклы дип уйлыйбыз.

نصیحت نامه لاهل زمانه

اثر ماهروی بنت ملا عبد الولی

بو کتاب باصمه سنه رخصت بیرلدی سانکت پیطربورغده
٢٧ نچی نویابرده ١٩٠٠ نچی یلده

اوشبو کتاب قزان اونیویرسیتیتی ننک طبع
خانه سنده باصمه اولنمشدر ١٩٠١ نچی یلده

Дозволено цензурою. С.-Петербургъ, 27 ноября 1900 г.

КАЗАНЬ.
Типо-литографія Императорскаго Университета.
1901.

Маһруйбанәт бинте мелла Габделвәлинең «Нәсыйхәтнамә лиәһли заманиһи» китабының тышлыгы

НӘСЫЙХӘТНАМӘ ЛИӘҺЛИ ЗАМАНИҺИ*

[Замана әһелләренә нәсыйхәтнамә]

Бисмилләһиррахманиррахим.

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә барлык мактаулар булсын, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның әһеленә, һәм сәхәбә кирамнарга салават һәм сәламнәр булсын.

Абыстайлар вә бикәләр, сезләргә гыйлемем җитешкән кадәр үз телебезчә нәсыйхәтнамә бер сүз әйтәем. Без хатыннар ни өчен бу кадәр гафилбез, укырга бер дә иҗтиһад [тырышлык] итмибез. Дөнья эшен һәркаюсын тегүчелек, бәйләү вә ма әшбәһеләрне [шуңа охшашларны] иҗтиһад итәргә яхшы беләбез, укуга да шулай иҗтиһад итсәк, иншаллаһ, тәгали яхшы булыр иде. Үзебез гафил, үзебездән иҗтиһад кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. әфәндебез гыйлем эстәмәк һәр мөселман иргә һәм мөселман хатын-

* Әсәр кыскартып бирелә.

га фарыз дип боерган. Без үзебезгә кирәкле фарыз булган нәрсәләрне үгрәнергә тиеш. Бинаән [нигездә], ислам гыйлемнәрен уку һәм аңлау без хатын-кызларга фарыз эш. Ник иҗтиһад итмибез? Бу фани дөньяның ләззәтенә бик җәһед итәбез [көч куябыз], төрле-төрле күлмәкләр, төрле шәлләр, төрле калфакларга күңел куябыз, бер-беребездән уздырырга җәһед итәбез. Кабердә, кыямәт гарасатында безгә сөаль булачак, ни җавап бирербез? Туганнарым гыйлем безгә фарыз гайндер [һәрбер мөселман башкарырга тиеш булган гамәл]. Кирәк бай, кирәк фәкыйрь булсын, кирәк яшь вә кирәк карт булсын, фарыз гайн булган гыйлемне Мәккәи мөкәррәмәгә вә Мәдинәи мөнәвәрәгә барып, тәкия [мөридләрнең ишан кул астына зикер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары] алып, яки Бохарага барып, хөҗрә [шәкертләргә яшәү өчен корылган таш бина] алып вә яки үз җиребездәге мәдрәсәгә кереп тәхсил гыйлем кылмак [уку] фарыз имештер. Әмма бу тарика [юл] мөмкин булса, бик яхшы. Әгәр алай булмаса, һәркем үзе генә зарур мәсьәләне үзеннән өстен булган әһле галимнән сорап белмәк мөмкиндер. Гаҗәп, бу заманыбызда дөньяны язмыш хикәят вә сафсата китапларын укырга вакытыбыз буладыр, әмма дин вә милләтебезгә тиешле булган китапларны укырга вакытыбыз булмыйдыр. Бу вакыт булмаганлыктан, без бичараларның күңелләре каралып, дөнья алдаучыларга мәхәббәт баглап шайтан юлына төшкәнлегебездәндер. Һәр мөэмин вә мөэминәгә фәһем итәрдәй [зиһенгә алырдай] китапларны мөмкин кадәр күп карамак вә укымак лязимдер. Шәригатьне еш истигъмаль кылмак [файдалану] күп вакытлар Аллаһы Тәгаләнең гамәл вә тагатьләренә [кушканнарына буйсынуга] муафикъ булмакка сәбәптер. Әй, газизә бикәләр! Без хатыннарның гакылыбыз кыска булып, сачебез озын булса да, бу фани дөнья эшен тиз фәһемгә хафиз [зиһенгә алабыз] итәбез. Кием-салымның елдан ел формасын арттырабыз. Әгәр фарыз важиб [тиеш булган] вә сөннәте хәләл, харам вә мәкруһларны [тыелганнарны] фәрыкъ итәр [аерыр] кадәр үгрәнсәк, нинди яхшы эш булыр иде. Әмма, кардәшләрем, бәгъземез укыйбыз ак өстендә кара язганны, әмма агызыбыз укый — колагыбыз ишетми. Бу эшебез гакылыбыз кыскаданмы яки бу фани дөньяның кимчелегеннәнме, яки ирләребез вә балаларыбыз шөгыленнәнме, яки җаһил [наданлык] вә химакатебездәнмедер [акылсызлыгыбызданмы]? Хакыйкать, ата вә анабыз безне сабый вакытта сабак үгрәтү һәм остазга бирү фарыз булган вакытта, сабак укуга бирмәсә, баланың җаһил булып калуы бар, ләкин сабый вакытта ата-ана җәһед итеп, баласын остазга тапшырса, бала сәләте булса тиз вакытта язу таный. Чөнки балалар яшь агач кебидер — яшь агач никадәр кәкре булса да, төзәтүе асаттыр. Шуның кеби, адәмгә сабый вакытта тәрбияне кабул итү асат буладыр, ләкин бәлягатькә [ир һәм кыз баланың җенси җитлегүе] җиткәч, күңелгә төрле уйлар вә фикерләр төшеп, дөньяга чыгу фикерләре килеп, төрле нәрсәне арзу кыла башлый. Шул сәбәптән, яшь вакытта җәһед итәргә кирәк. Гыйлем ысул җәдидтәнме, ысул кадимнәнме, максуд — язу танымак. Әмма, минемчә, ысул җәдиднең укырга һәм язарга өйрәтүдә асатлыгы, кыска гына заманда язу таныр өчен файдасы бар. Хәзерендә тәҗрибә итәбез, үзебездә сабыя [сабый] һәм балига [балигъ булган] шәкертләрем бар. Ысул җәдидә илә укып, бер елда яхшы гына сәвад таныпа [укый-яза белеп], кәлям шәрифне әхкяме [кагыйдә] илә укучы сабыйларым бар. Аз-аз язу язалар, рәсем хатлары [каллиграфия]

Печән базары мәчете

булмаса да, мәмләкәт халкыбызның рәсме илә [гади язу мәгънәсендә] язалар вә һәм балигәләре гыйльме хисаптан да беләләр. Пәйгамбәребез, гәрчә мөгаллим еракта булса да, барып укырга әмер иткән. Аллаһы Тәгалә Коръән кыйраәт хөкеме илә укылмаса, укучы гөнаһлы булыр, дигән. Кулыбызда форсат бар вакытта тәгаллем алыйк [укыйк], әлхәмдүлилләһи, мөгаллимәләребез бар. Гафләттә [наданлыкта] булмаек. Әй, зәгыйфәләр! Сәламәт вә терек вакытыбызны ганимәт [байлык] дип белеп, бу фани дөнья эшеннән ахирәт эшен алда тотыйк. Барасы юлыбызны фикерләп, сәламәт вә яшь вакытта гафләт булырга ярамый, пәйгамбәребез мал табылыр, әмма тиз бетәр, ә гыйлем бетмәс, дигән. Әй, зәгыйфәләр! Бу нәсыйхәтне мин язмадым гайбәт итеп, мәгәр үземдә булган ноксанатны [кимчелекне], әгәр хатасы булса, гафу итегез.

КАЕНАТА ҺӘМ КАЕНАНАЛАРГА ТИЕШЛЕ СҮЗЛӘР

Каената һәм каенана — олуг кешеләр. Алар килен булып төшкән кешеләргә шәфкатьле булырга тиеш. Хосусан яңа вакытта бу эшләр минем башымнан үтте, үзем Тәтеш өязендәге бер имам баласы идем. Йөз чакырым җирдән бу шәһәргә килдем, әмма икенче хатынлыкка. Ул вакытта мөгаллимә каенанам бар иде һәм мөляемә вә мазлумә [рәнҗетелгән] көндәшем бар иде. Шулвакытта мин бу шәһәрнең гадәтләрен вә мөгамәләсен вә тәртипне белми идем. Чөнки мин үзем ата-ана сохбәтеннән башка сохбәт күрмәдем, хәтта атабыздан башка кемсәне белмәдем, фәкать үз йортыбыздагы мөгамәләне генә белдем вә әл-хасил мине зәүҗәм [ирем] алып килде, яңа вә яшь вакыт, бу йортның мөгамәләсен ничек итәргә белмәймен, бәгъзе нәрсәләрнең исемен һәм белмәймен, чөнки дөнья күрмәгән мин, тәмам башым шашып, төбемнән аерылган коштай булып ман сабара зафарә [ягъни сабыр иткән максатына ирешер] дип сабыр иттем. Әлхәмдүлилләһи, бара-бара зафарә [өстенлек] таптым, әмма каенанам, мәрхүмә, гаять тәкъва [диндар] кеше иде, һәрдаим кулында кәлям шәриф булды. Хозурына чакырып вәгазь вә нәсыйхәт итәр иде вә көндәшем дә бу шәһәрнең олуг мөдәррис вә имам баласы иде, ягымлы вә мөлаем сүзле кемсә иде. Һәр икәүне Аллаһ хәзрәте чиксез рәхмәт итсен имди. Әфәнделәр, олуг булган адәмнәр яшьләрнең бәгъзе [кайбер] ноксанатларын [кимчелекләрен] гафу итеп юл куярга тиеш, чөнки картлар һәм яшь вакытта үз башларыннан үткән эшен онытмаска тиеш. Китап: «Картлык килмәстән әүвәл яшьлекне ганимәт бел, фәкыйрьлек килмәстән әүвәл дәүләтнең кадерен бел, авыру килмәстән әүвәл тынычлык кадерен бел, әҗәлең килмәстән әүвәл тереклек кадерен бел», — дип әйтә.

Тәртип итеп язгучы шәһре Казанда Печән базары мәхәлләсендә балалар мөгаллимәсе, мулла Хуҗаәхмәд Мозаффари хатыны, Казан губернасы Тәтеш өязе Олуг Тормы иленең имам хатибы һәм мөдәррисе, мулла ***Габделвәли бине мулла Габделсаттар кызы Маһруй*** *әсәредер.*

Чыганак

Маһруйбанәт бинте мелла Габделвәли. Нәсыйхәтнамә лиәһлел заманнә [замана әһелләренә нәсыйхәтнамә]. — Казан: Универ. табгыханәсе, 1901. — 14 б.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

МӘХМҮДӘ МОЗАФФАРИЯ

ХАНЫМНАР

И ханымнар! Әя, сездән күргән бармы
Кырда матур чәчкәләрне, үләннәрне?
Иркен үсә ул үләннәр — гыйбрәт безгә —
Чапаннарны, озын шәлләрне бөркәнми.

Көндез кояш, айлы кичтә айның нуры
Һич манигъсыз[1] үләннәргә төшә туры,
Көмеш илә бизәклидер вакыт-вакыт,
Ялтырата рәхмәт ягъмурының суы…

Үләннәр дә хакыйкатьтә ирле, хатын-
лы булалар, берсе — ирдер, берсе — хатын.
Ләкин алар шундый рәхмәт яуган халык:
Ашашмыйлар рәфыйк рәфыйканың[2] хакын.

Алар җәйнең матурлыгын бергә бүлә,
Һәр тугърыда тигезлектә гомер сөргәч,
Каты җилләр, давылларда бергә була,
Көз көнендә кышка каршы бергә сула.

(Татар шигърияте: XX гасыр башы /
төз. Зөфәр Рәмиев. — Казан: Мәгариф,
2004. — Б.188-189.)

[1] Манигъсыз — каршылыксыз
[2] Рәфыйк рәфыйканың — иптәш иптәшнең (ягъни ире хатынының)



СӘНГАТЬ

Әй, дөнья, бер балаң бит мин;
Миңа тормыш җырларының
Барысын да
Җанга үз итәсе…

Рәдиф Гаташ

НӘҖИБӘ ИХСАНОВАГА 75 ЯШЬ

УЙНАП УЗГАН ГОМЕР

ЛУАРА ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты,
Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрының музей мөдире

«...Аның иҗатын беркемнеке белән дә чагыштырып һәм бутап булмый. Күпме артистлар иҗат иткән 100 еллык театр тарихында Нәҗибә апаның үзенә генә хас урыны бар. Яңалыктан курыкмаучы актриса ул».

(Театрның баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев)

Быел Камал театрының мәшһүр сәхнәсендә күренекле артистларыбыз — щепкинчыларның 75 яшьлек юбилейлары башланды. «38 нчеләр»нең түгәрәк еллары... Сәнгатьнең һәм сәхнәнең тылсымын раслап, яраткан эш белән шөгыльләнүнең матур нәтиҗәсен исбатлап, Ходай биргән игелекле талантны оста файдаланып яшиләр алар; һаман рольләр уйныйлар, гастрольләргә йөриләр, кыскасы, тулы канлы тормышта кайныйлар.

Хәер, үз эшен шулкадәр яратып, бирелеп, җаваплылык тоеп башкаручы сәхнә остасы Нәҗибә апаны мин баш табибә яисә мөгаллимә, я берәр җитәкче итеп тә күз алдына китерә алам кебек (табигый итеп уйнаган рольләренең дә тәэсиредер инде), чөнки нәкъ бу һөнәрләргә фарыз булган таләпчәнлек, җитдилек, һәр вазифаны, йөкләнгән эшне җиренә җиткереп үтәү таланты да бар анда. Мөнәҗәтләр әйтү остасы булып танылган апасы кебек, бөтен күңеле белән инанып һәм ышандырып вәгазь сөйләүче затлы остазбикә дә була алыр иде ул — чөнки сүз сөйли белә, җөмләсенең, халык әйтмешли, «атаанасы» бар, зирәк фикерле. Соңгы елларда дөнья күргән «Уйнап узган гомер» дигән китабы белән Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәҗибә Ихсани күз алдыбызда тагын да күтәрелде — ул язучы да икән, ләбаса. Узган гомер хатирәләрен, иҗатташ дуслары, күренекле затлар турындагы истәлекләрне үзенең каләм осталыгы белән баетып, тәэсирле мизгелләрен тотып алып, укучыга җиткерә алуы, һәр уңайдан үз фикерен-карашын белдереп, уйланып, анализ ясап, нәтиҗәсен үреп бара белүе дә сокландырды. Ирексездән: «Кеше уйланып яшәргә тиеш, буш, эзсез узмасын тормышның бер көне дә», — дип, аныңча фикерли башлыйсың... Китап тирән эчтәлекле. Үз рольләре — уйналганнары, уйналмаганнары турында үз фәлсәфәсе. «Ничек Шәмсегаянны уйныйсым килгән иде, насыйп булмады, үкенеч. «Өч аршын җир» спектакленә репетицияләр дә башланган иде, ләкин эш «өстәгеләр» тарафыннан туктатылды. Без заман корбаны булдык. Еллар

узып, Аяз Гыйләҗевнең бу әсәре рөхсәт ителгәндә, олыгайган идек инде», — дип уфтана ул... Яшьлегендә сәхнәдә Галиябану булып җырлыйсы, самими авыл кызының саф мәхәббәт хисләре белән янасы килгәнен дә яшерми... Нишлисең бит, һәркемнең тормышка ашмаган хыяллары кала — сәхнәдә бигрәк тә... Әмма, мәсәлән, «Акчарлаклар» (Ш.Камал) спектаклендәге Газизәсе белән ул бу бушлыкны тулыландыргандыр дип ышанасы килә: аның «Акчарлаклар» җыры, Гарифка булган тәүге тирән хисләре һаман хәтердә...

Әйе, сүз кодрәте булган кеше, теләсә, каләм дә тибрәтә ала. Нәҗибә апа белән күп очрашуларда — мәктәп, институтларда, музейларда, радио, телевидениедә яше-карты алдында чыгыш ясаган чакларда — аның көтелмәгән сорауларга — фәлсәфиенә, сәясиенә, четереклесенә — яшен тизлеге белән мәгънәле җавап табуына, ихласлык һәм әдәби матур сөйләм белән тыңлаучыларга җиткерә белүенә гел сокландым мин.

Н.Ихсаниның 50 ел буе репертуардагы күп әсәрләрдә уйнавы, йөзләп образ тудыруы — аның үзенчәлекле талантында, бөтен кыяфәтенә чыккан тырышлыгында. Тырышлык ана сөте һәм яшьли хезмәт белән кергән алар гаиләсендәге җиде балага. «Әтиәни белән бергә таңнан йокыдан тора идек, — ди Нәҗибә апа. — Йорт эше, колхоз эше...» Өй идәннәрен генә түгел, ишегалдына сукмак итеп җәйгән такталарны да сап-сары итеп юып куя торган булган ул. Апалары, сеңелләре дә шундый уңган аның. Ата-ана тәрбиясе аларда исемнәреннән үк башлангандыр. Гади авыл кешеләре, динле, иманлы Гыймаделислам абзый белән Миңлеямал апа бик мәгънәле, акыллы исемннәр куша белгән балаларына. Бәһиҗә (гүзәл, яхшы мәгънәсендә), Хәниф (туры күңелле), Галия (олы, бөек), Нәкыя (чиста, пакь), Нәҗибә (тәрбияле, затлы), Хәния (миһербанлы), Роза (чәчәкләр патшасы — гүзәллек билгесе). Галимнәр исемнең баш миенә ничек тәэсир итүен билгеләгәннәр, ди. Нинди исем ишетүенә карап, кешенең гамәле дә шуңа яраклаша башлый икән. Нәҗибә апаның туганнары барысы да үз исеменә лаек һөнәр сайлаган һәм игелекле гомер кичерәләр.

...Шундый кешеләр бар: гомер узган саен алар яшь чагыннан күпкә сөйкемлерәк, затлырак, яктырак күренә башлый. Тормыш тәҗрибәсе, укымышлылыгы, рухи югарылыгы күзләрендә, йөзләрендә гади чибәрлектән өстенрәк бер күркәмлек белән балкый. Еллар гүя аларны картайтмый да, ямьсезләми дә, киресенчә, яшәртә, чөнки күңелләре заман белән бергә алга омтыла. Нәҗибә апа турында мин нәкъ шундый фикердә.

Ул — сәхнәдәге самими, ихлас гадилеге белән күңелләрне яулаган артистка. Мин мәктәп укучысы идем әле. Телевизордан караган «Көзге ачы җилләрдә», «Күзләре нинди иде» кебек беренче спектакльләр истә калган. Яңа гына Мәскәүдән укып кайткан яшь-яшь Н.Ихсанованы беренче күрү. Бу миңа киләчәк юлны билгеләү, балачак хыялымны тормышка ашыру өчен, бер мөһим роль уйнады, өмет, этәргеч биргән иде. Ник дисәң, артистларны буй җитмәс югарылыкта, күз явын алырдай чибәр булырга тиеш дип уйлап йөргән авыл баласына (клубка курчак кебек матур Җәвәһирә Сәләхова, Венера Шәриповалар килгәне бар иде, ә газета битләрендә гүзәлләрдән гүзәл Фатыйма Ильская, Галия Булатова, Шәхсәнәм Әсфәндияроваларны күрә, яңгыравык, театраль матур пафослы тавышларын радиодан ишетә идек) Н.Ихсанова дигән яшь артистканың үзебез төсле гади авыл кызы булып күренүе, бик якын, таныш тоелуы бу томанны таратты, җилкендерде. Һәм унны бетергәч, мин театр юлын

«Ак чәчәкләр» (Г.Әпсәләмов) – Гөлшаһидә, Мансур ролендә – Ә.Шакиров, Бала ролендә – Әлфия Миңнуллина

«Чамасына күрә чарасы»нда (В.Шекспир) – Марианна

сайладым, Нәҗибә апага чынлап та рәхмәтлемен. Әнә шулай тормышчан, табигый, чын халыкчан булуы белән кадерле миңа артистканың иҗаты. Марсель Сәлимҗанов әйткәнчә, миллилеге белән, шагыйрьләрне, шигъриятне аңлаучы шигъри җаны белән дә хөрмәткә лаек ул. Спектакльнең тулаем уңышы өчен янучы режиссёр кемнең кеме дип түгел, әнә шулай зур хәреф белән языла торган таланты, тырышлык хакына роль бирә артистларга.

Нинди генә халәттә күрмәдек инде без артистканы сәхнәдә. Тыйнак, сабыр, кыюсыз татар кызлары, тырыш, уңган чая авыл киленнәре, чын йөрәктән өзгәләнеп, бәргәләнеп сөя белүче хатыннар, ак халатыдай пакь күңелле шәфкать иясе Гөлшаһидә һәм Зифа, Миләүшә кебек зыялы ханымнар («Ак чәчәкләр», «Зифа», «Миләүшәнең туган көне»), Гөлфинә кебек киң күңелле, ягымлы, бәхетле аналар («Әниләр һәм бәбиләр»), Әлмәндәр килене кебек «илдән аерым» үзенә бер кызык корткалар («Әлдермештән Әлмәндәр»), усал, «әрем телле» Сабиралар («Татар хатыны ниләр күрми»), заман чуалышында югалып калган бичара Хәбирә әбекәйләр («Сөяркә»), чая, батыр, нәсел-нәсәбен дилбегәдә тотып, гореф-гадәтләр өйрәтүче мишәр түтие Асимә («Йөрәк маем»), йөз яшьлек керәшен карчыгы Әүдәки («Гөргөри кияүләре»), коеп куйган чын рус әбие Мария («Илгизәр+Вера»), тагын бер гади авыл хатыны кибетче Мария («Авылдашлар, акча кирәк!»), тотнаклы, укымышлы аристократкалар, төрле холыктагы абыстайлар, нәзакәтле Шекспир героинялары... Әнә шундый танымаслык төрле ул Нәҗибә апа сәхнәдә. Рольләренә карап гүзәл һәм ямьсез күренүдән дә курыкмый торган илһам кешесе.

Бу буынның иң күп рольле артисты бугай ул. Ире драматург булганга гына түгел — беренче көннән шулай. 1961-1967 елларда (ягъни әле режиссёр М.Сәлимҗанов Туфан Миңнуллин әсәре буенча куйган беренче спектакль «Миләүшәнең туган көне»нә кадәр)

«Әниләр һәм бәбиләр» (Т.Миңнуллин) – Гөлфинә, Валентина ролендә – А.Гайнуллина



«Йөрәк маем» (Т.Миңнуллин) – Асимә

Н.Ихсанова инде 20 зур роль уйнаган! Япь-яшь килеш әбине дә уйнаган — тырышкан. Кәефе киткәләгән, әлбәттә, бераз, әмма режиссёр кушканга каршы килүче актриса түгел шул ул! Дәртле, көчле гәүдәгә картлык хәлсезлеге бирә белү, ышандырырлык табигый пластика табу — бу да сирәк талант. Нәҗибә апа тормышта да күпкырлы: җитди, хәтта кырыс та шикелле үзе, ә менә театр сабантуйларында капчык күтәреп, «көрәшеп», көлеп, шаярып та ала белә. Тормышның һәр ягын үзе тоеп, сынап карарга омтыла, шуннан тәм таба, күрәсең, артист җаны.

Әтисенә охшаган кыз бәхетле була, диләр. Хактыр. Нәҗибә апага бала чактан шулай юраганнар һәм дөрес: Нәҗибә апа бәхетле хатын, бәхетле актриса. Ирле, гаиләле булып, акыллы кыз бала үстерүе (Әлфия — танылган журналист), инде оныгының баласын да рәхәтләнеп сөя алу аңа хатын-кыз бәхетен китерсә, иҗат белән шөгыльләнү — актриса горурлыгы бирә. Ата-бабалардан калган йолаларны үтәп, кыйблага йөз тотып яшәве күңелен юата. «Заманалар кысты бит, юкса кечкенәдән әни янына намазга баса идем», — ди ул, «денсез» үткән совет чоры өчен ачынып.

Беренче тәпи баскан, кадерле сабый чагы узган 20-30 йортлык кына ямьле туган авылы Яңа Ташлыяр (Азнакай районы) җир өстендә күптән юк инде. Күңелен сызлаткан иң әрнүле уе ул аның. «Көн дә авылымны күз алдына китерергә тырышам, басу-кырларны, туган нигезне, зиратны, бәрәңге бакчасын, ишегалдын, күрше-тирәләрне, авылның һәр кешесен кабат-кабат күзаллыйм, искә төшерми торсам, онытырмын диеп куркам, кайтып карарга юк бит инде ул», — ди Нәҗибә апа. Шуңа күрә якташлары — Азнакай районы хакимияте җитәкчеләренең зурлап искә алып торуы, күренекле артистканы беренчеләрдән булып районның мактаулы кешесе итеп сайлавы аны кош тоткан сабыйдай сөендергән иде...

Язучы һәм артист гаиләсе... Ярты гасыр Туфан Миңнуллин кебек талантлы әдип, гакыллы җәмәгать эшлеклесе белән тормыш юлында бергә

Тормыш иптәше Туфан Миңнуллин белән

бару артистканың тынгысыз, кызыксынучан табигатенә уңай йогынты ясаган, билгеле. Иҗади уңышларында иренең дә өлеше бар икән — бары тик афәрин аларга! Туфан абый казанышларында да Нәҗибә апаның роле кечкенә түгелдер. Әйе, тормыш дигән күппәрдәле спектакльнең «гаилә бикәсе» дигән иң зур ролен дә Нәҗибә ханым әйбәт башкарды. Бик юксына ул Туфанын...

— Без бит бербөтен булып беткән идек инде, шул бөтен кителеп төште, аның урынын, ул бушлыкны һични белән тутырып булмый. Яра инде ул. Ул мәхәббәт тә, ирем дә, кызымның әтисе, оныкларымның бабасы, иптәш, юлдаш, юлбашы, идеологым да иде... Һәрберебезгә, бөтен халкына да җитә иде аның җылысы. Бөтен нәрсәне яхшыга үзгәртәсе килеп яшәде, турысын әйтте. Алай тиз генә үзгәрми шул дөнья, йөрәгенә җыеп барган инде барысын да... Уйласам, гел елый башлыйм... Оныгымның кызы Саҗидә белән юанам. Ул минем иң актив, иң яхшы әңгәмәдәшем, бөтен нәрсә белән кызыксына, ни теләсә, шул уенны уйнап, онытылам. Театрда әле рольләрем бар. Уйныйсы спектакльләремне алдан әзерләнеп, җыенып, җыелып көтеп торам. Сәхнәдә бит яшәргә кирәк, аңа көч кирәк.

Әйе, әле дә янында Әлфиясе, кияве бар — алар игътибарында, алар кадерендә яши ул һәм дә яраткан тугры тамашачысы мәхәббәте көч бирә Нәҗибә апага бүген.

— Җир йөзенә килгәч, тиешле булган эшләрне үтәдем кебек. Олыгаюга тыныч карыйм. Балалар өчен дә күңел тыныч әле. Алар ярдәмчел, милли рухлы. Шулай да күңел башканы уйлап борчыла: төрле хәвеф-хәтәренә кайгыра, яхшысына сөенә. Радио, телевидение, газеталардән ни хәбәр килер дип, барысы белән кызыксынып торам, җанга ял бирмим. Тотрыклы, имин генә булсын инде җир һәм җиргә килгән һәркемнең тормышы, язмышы.

...Кечкенә чагында ике тапкыр үлемнән калган Нәҗибәгә әнисе: «Озын гомерле булырсың, балам», — дигән. Юш килсен юравы! ■

АЛЬТЕРНАТИВ... ЯКИ КИНӘСЕЗ КИНО*

ӘХТӘМ ЗАРИПОВ,
режиссёр,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Менә шундыйрак эчтәлекле әңгәмәләр була иде күршем белән очрашкан чакларда.

Ләкин беркөн безнең очрашып сөйләшүләр өзелде, күршем бакчасына җимеш җыярга да килми башлады. Күңелгә төрле уйлар килеп, кеше югалуның төрле сәбәпләре булу ихтималы куркытса да, әзләвем күршеләрдән сораштырудан узмады. Алар да шул... миннән артык белмиләр иде.

...Бу язмада китерелгән диалоглар стенографик төгәллеккә дәгъва итмиләр. Алар төрле очрашулардагы сөйләшүләрнең ни турында баруына, ничегрәк узуына ишарәләр генә. Һәрхәлдә, күршем белән әңгәмәләр кызыклы уза иде. Шуларда яңгыраган яки ялтыраган кайбер фикерләр белән уртаклашып, газета-журналларда мәкаләләр дә бастырдым хәтта. Бу язмамда аларның кайберләре очраса, әйтер фикерем юклыктан түгел, ә элеккеләренә резонанс-яңгыраш булу-булмавына икеләнүдән. Мәкалә язучының көткәне — резонанстыр. Кайберәүләр ялгыша: мактау көткәндә хурлаудан да яман нәрсә юк, имеш. Иң яманы — үзеңә карата ваемсыз-игътибарсызлык.

Борчылганым — кешеләрнең берберләренә илтифатсызлыгын күрү. ...Ләкин ил, тормыш минем борчылуларга карамый, үз кануннары буенча, үз ярларында ага бирә, гомер уза. Илдә, үтәлмәсәләр дә, күп карарлар кабул ителә, вәгъдәләр бирелә, шартнамәләр төзелә, сайлаулар уздырыла. Сугышалар, узышалар, алдыйлар, алданалар; җырлыйлар, сөйлиләр, макталар, мактаталар. Язалар, сызалар; пешерәләр, төшерәләр. Ни генә юк!

Сирәк булса да фильмнар да төшерелә. Алар турында фикерләрем белән уртаклашып барырга тырышам. Бер кәлимә сүземнән күңелемдәге аңлаган күршем генә юк, аны юксынам, сораштырам.

...Бакча ширкәте кассиры әйтә: «Елныкын елда взносларын түләп бара — исән ул, өендә генә эшләп утырадыр, сурәт ясаучы бит ул», — ди. Рәссам икәнен беләм. Күргәзмәләрдә күренгәне юк, газета-журнал битләрендә дә исемнәре очрамый. Ни булыр?

...Гомер узып баруны искәрткәндәй, кинәт кенә абый үлде. Аны җирләшергә дип авылга кайтсам, кемдер әйтә: «Мәрмәр таштан һәйкәл эшләүче таныш рәссам бар, хакны да күпме бирсәң — шуңа риза», — ди. «Һәйкәл эшләүче булгач, сынчы була бит ул, рәссам түгел», — дим. Шулай да телефон номерын язып алдым.

*Дәвамы. Башы журналның 1, 2 нче саннарында

Телефоны булгач — булды инде: киттем абзый каберенә һәйкәл эшләтергә сынчыга!

Барып керсәм... — ул!

...Йола буенча күрешү, хәл сорашудан, чәйдән соң сүзне сүз тартты.

— Югалмадым, дисең инде алайса?

— Ниһаять, мин дә үземне таптым кебек.

— Сынчыга әверелүне әйтәсеңме?

— Рәссам булып ныгуымны әйтәм. Сынчылык ул миңа рәссамлыгымны ташламас өчен бер кәсеп кенә иде.

— Хәзер?

— Язам! Әнә — кара!

— Заказлар бармы?

— Гомергә дә заказ буенча эшләмәдем.

— Йөрәк кушуы буенчамы?

— Нәкъ шул кирәк булганга! ...Бу эскизлар «Тарихыбыз сәхифәләреннән» триптихыннан кенәз Дмитрий белән Мамайның килешү шартнамәсенә кул кую моменты...

— Пәрдә артындагылары кемнәр?

— Литва короле Ягайло, ә тегесе Тверь кенәзе.

— Шундый килешү булганмыни?

— Килешүләре дә күп, хыянәте дә. Мин хыянәтләргә тимим. Мине татарлар белән урысларның...

— Дуслыгы кызыксындырамы? Комедия!

— Нигә шундый купшы сүзләр?

— Килешү төзелгәч, дуслык булмый нәрсә була?

— Без кешеләрне дуслар-дошманнарга, кирәкле-кирәксезгә, файдалы-файдасызга, акка-карага гына аерырга...

— Өйрәнгәнбез.

— Дөньяда төсләр күп булган кебек, кешеләр дә файдалы-файдасызлардан гына тормый. Человек — звучит гордо!

— Демагогиягә дә өйрәнгәнсең, күрәм...

— Синнән! Син дә бит тормышта булганны, сәнгатьтән күргәнеңне, алганыңны сөйлисең генә. Син — фиксатор! Иҗат турында сөйләнүдән иҗатка күчтем мин. Син минем бер остазым булдың. Әнә кара: Олуг Мөхәммәт Василийны тәхеткә утырта, бусында патшаны татарлар белән дуслыгы өчен туганнары сукырайта.

— «Тёмный»га әверелдерә.

— Рәсәй тарихы — тёмный эшләр тупланмасы ул.

— Без шул тарихны агартучылармы?

— Укы — бу «Культура» газетыннан кисеп алынган: «Лауреатами Государственной премии России за 2007 год стали ... коллектив сотрудников заповедника на Куликовом поле», — дигән. Тарихны агартумы бу?

— Белмим инде...

— Белергә теләмибез! «Прошедшее нужно знать не потому, что оно прошло, а потому, что уходя, не умело убрать своих последствий...» — дигән урыс галиме. Так что убираем последствия. «Белмим» дип яшәү — ул упкынга юл.

— Син мине гаҗәпләндерәсең.

— Тормыш — гаҗәп. «Бүген сөйгән нәрсәбезгә нәфрәт туа иртәгесен», — дигән Кюхельбекер.

Тик нәфрәт колы булып яшәмәскә кирәк.

— Гомумән, кол булмаска кирәк!

— Килешәм. Бу синең үсешең.

...Кичтән башланган әңгәмәбез иртәнгә кадәр дәвам итте. Мин җиңелеп кайтып киттем. «Дөрес яшибезме?» — дигән сорауга җавабым булмау мине изә, уйларымны чуалта, гамәл кылулардан мәхрүм итә иде. Шулай аңкымиңке гомер уздырганда, «Орда» дигән фильм чыгуы турында ишетәм, оныгым ярдәмендә аны карауга ирешәм.

Фильм оныгымны сокландырып таң калдырса, мине татарларның әшәкелекләрен күрү тәмам хәлсезләндереп, аяктан екты. Шул егылудан әле хәзер дә мантый алмыйм. Андагы ялганны уйлап чыгарырга һәм шуңа ышандырырга талантлы булу гына җитми. Фикердәш рәссамыма шалтыратам.

— Котлыйм! — ди ул миңа. — Йөзеңә төкерелү белән тәбрик итәм.

— Кыланмасаң иде...

— Бәлки шушы хурлыктан соң уянырсыз?

— Уянгач, беренче эшебез ни булырга тиеш?

— Альтернатив фильм төшереп, аны Рәсәйдә генә түгел — бөтен дөньяда күрсәтү!

— Аңламадым...

— Ә син әүвәл Карамзинның «Россия дәүләте тарихы»н өйрән. Шуннан соң сөйләшербез... Ә хәзер... Хәзергә җитте. Мине эшемнән аерма. Бу фильмга җавапсыз калу — элмәкне үзең эзләп киюгә бәрабәр.

Шулай итеп «Орда» фильмы мине тарихка утыртты, Рәсәй дәүләте тарихына. Ниләр генә юк анда?!

Барысы да Рәсәй дәүләте мәнфәгатьләрен күздә тотып, буяп, шомартып ясалган тарихи-әкияти сәхифәләр.

...Куликово кырында 1380 елның 8 сентябрендә булып узган сугыш турындагы әкият-легендаларның әледән-әле яңартылып торуы кемгә кирәк?

Алтын Урда империясенең 1360 еллар башында икегә аерылып, Идел уң ягындагы биләмәләр «төп йорт» Урда-Сарай хакимлегенә каршы фетнәчел көчләр йогынтысында булуын Европа тарихчылары ачыктан-ачык язып калдырганнар.

Дмитрий Иванович Мамайны «җиңүе» белән Алтын Урдага ярдәм итә. Тик бу эшенә тиешле бәһа көтмәстән, ягъни Куликово кырыннан кайтышка ук, Мәскәү, Алтын Урдага ясак-налог түләүдән туктый, аннан бәйсез булуын белдерә, шулай кабат үзенә каршы яу белән килергә мәҗбүр итә, Мәскәү кенәзлеге тагын буйсындырыла. Исеменә «Донской» кушаматы өстәгән Дмитрий элекке кебек үк ясак түли. Урда илендә мондый эшләр тәртип бозучыны тәртипкә китерү эшләре итеп кенә каралганнар.

Бу вакыйгалардан соң да Алтын Урда озак еллар яши, таркалуы Рус кенәзлекләренә җиңелүдән түгел — империяне бербөтен итеп тоткан яшәү кануннарының заман-чор таләпләренә җавап бирми башлавыннан, яшәү концепциясе булмаудан. Таркалуга йөз тоткан Урда империясе акрынлап сүнү юлын 1502 елга кадәр дәвам итә. Шулай икәне бәхәссез факт булса да, 1380 елдагы Куликово сугышы әле һаман рус гаскәрләренең татар гаскәрләрен «җиңү» сугышы дип билгеләп үтелә.

Чынлыкта исә Мамай гаскәре татарлардан тыш, күпчелеге яллаган — черкеслардан, яһүдиләр, әрмәннәр, греклардан һәм Кавказ-Кара диңгез тирәсендә яшәүче төрле милләт вәкилләреннән торган. Союзниклары белән килешү буенча, Мамайның Мәскәүгә сәфәре соңракка планлаштырылган була. Рязань кенәзе Олегның ике якка да хезмәте, дөресрәге, хыянәте нәтиҗәсендә Дмитрий, гаскәр туплап, Мамайга көтелмәгән һөҗүм оештыруга ирешә. Нәтиҗәсе — 110 мең сугышчысын югалтып, калган 40 меңе белән кайтырга чыккач, юлда очрашкан Ягайло армиясе тарафыннан үзе дә тар-мар ителә.

«Куликово кырындагы җиңү», диләр, «Невадагы», «Чүл күлендәге», «Полтавадагы җиңү», диләр. Җиңүләр бик күп... «Җиңгән» Дмитрийны, кырылыш тынгач, кемнең җиңгән яки җиңелгән икәнен эт тә белмәслек шомлы тынлыкта мәетләр арасыннан табып алалар. Һушына килгәч, олуг кенәзнең беренче сүзе сугыш әләменең язмышы мәсьәләсендә була.

Аңа кара флагны эзләп табып китерәләр. Шуннан соң Мамайдан калган атсыз арбаларны талау башлана. «Җиңү» игълан ителә.

Рус милләтеннән булган укымышлы, үзләрен интеллигентка санаган кешеләр белән Куликовога кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышканда, алар, гадәттә, темадан качарга тырыш-

салар да, күз карашлары очкынлана, үзләрен өстен тою, тәкәбберлек сыйфатлары бәреп чыга.

Янәсе, нигә кирәк ул бер үк илдә әллә ничә телдә сөйләшеп, берең — чиркәүгә, икенчең мәчеткә йөреп, бер Аллага төрлечә табынулар? Алла бер икән, аңа табыну да бер үк төрле булудан кемгә нинди зыян? Гомумән, нигә кирәк төрле-төрле телләр, йолалар, гадәтләр, ягъни, җыеп кына әйткәндә, милләтләр? Рудимент?! Әгәр дә бер үк төрле тойгыларны, хисләрне, фикерләрне төрлечә әйтер өчен генә булганда, тизрәк алардан котылырга омтылу хәерлерәк түгелме? Хәерлерәк түгел шул! Төрле телләр, төрле йолалар һәм, ниһаять, төрле мәдәният — ул рудимент түгел, ә чиксез күптөрле дөньяның төрлечә чагылыш формасы.

Дөнья түгәрәк, дөнья бер дисәк тә, кешеләр аңа төрле яктан, төрле ноктадан карый, төрлечә күрә, күреп тануыннан чыгып, сүзе, теле формалаша, холык-фигыле ныгый, милләт булып оеша.

Һәр милләтнең дөньяны танып белүе үзенчә. Һәр милләт оешуыннан алып язмыш аңа билгеләгән миссиясен үтәп яшәргә тырыша.

Үзләрен җиңүче милләт хәдимнәре дип санаучыларга тарихи хакыйкатьнең бик кечкенәсен тану да зур ташламага бару буларак бәһаләнә. Милләтләрне «сортларга» аеру буенча ачыктан-ачык гамәлләр сизелми. Барысы да бик сак, кинаяләр аша гына суктырыла. (Халык санын алу кампанияләрен хәтерлик.)

Ә елганың чишмә башы шул 1380 елдан...

Аптыраган, йөдәгән кенәз Дмитрий киңәшкә Радонежскийга килә.

Игумен аңа: «Дошман җиңелүгә дучар булачак, ә сиңа Ходайдан ярдәм киләчәк, син татарларны җиңәчәксең!» — дип фатихасын бирә. Кимендә 150 мең сугышчыдан исән калганнарының бик азы гына кире әйләнеп кайткач, игумен кенәздән гафу үтенгәнме? Безгә билгеле кадәресе — бүген Сергей Радонежский да, Дмитрий Донской да изгеләрдән санала. Болары инде парадокс.

Чиркәү кенәзләрне якласа, кенәзләр чиркәүне сәясәт акцияләрендә файдаланалар. Тандем!

Православие руханилары ничә яугирен, ничә кенәзен «изге» дип канунлаштырды икән? Күбесен! Ә безнең ислам динендә хезмәтне кәсепкә әверелдергән имамнарыбыз мәмләкәт таркалмасын өчен ни кылганнар? Бармы телгә алырлык эшләре? Тарихта да, халык иҗаты әсәрләрендә дә андый фактлар юк. Мөнбәр әһелләренең күбесе «сарай сандугачы» булып хан табынында урын алуга омтылган, аларга үгез үлсә ит, арба ватылса, утын булган. Төп гамәлләре — фидая, сәдака җыеп утырудан узмаган.

Ә чиркәү әһелләре акыл белән, максатчан яшәгәннәр.

Татар белән сугышучы яугирләр гасырлар буена изгеләргә тиңләнә. Шулай бөек, мәрхәмәтле русларга дошман мәкерле, явыз татар образы формалаша. Хәзергәчә шулай.

Болар барысы да Сергей Радонежский «фатихасы»ннан башланган эшләр нәтиҗәсе.

Әгәр ул Алла каршында җаваплылыкны үз өстенә алып, татарларга дошман мөһере сугып «фатиха» бирмәсә, Дмитрий сугышып яшәүне кәсебенә әверелдергән яуга каршы ерак сәфәргә чыгарга җөрьәт итәр идеме?

Ләкин бу хәл русларга карата һич тә тискәре мөнәсәбәт сакларга сәбәп булырга тиеш түгел. Алар үз милләтенең бәйсезлеге өчен көрәшкән. Сүз алар күңелендә сакланучы дошман татар образы турында, шуннан ничегрәк котылу турында.

Яра төзәлә, гариплеккә ияләнәсең, сүз онытыла, ә менә образ... Образ — озын гомерле икән. Аны күңелдән суырып алып та, карарлар кабул итеп, онытырып та булмый.

Шекспирга мөрәҗәгать итсәк, Ричард IIIне яклап, исемен аклау өчен көрәшүче оешмалар хәзер дә эшли, диләр! Шулар өстенә тарихта билгеле кайбер фактлар Ричардның юньле кеше булуын раслап, аны аклау ягына шаһитлык итәләр. Әмма Шекспирның иҗат җимеше булган Ричард III образын күңелләрдән алып ташлый алмыйлар. Ул драматург ничек язган, шулай яши, яшәячәк образ, әдәбипоэтик образ, тарихи шәхеснең үзеннән гомерлерәк. Дмитрий Донской — гасырлар буе шомартылучы образ ул. Куликово сугышы үзе дә образ. Чиркәү тудырган образ!

Хәтәр бар җирдә гел татар кирәк булса да, «татар бар җирдә хәтәр бар», дип аны каралтып күрсәтү нәтиҗәсендә, руслар күңелендә татар һаман дошман булып яши. Ягъни дошман образы!

Ни кызганыч, безнең милләтнең Александр Невские да, Дмитрий Донское да тудырылмаган...

Ә бит тапкыр сәясәтчеләребез дә, батыр сугышчыларыбыз да, полководецларыбыз да булган. ...Тик аларның берсе дә милләтне берләштерү символы дәрәҗәсенә күтәрелеп, образга әверелә алмаган.

Моңа милләтнең Радонежскийга тиң рухани атасы юклык төп сәбәп дисәк тә, мәчет манарасыннан карап, мәхәлләдән ары манзара күрмәү дә хәлиткеч роль уйнагандыр.

Инде нихәл итмәк кирәк — бик күпне күрми калган безнең хәзрәтләребез. Юкса милләтебез тарихында исемнәрен йолдызларга кушарлык затлар бар бит. Әйтик, үзе бер дәвернең сыйфатын билгеләгән олы шәхес — Казан ханлыгының беренче ханы Олуг Мөхәммәтне генә алып карыйк. Бармы рус кенәзләре арасында киң күңеллелеге, кыюлыгы, сугыш тактикасын камил белүе, тәвәккәллеге, фидакарьлеге белән аңа тиңләшер зат? Юк! Ул бит өч мең чамасы яугире белән мәскәүлеләрнең кырык меңлек гаскәрен җиңә, олуг кенәзен әсир итә, хыянәте өчен аңа җәбер-җәфа күрсәтми, гафу кылып, иленә кайтарып, кенәзлек итү урынына кабат утырта. Нинди бөек бабабызның әдәбиятта да, сәнгатьнең башка төрләрендә дә шәхесенә тиң (адекватный) образы юк.

Беренче карашка бик гади генә булып тоелса да, гаять җитди мәсьәлә бу. Шакирҗан Юныс улы Мөхәммәтҗановның «Александр Матросов»ка әверелүе дә, җиңү байрагын Рейхстаг манарасына беренче булып Гази Заһитов кадаса да, Герой исеме Егоров белән Кантарияга бирелү дә һаман шул милли мәсьәлә чишелмәүдән килә. Әгәр саный китсәң, татар булган өчен генә кимсетелү фактлары тормышта да, әдәбият-сәнгать өлкәсендә дә бихисап.

«Хованщина» операсында: «О, святая, Русь! Не скоро ржавчину татарскую ты смоешь!» — дип җырлыйлар. Ник «не скоро»?

Әгәр тутыкны, чынлап та, бетерергә кирәк икән — авыр эш түгел бит ул — бетерик соң! Бергәләп бетерик! Димәк, тутык кемнәргәдер кирәк.

Сергей Радонежский 1380 елның 18 августында кенәз Дмитрий Ивановичка биргән «фатиха» Мамайга сугыш белән барырга бирелгән фатиха гына түгел. Тарафдарлары изге зат дип саналган игумен «фатихасын» руслаштыру сәясәтенең һәм империячел сугышның башлануына фатиха дип карарга кирәк. Бу исә безнең хәзерге Конституциядә тыелган гамәл. Әйе, империячел сугышның старты Куликово кырында!.. Сугыш игълан ителгән, әмма «отменять» ителмәгән. Урданы — патшалар, патшаларны — советлар алыштырса да, империячел сәясәт төсен, кыяфәтен генә үзгәртә. Барысының да нигезендә дини һәм милли нетерпимость ташы — игумен салган таш ята.

Ахыры киләсе санда

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

РӘДИФ ГАТАШ

(30.03.1941)

***

«Мәхәббәттән башка берни белмисең син,
күрмисең син...»
Шулай диләр.
Юк, мин беләм,
Мәхәббәттән башка да мин күпне күрәм:
гөл керфекләре тибрәнеп ни аңлата?
Сандугач ник җыр ярата? —
Әйтеп бирим.
Мин йолдызлар телен беләм...
Искән җилләр нәрсә сөйли,
яшь топольләр нәрсә көйли,
бәхет кайда күбрәк үсә,
кайгының ник көне бетә — барсын беләм.
Мин тормышны бөек иткән көчне
Мәхәббәттә —
Илгә, җиргә Мәхәббәттә күрәм.
Һәм яшермим: сөям, сөям!
Мине:
«Хисләреннән шашкан», — дисез, әйеме?!

Бер сүзем юк...
Мәхәббәтнең
Мәҗнүн исемендәге премиясен
бу ел өчен миңа бирегез, яме?!

---

*Шагыйрь Рәдиф Гаташның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

ӘДӘБИЯТ

Гадиерәк хәзер идеаллар да,
Матильдалар түгел я Сандлар:
истә күбрәк Сәмитова апа,
Мозаффария, Гыйффәт туташлар.

Рәдиф Гаташ

РАБИТ БАТУЛЛАГА 75 ЯШЬ

КАРАШ ҖИТМӘСНЕ КОЛАЧЛАГАН ӘДИП

ДАНИЯ ЗАҺИДУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

БЕР ӘСӘРЕ БЕЛӘН ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА КЕРЕП КАЛГАН, ӘДӘБИ ПРОЦЕССНЫ ҮЗГӘРТКӘН ЯЗУЧЫЛАР БУЛА. БОРЫНГЫРАК ЧОРНЫ ИСӘПКӘ АЛМАСТАН (МИРАСНЫҢ ГЕЛ ТАБЫЛЫП ТОРУЫ ГАДӘТИ КҮРЕНЕШ БИТ), XX ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ГЫНА ДА КҮПЛӘРНЕ ШУШЫ ИСЕМЛЕККӘ КЕРТЕРГӘ МӨМКИН: АЗСАНЛЫ ШИГЫРЬЛӘРЕ БЕЛӘН ТАТАР ПОЭЗИЯСЕН ТАМЫРДАН ҮЗГӘРТКӘН ДӘРДМӘНД, Г.КУТУЙ («ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» ПОВЕСТЕ), М.ХӘСӘНОВ («ЯЗГЫ АҖАГАН» РОМАНЫ) Һ.Б.

Әинде кайберәүләрнең иҗат хәзинәсен күздән кичергәндә, эзләнүләрнең киңлегенә, төрлелегенә хәйран каласың. Була шундый язучылар: әйтерсең лә үз алларына милли әдәбиятны масштаблы, төрле сукмакларда үзгәртү-үстерү максаты куялар да, шуңа ирешү өчен, барлык көч һәм вакытларын сарыф итәләр! Бу яктан, XX гасыр башы татар әдәбиятында Ф.Әмирханга, Г.Ибраһимовка тиңнәр юк…

XX йөзнең икенче яртысы — XXI гасыр әдәбиятында да андый иҗатчылар аз түгел, алар арасында Рабит Батулланың күпкырлы, күптармаклы әдәби иҗаты аерым бер урын тота.

Тышына диңгез буенда комда утырып торган малай һәм кара эт ясалган китап — Роберт Батуллинның «Исемем минем Дүрткүз» (1966) повесте [1] — мин үскәндә һәр өйдә диярлек бар һәм кат-кат укыла, мәктәпкә барганда-кайтканда аның хакында да сөйләшелә торган әсәр иде. Гадәти, төп вакыйгаларында мәгълүм сюжет: шаян көчекнең туган җиреннән, нәни хуҗасыннан аерылып еракка китеп баруы, андагы маҗаралары һәм кабат таныш ишегалдына кайтып керүе — дөнья мифологиясендәге иң киң таралган «кабат үз урынына кайту» («вечное возвращение») тарихын яңарта. Ләкин повесть үзенең нәни укучысын бу ягы белән түгел, бөтенләй башка сыйфатларына бәйле җәлеп итә: беренчедән, ул әлеге Дүрткүз исемле кара көчек исеменнән язылган һәм авторның уйланмасы уңышлы килеп тә чык-

кан: әсәрдәге дөнья чынлап та көчек «күргәнчә» тудырыла. Икенчедән, аның төп герое Дүрткүз — ярдәмчел дә, батыр да, тугры да, самими дә. Ул үзенең маҗаралары хакында укып утыручы балаларга да кеше холыкфигылендә шушы сыйфатларның мөһимлеген аңлатырлык итеп язылган. Татар прозасына оста каләм иясе килүен Р.Батулла шушы повесте белән 1960-1980 еллар укучысына хәбәр итте, җиткерде.

Озак та узмый, 1969 елда яшь язучының «Уйларымны кеше белсен» исемле хикәяләр җыентыгы [2] басылып чыга. Бу китапчыкта алга таба язучы иҗатында әйдәп барачак темалар аермачык күренеп тора. Һәр хикәя бер эзләнү сукмагын хасил итә. Җыентыкка беренче итеп урнаштырылган «Офыклар алсу иде...» (1964) әсәре әтисе сугышта булган малай исеменнән язылган. Әлеге алым авторга сугыш чоры авырлыклары алып килгән борчуларны, кешеләрнең күңелен күтәреп торган өмет-ышаныч хисен самими-якты сурәтләргә мөмкинлек бирә. Гомумән, Батулла иҗатында герой исеменнән сөйләү төп психологизм алымы булып җитешә.

1960 еллар уртасы — татар әдәбиятында яшерен эчтәлек, «эзоп теле» активлашкан вакыт. Шушы елларда шәхес культы фаҗигасен, совет идарә системасының кимчелекләрен, читтә яшәргә мәҗбүр ителгәннәр тарихын яшерен катламда сөйләгән әсәрләр языла. Р.Батулланың «Фасил белән Вәсилә» (1967) хикәясе шушы агымда — кырым татарлары фаҗигасенә, аларның туган җирләре хакындагы мәгълүматны тарихи хәтердә яшереп яшәргә мәҗбүр ителүенә игътибар юнәлтә. Беренче карашка, хикәя бик гади күренешләр турында бәян итә. Ике балалары булган ир белән хатын, хатынның сәламәтлегенә бәйле врачлар кушуы буенча, диңгез буена ял итәргә киләләр. Авылда хокукый яктан мөнәсәбәтләрне ныгытмыйча гына, ләкин матур гаилә булып яшәгән кешеләр читтә паспортка сугылган пичәтнең әһәмиятлерәк саналу күренеше белән очраша. Сюжет барышында очраклы шикелле генә әйтелгән өзек-өзек фразалар, детальләр хикәя буенча бербөтен образга әйләнә — Фасилнең бу җирләрдән куып җибәрелгәннәр баласы булуына ишарә ясый. Фатир хуҗасы Ксенья Тарасовна һәм миндаль сатучы күрше хатын белән сөйләшүләр яшерен сюжетны укучыга җиткерерлек итеп уйланылган. Хикәянең соңгы җөмләсе — «Риза бабайлар коймасы өстендә бер баш күренде. Фасил аның кем икәнен шундук танып алды. Бу — миндаль сатучы хатын иде» («Уйларымны...», 111 б.) — яшерен эчтәлекнең хакыйкать булуын хәбәр итә, тагын хикәягә әйләнеп кайтырга, кабат укырга этәрә һәм, нәтиҗәдә, яшерелгән сюжетны беренче планга чыгара.

Җыентыктагы «Шәйдулла абзый» (1969) хикәясе яшерен эчтәлектә шәхес культы, кешеләрне бер гаепсез «алып китүләр», совет чорындагы идеологик җитәкчелекнең җир кешесенә, үз эшен күзәтүчеләрдән башка да яхшы белә торган гади кешегә зыяны хакында сөйли. Нәтиҗәләр ясамыйча, үз карашын белдерми генә, бары тик Рифкать исемле малайның искә төшерүендә аерым күренешләрне тергезеп, автор укучысына Шәйдулла председательнең җир, кешеләр өчен көнен төнгә ялгап эшләгәнлеген, намуслы һәм миһербанлы булуын җиткерә. Ә инде председатель белән бергәләп авырлыкларны җиңгән авыл кешеләренең печәнне җыйнап бетергән көнне бәйрәм иткән вакытында, сюжетның чишелеш моментында килеп кергән өзек укучы фикерен бөтенләй башка тарафка алып китә: «Победа» әле генә Шәйдулла абый биегән түгәрәк уртасында туктады. Ишекләр ачылды. Вафин шофёры Шәйдулла абыйны чакырып нидер әйтте. Шәйдулла абый, бер сүз дә дәшмичә, машинага кереп утырды. «Победа» сыек зәңгәр төтен калдырып китеп тә барды. Шул китүдән председатель кире кайтмады» («Уйларымны...», 48 б.).

Язучының соңрак, инде совет чоры узгач басылып чыккан «Әйтсәң, конфет бирәм» (1963) хикәясе исә бу теманы яшерен эчтәлектән алып чыга һәм әсәрнең үзәгенә куя. Кайчандыр малай чакта әтисенең күрше яласы буенча харап ителгәнен белгән, бүген инде «үзе эти» булган герой бу куркыныч хәлләрдә аерым кешеләр, куркаклар гаепле икәнне аларның күзләренә бәреп әйтә: «Гаепләмә үткән заманны! Ахмак замана ахмак кешеләрне тудырмый! Ахмаклар ахмак заманны тудыра! Кызыл комач арасына яшермә куркак җаныңны!» [3].

Шулай итеп, инде 1960 еллар уртасында яшь язучы совет чорының идеологик хаталарына, кешеләр тормышын җимергән ялгышларына игътибар иткән әсәрләр яза, аларны яшерен эчтәлектә биреп, укучы фикерен заманның актуаль мәсьәләләренә

юнәлтә. Бу мәсьәләләр инде совет хакимияте мәйданнан киткәннән соң да үзәк проблемаларның берсе төсендә язучы иҗатында сакланып кала. Бер үк вакытта аларның сәбәпләренә, нәтиҗәләренә кагылышлы авторның караш офыклары киңәя бара.

Язучы иҗатын үтәли кисеп барган тема фәлсәфи табигатьле — гомумиләштереп, аны туган җир темасы дияргә мөмкин. Шул темага язылган иң матур әсәрләрнең берсе — «Соңгы чабыш» (1969) исемле хикәядә кешенең зур омтылышлар белән туган җирен яратуы арасында бәргәләнүе турында төп герой Егор исеменнән сөйләп, аның хисләрен укучы күңеленнән уздырырга мәҗбүр итә. Минем хәтеремдә ул 1960 еллар язучысы Батуллага таныш түгел автор Әхнәф Тангатаровның «Өзелде» (1917) хикәясендәге мәхәббәте Настя һәм милләткә хезмәт итү максаты арасында сайларга мәҗбүр татар егете образы белән кисеште. Егорның күңеле дә, бер яктан, шәһәр һәм ил киңлекләренә, андагы дусларына, мәхәббәте Настяга тартыла, ул алардан башка яши алмый. Икенче яктан, туган авыл, әти-әни, җанга газиз урыннар «җибәрми». Язучы биредә ике образны парлы символ дәрәҗәсендә файдалана: поезд һәм ат (әлеге парлы образлар һәм ситуация шулай ук XX йөз башы матбугаты битләрендә калган һәм XXI гасыр башында гына укучыга әйләнеп кайткан Г.Рәхимнең «Ярыш» (1916) хикәясенә аваздаш). Бу хикәядә дә язучының «көчле позициясе» — әсәрнең ахырын оста файдалана белүен билгеләп үтәргә кирәк. «Поезд кузгалып китте. Поезд тизлеген арттыра, арттыра... Җәгүр, бераз хәл алгач, калай кружка алып су эчәргә дип торган иде, тимер юл буенда басып торучы Кашканы күреп катып калды. Кашканың юеш койрыгы асылынган, йөгәне салынган, башы пычрак җиргә тияр-тимәс иелгән.

— Нишләп кайтып китмәде икән ул? Нигә минем арттан килде икән ул? — дип уйлады Җәгүр.

Кашка яныннан үтеп киткәндә, Җәгүрнең колагына зәгыйфь кенә кешнәгән тавыш ишетелгән сыман булды» («Уйларымны...», 25 б.).

Шул рәвешле, язучы укучысына заман тизлегенең, шәһәр тормышы иркенлегенең авылда саклана торган кыйммәтләрне уза баруын искәртә. Ләкин бу күренеш аның герое Егор күңелендә бәргәләнү уяткан шикелле, укучы күңелендә дә сызлану, экзистенциаль сагыш барлыкка китерә.

Шушы темага язылган, әйтерсең, аны дәвам иткән «Көз көнендә» (1963) хикәясе кайчандыр туган җирен, хатыны белән кечкенә малаен калдырып читкә киткән кешенең кайту юлында улы белән очрашу күренешен җанландыра. Хикәянең башлануы Ш.Камалның «Сукбай» (1914) хикәясе белән ассоциацияләр уята һәм язучының «элеккеге сукбайларны хәтерләтә торган» дигән бәясе моның махсус алым булуын күрсәтә: «Кыр өстен юка гына кар каплаган. Ул, көн урталарына таба эреп, җирне пычраткан. Урыны-урыны белән түмгәкләр һәм калку җирләр генә кар астыннан башларын тыкканнар. Еракта, юлдан бераз читтәрәк, чакрым баганасы тора. Аның өстенә козгын кунган.

Юл буйлап бер кеше килә. Аның аркасында элеккеге сукбайларны хәтерләтә торган юл капчыгы. Ул, ниндидер сорауга җавап эзләгәндәй, күзләрен җиргә текәгән шикелле, аяк астындагы юеш карны лошпырдатып, салмак кына атлый» [4]. Әлеге сурәт, ике хикәя арасында күзгә күренмәс бәйләнеш урнаштырып, Ш.Камал башлаган сөйләшүне яңа заманга күчерә: сукбайлык тормыш авырлыктан килеп чыкмый, ул кешенең холкында. Әгәр кеше җанына салынган киңлеккә омтылышны якыннары хакына җиңә, аны үзенә буйсындыра һәм туган җирендә

хезмәт итүгә файдалана алмый икән, бәхетсез була дигән фәлсәфә укыла башлый. Алга таба шофёр егет исеменнән яшь председатель Илдар — кайчандыр әтисе ташлап киткән малай турында сөйләп, язучы бәхетне туган җирдә табу мөмкин, монда да күңеле еракка карый белгәннәр кирәк икәнлекне ассызыклый. Бу янәшәлек кадерле кешеләрен дә, үзенә карата яхшы мөнәсәбәтне дә, туган җирен дә югалткан картны кызгану хисе уята.

Шактый озак тәнәфестән соң, 1980 елны язучының «Ташламам, җанкисәгем» дип исемләнгән хикәяләр җыентыгы [5] дөнья күрә. Икенче итеп урнаштырылган «Оча торган келәм» (1971) хикәясе авторның яңа бер сукмак — шартлы сурәт тудыру юлын үз иткәнлеге турында сөйли. Мирас исемле малай авызыннан сөйләнгән әкияти тарих аның оча торган келәм булуга ышануы, шуның өчен кагылу-сугылуы, кибеттә шундый исем белән келәм сатылуын күреп, аны алу өчен акча эшләве, ниһаять, теләгенә ирешеп, инде яраксызга чыгарылган келәмне өенә алып кайтуы, ләкин келәмнең очарга теләмәве кебек күренешләр тезмәсендә үсә бара. Соңгы җөмлә: «Шуннан соң келәмне өйгә алып кайтып, бусага янына аяк сөртергә җәеп салдым» («Ташламам...», 18 б.) — фәлсәфи нәтиҗәне яшәеш канунына әйләндерә. «Кешеләр зур хыяллар белән яшиләр дә, аларны тормышка ашыру юлында кыенлыкларга очрагач, үз хыялларына «аяк сөртә» башлыйлар», диюче автор әкияти-шартлы тарих аша кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә.

Элегрәк табылган темага, туган җирнең, авылның кеше күңелендәге, тормыш-яшәештәге урынын барлап язылган матур әсәр — «Тау төшәбез» (1967) хикәясе — кеше өчен туган туфракның газизлеген раслый. Очраклы сыман гына әйтелгән фразалар (мәчеткә бәйле: «Ваттыручысы да Мәрдән, төзәттерүчесе дә Мәрдән» шикелле), татар әдәбиятында формалашып килүче авыл реализмы агымында язылган әсәрләр рухында, иҗтимагый-сәяси тәнкыйтькә дә урын бирә. Батулланың әлеге хикәясендә дә татар әдәбиятындагы авыл реализмы агымының төп үзенчәлекләреннән булачак сыйфатлар — сызлану (экзистенциальлек) һәм сагышлану-сентиментальлек калкып чыга, мондый пафос символик образлар белән тирәнәйтелә. «Үр менүгә караганда, тау төшүе кыенрак икән! Басу капкасына җиттек. Хыялым тормышка ашты кебек. Тик ни өчендер ямансу... Белмим! Хыялымдагы авылның юкка чыгуымы, тирә-як табигатьнең үзгәрүе шундый сагыш алып киләме? Белмим!» («Ташламам...», 37 б.).

Сайлап игътибар ителгән хикәяләр Батулла прозасындагы алымнар, темалар ягыннан эзләнүләрнең сукмакларын бик ачык күрергә ярдәм итә. Соңрак бу сыйфатлар зуррак жанрдагы әсәр — «Юл буенда зәңгәр чәчәк» (1990) повесте (язучы үзе аның жанрын кыйсса дип билгели) — эчендә очрашып, аның уңышлы килеп чыгуын тәэмин итә. Дөрес, әсәрнең жанры күләме ягыннан хәтта роман таләпләренә җавап бирә. Андагы күптавышлылык Ф.М.Достоевский иҗатында аваз салган полифоник роман традицияләренә нигезләнгән. Ләкин, безнең фикеребезчә, икенче төп — иҗтимагый — сюжет сызыгы автор тарафыннан әсәрнең барлык тарихын үзенә тупларлык итеп эшләнеп бетмәгән, ул, барыннан да элек, әсәрдәге вакыйгалар вакыты булып аңлашыла. Бу үзенчәлек, күрәсең, әсәрнең авыл прозасы агымында язылуыннан килеп чыга торгандыр.

Әсәргә күчкәнче, татар әдәбиятында 1960 еллар ахырында башланган кайбер үзгәрешләрне искә алып үтү урынлы булыр. Бу чор милли әдәбиятын без традицияләрне яңарту, милли нигезләргә әйләнеп кайту баскычын-

да дип бәялибез [6]. Шушы барышта татар авылы хакында сөйләшүне үзәк тема итеп сайлаган авыл реализмы агымы формалаша, ул татар әдәбиятына халыкчан характерларны, милли әхлак сыйфатларын, кабатланмас җанлы сөйләмне кайтаруы белән үзенчәлекле була. Халыкның рухи тамырлары, мәдәнияте сакланган урын итеп авылны югары күтәрү агым үсешенең икенче этабында аның үз йөзен югалта баруына бәйле үкенеч, сагыш, үткәнне сагыну белән өретелде. Авыл реализмы агымы татар әдәбиятына төрле стильләргә, юнәлешләргә хас алымнарга бик теләп мөрәҗәгать ителә торган, мифологик, психологик, романтик алымнар тәэсирлелек арттыру буларак кулланылган әсәрләр бирде.

«Юл буенда зәңгәр чәчәк» (1990) повесте, авыл прозасы агымындагы әсәрләргә хас булганча, әхлакый кыйммәтләрнең югала баруына ачынып, шушы рухи торгынлыктан чыгу юлларын барлап язылган. Айдулла бабай — Ярмөхәммәт — Гозәер сюжет сызыгы бер нәселнең традицияләргә тугры калып, аларны буыннан буынга тапшырып яшәү үрнәге кебек калка. «Чәчәк тамырына узар өчен ыруның бер гомере кирәк» [7], дигән сүзләр яшәеш хакыйкатенә нәселләр буена килү генә мөмкин икәнлекне билгели. Нәсел өзелгәндә, хакыйкать өзелә. Нәселне, милләтне саклау әсәрдә олы бер проблема булып калка. Аерым нигезләр, нәселләр мисалында бу югалту автор-хикәяләүченең экзистенциаль сагышына әверелә. (Шунысы да бар, нәселләр югалу мотивы Батулланың алга таба язылачак һәр тарихи әсәрендә диярлек кабатлана һәм бу лейтмотив әлеге югалтуны татар халкы тарихындагы иң олы фаҗига итеп аңлауга китерә.) Нәсел сыйфатлары, милли үзенчәлекләр күзәтелеп, алар идеал дәрәҗәсенә күтәрелә. Ил карты Айдулланың үткәнгә, тарихка мөнәсәбәте, яшәү-көнитеше матурлык, татарча яшәү рәвеше буларак бирелә.

Повестьтагы төп сюжет сызыгы Ярмөхәммәтнең гомер тарихы кебек тәгәлләшә. Шушы сызыктагы төенләнеш — «Айдулла карт оныгы Ярмөхәммәтнең табигатькә, җиргә мәңге береккәнлеген» («Юл буенда...», 17 б.) аңлау — әсәрне бер үзәк тирәсенә җыя. 10 яшьлек малайдан 50 яшьлек ир булып гүргә кергәнче, Ярмөхәммәт бабасының ялгышмаганлыгын раслап яши, үлеме дә моңа дәлил булып тора. Әлеге төенләнеш язучы тарафыннан бик матур шартлы-романтик формага салына: Ярмөхәммәтнең зәңгәр чәчәк эченә үтеп керүе, аның матурлыгын аңлавы ул. Зәңгәр чәчәк символы повестьтагы мәгънәви кырны киңәйтә, аерым бер урыннарда төрлечә аңлау мөмкинлеге дә тудыра. Бер яктан, матурлык билгесе, гомумән, идеал төсендә матурлыкның «аяк астында», туган җирдә, бик гади-гадәти күренешләрдә яшәвен ассызыклый. Икенчедән, шушы матурлыкны күрә белүчеләр («чәчәк эченә узарлык шигъри куәткә ия адәмнәр күп түгел») җиргә береккән булырга, җирдә яшәргә тиешлекне искәртә. Өченчедән, авыл кешесенең рухи байлыгын, гади кешенең матур күңелле икәнлеген шулай сурәтли («Күңел күзең белән кара, улым, күңел күзең белән»). Дүртенчедән, матурлыкны күрә белүнең яшәү кагыйдәләренә төшенүгә тиңлеге билгеләнә («Дөньяның серен аңлар өчен, чәчәк серен белергә кирәк») («Юл буенда...», 11-13 б.). «Матурлыкны саклар өчен, азатлык кирәк», дигән сүзләр, язучы фикере кебек, шушы тезмгә килеп тоташа. Азат, хөр булып яшәү идеалы, нәтиҗәдә, Айбаш-Ярмөхәммәтләр мисалында, аерым кешенең хөрлеге кебек яңгыраш ала. Соңрак моны язучы тагын бер тапкыр аңлатып уза: «Күңел күзе ачылмаган кеше тулысы белән шәхес булып өлгерә алмый. Ул бары тик бәндә булып кына кала. Шәхес булыр өчен өч

баскыч узарга кирәк. Бәндә — Кеше — Адәм. Дөньяның бөтен әшәкелеге бәндәләрдән чыга. Кайда гына укып, зур белем алмасын, бәндә кешеләргә игелек кыла алмый. Ул бәндә дөньяга маңгай күзе белән генә карар. Ул тышкы рәвешләрне, өстә ялтыраган нәрсәләрне генә күрәчәк. Ә эчтәге, катлаулы үзгәрешләрне: үсешләрне, артка китешләрне күрү сәләте анда булмаячак. Ул бәндә, яхшылык эшлим дип, үзе дә сизмәстән яманлык кылачак» («Юл буенда...», 184 б.). Шушы яссылыкта күңел күзе ачылу, матурлыкны күрә белү, игелек кылып яшәү татарга хас милли сыйфатлар дәрәҗәсенә менә.

Ә инде мәхәббәт символы буларак, зәңгәр чәчәк туган җиргә, кешеләргә, аларның матур гадәт-сыйфатларына хөрмәт-ярату кебек аңлашыла. Язучы да үз «зәңгәр чәчәгенә» — җир кешесенә соклана, укучыны да үз артыннан иярергә, шушы фикернең дөреслеген тагын бер кат үз күңелендә расларга мәҗбүр итә.

Мәхәббәт темасы әсәрдә аерым урын тота. Шушы романтик мотив, кабатланып, повестьны якты өмет белән чолгый. Ярмөхәммәтнең Валиягә мәхәббәте, Зөләйха-Габделхәй һәм Ярмөхәммәт-Рәйсә мәхәббәтләре шәрык-татар әдәбиятларындагы илаһи мәхәббәт дәрәҗәсендә тасвирлана. Хәтта зур булмаган күренешләрдә, мәсәлән, Валия белән сөйләшүдән соң Нәдернең үзгәрүен билгеләп, язучы мәхәббәтнең кешене камилләштерә алу көченә ия кыйммәт булуын исбатлый. Хәтта Зөләйха-Габделхәйнең фаҗигале үлеме хакында язганда, автор мондый нәтиҗә чыгара: «Ил өстенә иңгән кайгылар онытылыр да, ә Зөләйха белән Габделхәй мәхәббәтенең фаҗигасен истән чыгармаслар» («Юл буенда...», 123 б.). Димәк, шатлыкның-бәхетнең иң олысы мәхәббәт булган кебек, кайгының да иң олысы — мәхәббәт фаҗигасе! Әлбәттә, бу фикер хакында (ил кайгысыннан өстен) бәхәсләшергә дә мөмкин булыр иде.

Әсәрдә башка кыйммәтләр дә игътибарга алына. Бәхет, кеше бәхете — тормышка ашмас хыял кебек аңлатыла («Бәхет ул — абага чәчәге. Әмма абага беркайчан да чәчәк атмый» («Юл буенда...», 48 б.)). Аның белән янәшә начарлык кылмау фәлсәфәсе урын таба. Геройлар да, шушы сыйфаттан чыгып, ике чиккә аерыла. Сабир, Фәрхун, Хөрмәтулла, Мирвәли, Ләйлә Таһировна кебек бер төркем геройлар, башкаларга (аңлапмы, аңламыйчамы) яманлык кылу ноктасыннан бәяләнеп, авторның тискәре мөнәсәбәте яктылыгында сурәтләнә.

Әдәбиятта авыл темасына алынучы язучылар авыл хуҗалыгындагы кыен хәлне тулырак һәм дөресрәк гәүдәләндерергә, авылда барган иҗтимагый-психологик процессларны тирәнрәк чагылдырырга омтылалар. Бу әсәрдә дә шулай. Язучының тәнкыйди карашлары ике яссылыкта — сурәтләнгән тормыштагы каршылыкларда һәм хикәяләүче фикер-мөнәсәбәте кебек — гомумиләшә.

Беренче яссылыкта тәнкыйди фикерләр әсәр буенча кабатлана торган Сабир, Фәрхун — авыл кешеләре каршылыгында ассызыклана. Сабир-Айдаш, Хәмидулла-Сабир, Валия-Сабир һ.б. бик күп каршылыклар төп проблемалар төсендә хакимияткә ия кешеләрнең үз мәнфәгатьләрен кайгыртуын, авыл халкына колларга караган кебек мөнәсәбәт хөкем сөрүне, бер төркемнең эчеп-исереп, азып-тузып, ил байлыгын әрәм-шәрәм итеп яшәвен, гади халыкның юк кына нәрсә өчен кимсетелүен, изелүен, җитәкчеләр белән авыл кешеләре арасында упкын хасил булуны, халыкның куркып көн итүен һ.б. ача. Каршылыклар арасында фаҗигале, кешеләр язмышын бөтенләй җимерүчеләре аерым урын тота. Сабир-Халисә, Сабир-Василә каршылыгы, кызларның харап булуы

ил кайгысы, ил фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәрелә. «Хәзер нәселләре юк. Нигез корган, тузган. Кем гаепле соң? дигәндәй, кирегә әйләндерелгән сорау билгесе булып, түшәмгә борып кертелгән бишек ыргагы җимерелеп төшәр вакытын көтә» («Юл буенда...», 112 б.), дигән хикәяләүче сүзләре нәселләрнең юкка чыгуында совет тәртипләрен гаепләү булып аңлашыла. Хөрмәтулла-Җәмига, Хөрмәтулла-авыл кешеләре каршылыгы кулларына кечкенә генә булса да власть эләккән кешеләрнең халыкны кан-яшь түктерүен, үз ихтыярына буйсындырырга омтылуын ачыклый. Ләкин алар сугыш чорында төгәлләнми, Ярмөхәммәтне гомере буе озата бара. Ярмөхәммәт-Гатауллин, Ярмөхәммәт-инженер һ.б. каршылыклар власть һәм халык арасындагы тартышның ниндидер заман, вакыт белән генә бәйле булмыйча, гомумән советчыл тормышка хас сыйфат икәнлеген дәлилләп килә. Ул язучының ваемы объекты, аны борчыган иң зур проблемаларның берсе төсендә хикәяләүче куйган сорауларда, шул сорауларга җавап эзләү барышының публицистик чигенешләр кебек килеп керүендә дә күренә. Мәсәлән, җитәкчеләрнең халыкка кылган җинаятенә мөнәсәбәт нинди булырга тиеш дигән мәсьәлә. «Гаделлекне яклап, кеше үч алырга тиешме, юкмы? Үч алырга тиеш булса, ни дәрәҗәдә, ничек итеп үч алырга кирәк?», «Ачылмаган җинаять, бирелмәгән җәза яңа җинаятьчеләр, кансыз буын тәрбияләмиме икән?», «Халыкны алдаучы элеккеге түрәләрне җәзасыз калдырып, тагын бер җинаять эшләмибезме икән? Дөрес, тәхеттән төшкән түрәне типкәләү дә бик миһербанлы эш түгелдер...», «Канга — кан, үлемгә — үлем, үчкә — үч булса да, без бер-беребезне кырып бетерәчәкбез!» кебек фикерләр постсовет чорына әле генә аяк баскан җәмгыять алдында торган сорауларны калкыту төсен ала.

Мондый тәнкыйди фикерләр аерым бер геройлар сүзе—фикере кебек тә гомуми агымга килеп кушыла: «Сабир—председательнең җитәкләү ысулы чыбык—чыбыркы—йодрыктан гыйбарәт икәнен бөтен авыл белә» һ.б., хикәяләүче «тавышы» да нәтиҗәләр ясый. Мәсәлән, «Айдаш баба» бүлегендә колхоз төзү вакытында булган кимчелекләрне, «кулак» исеме астында кешеләрне читкә куу яки күчерүнең ялгыш булуы билгеләнә: «Кызык бу дөнья, кызык. Җиргә берегеп үскән тырыш кешенең өе җимерек булырга тиеш идеме икәнни соң? Андый кеше атсыз җир сөрергә тиеш идеме икәнни соң?» («Юл буенда...», 15 б.). Бу сүзләр совет идеологиясенә карата бирелгән сораулар кебек яңгырый. Киная ясап киткән урыннар да байтак. Бу яктан, генератор алырга бару вакыйгасы оста эшләнгән. Язучы уен алымына мөрәҗәгать итә: юл, совхоз исеме (коммунизм) кинаяләп ил барган юлга ишарә ясый. «Коммунизм»ны таба алмау, ялгышып барып кергән авылның таркалып беткән булуы, баргач күргәннәр, ат үлү күренешләре автор уены-бәясен бөтенлекле ясый.

Иҗтимагый характерлы тәнкыйди карашлардан тыш, повестьта татарларга мөнәсәбәт, совет идеологиясенең милли сәясәтенә кагылышлы моментлар да бар. Мәсәлән, авылга эвакуациягә килгәннәрнең татарлар хакындагы күзаллавы — рәсми идеология нәтиҗәсе — болайрак китерелә: «Татарлар алар кеше ашаучылар, мөселман булмаган халыкларның канын эчүчеләр, бигрәк тә яшь балаларның канын яратып эчәләр икән, — дип уйлаганнар алар. — Безгә татарлар йонлы, мөгезле, ике койрыклы була, дип сөйләгәннәр иде...» («Юл буенда...», 71 б.). Әсәр ахырында иске мәчет, зират урынына яңа клуб кору белән бәйле вакыйгалар да милли сәясәткә ишарә ясый.

Милли характер буларак сурәтләнгән Айдаш карт — XX гасырның

икенче яртысы татар прозасы биргән иң матур образлардан. «Айдаш карт шатлыгын биеп шатланмады, кайгысын елап кайгырмады. Шуңа күрә аны төксе кешегә санады авыл халкы. Бии-бии шатланырлык зур сөенеч тә күргәне булмады Айдаш картның. Ләкин ул үзе өчен кечкенә генә нәрсәләрдән дә куаныч таба белә иде». «Кара кайгы килсә дә сыгылып төшә торган кеше түгел иде» («Юл буенда...», 20 б.) һ.б. Картның хезмәткә, атларга мөнәсәбәте, гаилә тотуы, бик кечкенә күренешләр: мунча ягу, оныгын тауга, урманга алып бару, каралтыга тамак кырып керергә өйрәтү һ.б. — татарча яшәү традицияләрен тасвирлавы белән кыйммәт. Повестьта Айдаш фәлсәфәсе дә шактый тулы күзаллана. Тормышның авырлыгын тирән аңлаучы («Чистармасмы бу фани дөнья») карт тотрыклылыкны өстен күрә («Кешеләрне сискәндерергә ярамый, улым»). Табигый яшәү рәвешен әһәмиятле санау да гел искәртеп барыла: «Дөньяны, кешеләрне аңлыйсың килсә, син тамырга төшәргә тиешсең», «Тормыш мәшәкатьләре белән чәчәкне, тауны онытма», «Биектән караганда, вак җәнлекләр, бөҗәкләр күренми... алар яши, яшәргә тели», «Һәр нәрсәнең җаны бар, улым. Җан ул — Ия. Кешенең эчендә кешенең Иясе була ...Кешене изеп кыйнасалар, аның тәнендә Кот калмый. Мәсхәрәләүгә Ия түзә алмый, тәннән чыгып кача. Кеше җансыз кала. ...Котсыз кеше күрергә язмасын, балам. Коты-Иясе чыгып качкан йортлар күрергә язмасын, иясез урманнар булмасын, дип телим мин... Кешенең гомер максаты шул булырга тиеш, Котны качырмаска, Котны сакларга. Котлы-Ияле булмаганнарны Котлы-Ияле итәргә. Менә шул ул яшәү максаты, улым Ярмөхәммәт. Кешеләр шуның серенә төшенә алса, шулай гына бәхеткә, сәгадәткә ирешерләр...» һ.б. Соңгы өзек язучының субъектив фәлсәфәсен дә үз эченә ала. Чөнки Ярмөхәммәт тарихы аның шушы максатка тугры калып тормыш итүен дәлилли. Котлы-Ияле тормыш төзү аерым кеше өчен мөһим булып кына калмыйча, һәм иҗтимагый, һәм милли өлкәләрне колачлап ала. Айдаш картның аерым бер кеше сыйфатларын күз уңына куйган әхлакый фикерләре дә бер җепкә тезелә. «Күп сөйләүчән, йөремсәк кеше тирән фикерле була алмый. Андый кеше җигелеп бер генә эшне тарта алмый. Ары сугыла, бире бәрелә дә төпле, тамырлы бер эш майтара алмыйча үлеп тә китә», яки: «Кайнарга түз, улым. Салкынга түз. Безгә түзем булырга кирәк. Безгә гел эссе була. Җә, гел салкын була, җә... Безнең ише халыкка урталык юк...» кебек җөмләләр шушы характерда.

Әсәрдә милли тарихка караган материаллар, әкият-кыйсса формасына төреп, киная белән (чукындыручы Аждаһа һ.б.) китерелә. Аждаһатау тарихы, Шаһимәрдән фаҗигасе милли тарихка ишарә булып ишетелә. Алып батыр малаеның өйләнү кыйссасы татарлардагы мифологик ышануларны тергезә. Бабасы үлгәннән соң, малайның ислам дине белән бәйле күзаллаулары китерелә. Мондый урыннар язучының тәрбияви максатын, тарихи мифларны, ислам белән бәйле ышануларны пропагандалауны үз алдына куюы хакында сөйли. Шуның белән бергә, бигрәк тә мифологик материал тәкъдим ителгәндә, халык сөйләме, халык фикере әдәбиятка киң дулкын кебек үтеп керә.

Айдаш баба белән бәйле бүлекләрдә үткәнне сагыну, идеаллаштыру аермачык. Гомумән, үткән һәм бүгенге әсәрнең буеннан-буена ике чик кебек күзаллана. Чик узу ноктасы 1917 ел инкыйлаблары икәнлеге искәртелә. «Хәзер» — совет чоры — тормышның авыраюы, кешеләрнең асылда ризык табу өчен яши башлау вакыты кебегрәк гомумиләштереп бәяләнә. «Урман тавыннан элек өч чишмә чыга иде. Хәзер

берәү генә». «Сугышка хәтле дә, борын заманнарда да бик уңа ие кавын. Кая хәзер... Кавын кайгысымыни? Арышбәрәңге үстерә кеше». Соңрак шушы сагышка хикәяләүче тавышы килеп кушыла: «Әмма үзгәрде табигать. Үзгәрде гадәтләр. Ямьсезлек ягына таба үзгәрде».

Повестьта төрлечә аңлау мөмкинлеге калдырылган, ләкин үз эченә яшерен мәгънәләр сыйдырган кызыклы ассоциатив образлар бар. Шуларның берсе — өч тупыл, Гозәер баба утырткан унбиш агачның «Рәсүлулла», «Ислам» һәм «Мөхәммәт» исемлеләре. Әйтерсең, алар татар кешесе өчен кирәкле, мөһим 15 кыйммәтне символлаштырган булган. Ярмөхәммәтнең үлеме алдыннан, икесенең басма өчен киселүен атеизмның җиңүе кебегрәк аңлау варианты бар. Өченче агач исеменең Ярмөхәммәт исеме белән аваздашлыгы герой тормышы тарихында язучы аерып чыгарган кыйммәтләрнең иң соңгы асыл баганалардан булуын ассызыклый төсле тоела. Ләкин укылыш өчен ачкыч булмау боларны фараз дәрәҗәсендә калдыра.

Шулай итеп, Р.Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте милли әдәбиятыбыздагы крестьян реализмы агымында язылган иң матур һәм тәэсирле әсәрләрдән. Авыл тормышын чынбарлыкка охшатып, ваклыкларда сурәтләү, авылны рухи байлык сакланып калган урын дәрәҗәсенә күтәрү әсәрдә шушы тормышны идеаллаштырып, романтик әсәрләргә хас алымнар ярдәмендә башкарыла. Гади, халыкчан сөйләмне сентименталь пафос белән кушу, гадәтине символлар ярдәмендә бәяләү әсәрдә үзенчәлекле, реалистик прозага хас булмаган интонация өстенлек алуга китерә. Милли идея белән чыгыш ясау, үткәнне мактау үзе үк күпмедер күләмдә совет идеологиясенә каршы чыгу төсен ала. Үткәндәге әхлакый кыйммәтләрне, халык традицияләрен югары күтәрү, укучыны да шул йола-гадәтләр белән мөмкин кадәр тулырак таныштырырга омтылу идеаль тормыш моделенең күзаллануына, чынбарлыкка каршы куелуына китерә. Геройларның эшгамәлләре, вакыйгалар иҗтимагыйтарихи детерминацияләнгән. Ләкин шәһәр тормышын авылга каршы кую, нигездә, аны авыллар таркалу сәбәпчесе итеп карау белән бәйле булса да, иҗтимагый кануннарны шик астына алып, табигый кануннарны дөрес санау идеологик яңгыраш ала. Җир кешесе, кечкенә кешенең бай рухи дөньясын, хисләр төрлелеген, характерын ачарга омтылу язучыга милли характерлар тудырырга юл ача. Бу сыйфатлар исә, үз чиратында, повестьны Р.Батулла прозасындагы иң уңышлы энҗеләрдән дип бәяләргә мөмкинлек бирә.

1960 еллар уртасында Р.Батулла иҗатында тагын бер яңа сукмак пәйда була — язучы тарихи темаларга мөрәҗәгать итә башлый. Бу өлкәдә иң беренче иҗат тәҗрибәләреннән булган «Мортаза» (1967) тарихи хикәясе Казанны яулап алгач булган фаҗигале сәхифәләрне тергезә. Автор татарларның кыю һәм горур булуына, халык мәнфәгатен үзләре өчен иң кадерле кыйммәтләрдән өстен куюына дан җырлый. Моннан соң да Казан ханлыгы тарихы, шул чорның аерым шәхесләре язмышы Батулла иҗатының үзәгендә кала. 1992 елны язучының «Сөембикә» романы басылып чыга. Авторга Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге китергән бу әсәр әдәби тәнкыйтьтә үзенә лаек зур бәяне ала. Аннан соң да «Вәгазь» (1996), «Соңгы сөннәт» (2004), «Казан астым Казансу буенда» (1988-2005), «Бәдәлче» (2005) кебек күпсанлы хикәяләрендә язучы шушы темага мөрәҗәгать итә. Әсәрләрдә аерым бер күренекле, бүген дә аңлатып бирү бәхәсле булып кала торган вакыйгалар үзенчәлекле шәрехләү ала.

Язучының тарихи әсәрләре арасында бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышланганнары шактый. «Имче» (1976) хикәясе Габдулла Тукайның балачагына алып китә. Язучы фантазиясе малайның күзенә ак төшү тарихын да, Кырлай авылына килү сәбәпләрен дә, мондагы маҗараларны да колачлап ала. Шигъри күңелле малайны Мөхәммәтвәли белән Газизәнең яратуы, Сәгъди абзый әкиятләре тәрбияләде диюче автор тудырган балачак дөньясы гаҗәеп самими. Мәктәп дәреслекләренә кертерлек бу хикәя Батулланың Тукайга багышланган тарихи әсәрләренә юл башы булып тора. Зуррак жанрдагы әсәрләрдән, «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» (1995) повесте — әлеге сукмакта язылган әсәрләрнең таҗы — Тукайның соңгы көннәренә багышланган. Тарихи фактлар язучы фантазиясе белән кушылып киткән бу повестьта шагыйрьнең дуслары Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Сәгыйть Рәмиев, Исхак Бикчуриннар Тукай белән очрашулары вакытында характер буларак ачылып китә. Ике сюжет сызыгы — Тукайның азатлык өчен көрәше (бу Шәүлә белән Тукай мөнәсәбәтләре, сөйләшүләре аша тергезелә) һәм мәхәббәт тарихы үзәккә куела. Повестьны башлый һәм төгәлли торган кабатланучы күренеш: азан тавышы, мөселманнарның мәчеткә ашыгуы, бу вакытта очраклы кешеләрнең сөйләшүләре — әсәрне борчулы-тантаналы бер дулкынга көйли, әлеге интонация ахырга кадәр югалмый саклана. Башлам һәм бетем Тукайны замандашларының чиктән тыш хөрмәт итүен, аны олылавын һәм изгеләштерүен әсәр буенча лейтмотив буларак алып барырга ярдәм итә. Язучы «Тукай — халыкның җаны» дигән фикерне калкытып бара.

Аерым катлау кешеләр белән очрашу-гәпләшү вакытында Тукай төрле яклап ачыла. Язучы аны милләт гаме белән яшәүче, башкалар мәнфәгатен үзеннән өстен куючы, туры сүзле, ачык күңелле һәм юмарт кеше буларак сурәтли. Зәйтүнәнең мәхәббәтеннән баш тартуы да кызның үзе хакына корбан китерү кебек шәрехләнә.

Әсәр символик образлар белән тирәнәйтелгән. Повестьның исеме үк күпмәгънәлелеккә ия: сират күперенә карата әйтелгән бу сүзләр һәр кешенең исән вакытта ук сынау узуын белдерә. Повестьтагы һәр герой шул сынау алдына куела: нәтиҗәдә, кемдер кешелеген саклап кала ала, кемдер кача, кемдер үлемне сайлый. Тукай яткан тактада, утырып язган өстәлдә, китап тартмасында хач (тәре) сурәте, шуның аша ясалган нәтиҗә сәяси символга әверелә. Зәйтүнә алып килгән зәңгәр чәчәкләр хыял-өметнең иҗат чыганагы булуына ишарә.

Язучы Тукайның хәлен аның төшсаташуларында символик рәвештә «читлектә яшәү» кебек бәяли. Шушы читлектән рухы азатлыкка омтылган шагыйрь моның өчен милләтне, халыкны азат итәргә кирәклеген аңлый. Ләкин әсәрдә моңа нинди юл белән ирешергә икәнлеге билгесез булып кала. Шәүлә белән бәхәсләрдә көрәш юлының куркыныч яклары күрсәтелә: «Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Барабыз да барабыз, кая барабыз соң без, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Зыялылар бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне асалар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак, һәр палач, гөнаһсыз башны чапканда, «Яшәсен революция!» дип акырачак. Менә нәрсә ул

революция!» [8]. Ләкин бу сүзләрне тискәре герой — Шәүләдән әйттерү авторның симпатиясе көрәшчеләр ягында булуга ишарә ясый.

Повестьтагы күптавышлылык, ягъни геройлар исеменнән сөйләү, үткәнгә кайтып искә төшерүләр, авторның геройларын кульминацион ноктапарга — иң яшерен серләр кычкырып әйтелә торган моментларга — куюы психологизм тудыру алымнарына әйләнә. Тарихи фактларга нигезләнү бу әсәрнең тәэсир көчен киметми, киресенчә, повесть бер тында укыла, бербөтен хисси дулкында кабул ителә.

Тарихи материалны олы жанр — роман кысаларында бирү язучы алдына аерым бурычлар куя. Мондый әсәрләрдә еш кына тарихи, фактологик башлангыч әдәби башлангычтан өстен чыга. Бер яктан, тарихи романнар билгеле бер чорга кагылышлы билгесез мәгълүматларны, бер җепкә тезеп, бер үзәк тирәсенә туплап, халыкка кайтарырга мөмкинлек бирә. Бу эш автордан күп эзләнүне, киң җәмәгатьчелеккә билгесез чыганакларга мөрәҗәгать итүне, хәтта аерым детальләрне берәмтекләп, күп кешеләрдән сөйләтеп чагыштыруны таләп итә. Икенче яктан, мондый әсәрләр югалырга әзер тарихларны саклап кала, аларга җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтә.

Батулла иҗатында тарихи романнар аз түгел. Аксак Тимер тормышына алып киткән «Мур кырылышы» (2005), Габдулла Тукай һәм аның тирәлеге тормышына багышланган «Апуш — Тукай» (1995-2009), «Күк капусы ачылганда» (2006), Кәрим һәм Заһидә Тинчуриналар язмышын тергезгән «Җимерелгән бәхет» (2004), атаклы биюче Р.Нуриев гомерен колачлаган «Бию җене кагылган егет» (2004) шундыйлардан. Әйтик, «Яралы бүре» (1995) романы бүгенге киң катлам укучыга бөтенләй диярлек таныш булмаган шәхес — XX йөз башының билгеле театр тәнкыйтьчесе һәм журналисты, Г.Тукайның якын дусты Кәбир Бәкер турында. Р.Батулла Кәбирнең этисе өйләнгән, гаиләдә өлкән ул туган вакыттан алып Кәбирнең үлеменә кадәр вакыйгаларны бик җентекле күзәтеп бара. Тукай белән бәйле вакыйгалар зыялы-белемле Муса Бигиев шәхесен каршылыклы холыкфигыль иясе буларак тәкъдим итәргә мөмкинлек биргән. Әсәрдә Шакир Мөхәммәдьяров образы үзенчәлекле ачылган. Гомумән, Батулланың кеше образларын бөтенлекле характер буларак тудыру осталыгы бу романда да тулысынча тормышка ашырыла.

Язучы татар мәдәниятенә кагылышлы оригиналь нәтиҗәләре, уйланулары белән әсәр буенча уртаклаша бара. Әйтик, Петербург белән бәйле өлештә З.Бигиевнең югалган дип саналучы «Катилә» һәм «Мөртәт» романнарының басылмау сәбәбен үзенчә шәрехләп уза. Гомумән, романда кешеләр язмышы турында сөйләү татарлар, аларның көнитеше, менталитеты турында кызыклы гына күзәтүләр белән үрелеп китә. Мәсәлән, «казак» атамасына тарихи аңлатма бирү [9], татарларның йорт салу-өйләнү мәсьәләләренә карашы («Оясы булмаса, сандугач сайрамый. Ата сандугач башта оя кора, аннан ары оясына хуҗабикә эзли башлый, хуҗабикәне ул сайрый-сайрый эзли. Оям да әзер, сайравым да бик матур, зинһар, ояма кер, хатыным бул, миңа чибәр-чибәр балалар чыгар, дип сайрый ул...», (186 б.), дин һәм тел мөнәсәбәтләре (187 б.), татарларның Казанга тартылу сәбәпләре («Казан» — һәр мөселманга, һәр татарга могҗизалы сүз. Ул шәһәр — һәр татарның мәгънәви кыйбласыдыр. Мине бүгенге урыс каласы түгел, ә ханнар заманындагы Казан, дин мәркәзе булган Казан, сәедләр үзәге саналган Казан, шагыйрьләр каласы, гүзәл хансарайлар шәһәре, бай көтебханәләр, гөлбакчалар, мәктәпләр, Сөембикә манарасы, атаклы ханнары-

мыз җирләнгән изге зиратлар тарта», 208 б.) һ.б. укучыга уйлану, автор белән бәхәсләшү өчен азык бирә.

Тарихи романнарның күпчелегендә мавыктыргыч башлангычны тарихи фактлар тезмәсе каплап китә, текстны әдәби әсәр буларак кабул итү авырлаша. Аерым бер очракларда, шушы куркынычны күздә тотып, икенче якка ташлану күзәтелә: язучылар, гыйшык-мәхәббәт күренешләренә чиктән тыш күп урын биреп, тарихи романнарны массачыл әдәбият дәрәҗәсенә төшерәләр. Р.Батулланың исә маҗаралылыкны арттыруда үз алымнары бар. Без карый торган әсәрдә төрек пашасы Әнвәр бәй һәм Кәбир Бәкер арасында янәшәлекләр уздыру шуңа хезмәт итә. Аннары, язучы тарихи фактларның үзләрен үк маҗарага әйләндерә. Бу яктан, 1912 елгы Төрек-Балкан сугышы башлангач, татар кызларының шәфкать туташлары булып Төркиягә баруы, юлдагы хәлләр, кызларга мөнәсәбәт, аеруча Иван Шамоновның Рокыя Юнысовага карата хисләре әсәрне бизәүче вакыйгаларга әверелгән.

Романның ахыргы бүлекләре «Яралы бүреләр» — Кәбир Бәкер белән Әнвәр пашаның революция һәм яңа сәясәт корбаннары булуы турында гына түгел. Бу өлешләрдә XX йөз башында гомерләрен татар милләтенә хезмәт итүгә, аның мәдәниятен, мәгарифен, фәнен, әдәбиятын, сәнгатен үстерүгә багышлаган татар зыялыларының аяныч язмышы милләт фаҗигасе дәрәҗәсендә күрсәтелә. Нәтиҗәдә, әсәрнең исеме үк символик мәгънә ала. Яралы бүре — аерым шәхесләр генә түгел, инкыйлаб яралаган татар халкы, төрки халыклар кебек аңлашыла башлый.

Гадәттә, тарихи әсәр өчен материаллар туплаган язучыларның шул материаллар нигезендә киң катлау укучыга атап, массачыл әдәбият дип исемләнә торган, маҗаралылыгы тәрбияви яктан күпкә өстен булган әсәрләр язуы — билгеле күренеш. Бу юнәлештә дә Р.Батулланың күп эшләвен әйтеп үтәргә кирәк. Бер яктан, Р.Батулла, риваять-легендаларны кабат тергезеп, күп кенә хикәят-әкиятләр иҗат итә. Әйтик, «Әстәгъфирулла» [10] китабындагы беренче бүлеккә авторның 35 шундый хикәяте туплап бирелгән. Халыкныкын халыкка кайтаруның бер юлы булган бу эш милли менталитет хакында, халык аңындагы үз итү, курку-саклану, кире кагу белән бәйле, яшәү һәм үлемгә мөнәсәбәтле күзаллаулар турында шактый тулы мәгълүмат бирә.

Моннан тыш, Р.Батулла массачыл укучыга адресланган, билгеле шәхесләр, тарихи вакыйгалар хакында кече жанрдагы әсәрләр (мәзәкләр, нәни хикәяләр) авторы буларак билгеле [11]. Мондый китаплар мавыктырып, сиздерми генә мәгълүмат бирү, аерым шәхесләрне характер буларак халык хәтерендә яңарту җәһәтеннән әһәмиятле. Язучының «Урыннары җәннәттә булсын» китабында [12], тарихи-әдәби документаль текстлар белән янәшә, урта жанрдагы әдәби әсәрләр дә бар. Язучы киң катлау укучыга түгел, белгечләргә дә аз мәгълүм фактлар белән иркен эш итә. Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Т.Соловьёв, Б.Урманче, М.Гайнуллин һ.б. бик күп шәхесләрнең якты образы, холык-фигыле, тормыш сынауларын үтү юллары укучы күз алдына килеп баса. Тарихи мәгълүматларны җыю һәм әйләнешкә кертүдә Р.Батулла бер әдип түгел, ун тикшеренүче көче җитмәс эшләрне башкарып чыккан.

Язучының эпик төрдә иҗат ителгән күпсанлы китапларына, әсәрләренә күзәтү ясаганда, каләменең активлыгына, авторның хыял байлыгына, хезмәт сөючәнлегенә хәйран каласың. Ләкин бит әле аның иҗат мәйданы проза белән чикләнми. Курчак театрында куярга нәниләргә атап язылган, өлкәннәр өчен драма төрендәге әсәрләре дә шак-

тый, алар сәхнәләрдә уйнала. Әдәби тәнкыйть һәм публицистикага караган китаплары да бар, басыла тора. Сәяхәтнамәләр, тәрҗемәләр, кино һәм телевидение өчен сценарийлар аерым алып күзәтү ясауны көтә.

Әлбәттә, санның һәрвакытта да сыйфатка тәэсир итмәве гомумбилгеле. Шуңа күрә, язучы иҗаты турында сүз барганда, әсәрләрнең әдәби барыштагы урыны, роле, алып килгән яңалыгы төп үлчәү берәмлегенә әверелә. Без прозаик, драматург, балалар язучысы Рабит Батулла иҗатының бер канатын — эпик әсәрләрен күзәтеп уздык. Бай һәм күптармаклы бу иҗатның XX гасырның икенче яртысы татар әдәби барышына зур йогынты ясаганлыгы шик уятмый. Шул ук вакытта нәтиҗәле эшләүче, иҗатта тәҗрибәләр юлы белән баручы авторның күп кенә әсәрләре әле бүгенгә кадәр тиешле зур бәяне алмаган дигән тәэсир кала. Иң беренче чиратта, язучының 1960 еллар әдәби яңарышына темалар яңалыгы, яшерен эчтәлектә заманның актуаль мәсьәләләрен күтәрүе ягыннан да, үзенчәлекле әдәби алымнары белән дә (бигрәк тә төп герой исеменнән сөйләүне психологизм тудыруның төп чарасына әверелдерүе, алымнар һәм проблемалар ягыннан XX гасыр башы психологик прозасының уңай традицияләрен тергезүе, ягъни символлар белән эчтәлекне тирәнәйтүе, яшәп килгән идеологиягә мөнәсәбәтле аерым мотивларның бөресен укучы игътибар итәр дәрәҗәдә әсәр буйлап үстерә баруы, милли кыйммәтләрне, милли образларны хасил итә торган детальләр, ышанулар, миф-легендалар белән уңышлы уйнавы, милли проблемаларны сызлану фәлсәфәсе яктылыгында бәяләве һ.б.) зур өлеш керткән хикәяләре аерып анализланырга хаклы. Татар әдәбиятын тамырдан үзгәрткән, социалистик реализм юнәлешенең асылына тәэсир ясаган авыл прозасының иң матур үрнәкләреннән берсе — «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте — милли әдәбиятта шушы сукмакның якты сәхифәсе төсендә анализланырга лаек. Язучының күпсанлы тарихи әсәрләре арасында милли әдәбияттагы тарихи әсәрләрнең беренче унлыгына керерлекләре бар икәнне дә онытырга ярамый.

Бу көннәрдә күренекле әдип үзенең матур юбилеен билгеләде. Иҗатының колачына һәм тирәнлегенә сокланып, рәхмәтле укучылары исеменнән аңа яңа сукмаклар, яңа табышлар, яңа әсәрләр язарга илһам телибез.

Әдәбият

1. Батуллин Р. Исемем минем Дүрткүз: повесть. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1966. — 83 б.
2. Батуллин Р. Уйларымны кеше белсен...: хикәяләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1969. — 111 б.
3. Батулла. Әйтсәң, конфет бирәм // Сайланма әсәрләр. Биш томда. 4 том: Иреккә чыгасы уйлар. Хикәяләр, тарихи әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — Б.9.
4. Батулла. Көз көнендә // Сайланма әсәрләр. Биш томда. 4 том: Иреккә чыгасы уйлар. Хикәяләр, тарихи әсәрләр. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2008. — Б.5.
5. Батулла. Ташламам, җанкисәгем: Хикәяләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. — 168 б.
6. Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы. Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. — Казан: Казан университеты, 2011. — 198 б.
7. Батулла Р.М. Юл буенда зәңгәр чәчәк // Сайланма әсәрләр. Биш томда. 5 том: Кыйссалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — Б.12.
8. Батулла Р.М. Кылдан нечкә, кылычтан үткен // Сайланма әсәрләр. Биш томда. 5 том: Кыйссалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. — Б.395.
9. Батулла Р.М. Яралы бүре // Яралы бүреләр: Кыйссалар. Роман. — Казан: Нашире ШЭ Корбанов Р.Х., 2011. — Б.185-186.
10. Батулла. Әстәгъфирулла: хикәятләр. — Казан: Нашире ШЭ Корбанов Р.Х., 2011. — 648 б.
11. Батулла Р. Тузга язмаган хәлләр: язучылар, артистлар, музыкантлар, гыйлем ияләре тормышына бәйле мәзәкләр, гыйбрәтле вакыйгалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. — 447 б.
12. Рабит Батулла. Урыннары җәннәттә булсын! (Мәрхүм шәхесләребез турында мәрсияләр, хатирәләр). — Казан: «Рухият» нәшрияты, 2007. — 991 б. ■

МӘҺДИ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ НИ СӨЙЛИ?

РАШАТ НИЗАМИ,
шагыйрь, прозаик, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты



БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНДӘ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ АЕРЫМ ӨЙРӘНЕЛӘ. БӘЛКИ, БУ ДӨРЕСТЕР ДӘ. КҮП КЕНӘ ӘДИПЛӘРНЕҢ ИҖАТЫНДА БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ӘСӘРЛӘР БЕЛӘН ТЫГЫЗ ҮРЕЛЕП БАРА ҺӘМ АЛАРНЫ АЕРЫП КАРАУ ДА КЫЕН.

Үз-үзенә һәйкәл салыр өчен,
Ташны ярып чыга үләннәр.

Кызыклы заманда яшибез: тарихта тирән эз калдырган шәхесләрнең дә һәйкәлләрен җимерәләр (Ленин, Дзержинский), яңаларына һәйкәл ачарга да онытмыйлар (әйтик, Екатеринбургта – Ельцинга). Кешегә бакырдан яки мәрмәрдән генә түгел, сүздән яки җырдан да һәйкәл салырга мөмкин икән…

Студентларның яраткан укытучысы, лекцияләр остасы, данлыклы язучы Мөхәммәт Мәһдиевкә сүздән һәйкәл салынганын күрдегезме әле? Моны күрер өчен, аның иң якын дусты, замандашы, каләмдәше, академик, язучы һәм әдәби тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» дигән китабын* укып чыгу фарыз. Узган ел, өч кисәккә бүленеп, иң әүвәл «Казан утлары» журналында дөнья күрде ул.

Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин язган. Аның бер җөмләсен игътибар үзәгенә калкытып куясы килә: «Роман-эссеның көче – документальлектә. Күреп торабыз: кирпеч калынлыгы романнар чоры үтеп бара».

Күләмле әсәрнең жанры дөрес табылган – роман-эссе. «Эссе» төшенчәсе татар укучысына бераз ятрак тоелырга мөмкин. Ул «истәлек», «хатирә» дигәнне аңлата. Мөхәммәт Мәһдиев халкыбызның сөйкемле сөяге иде. Фоат Галимуллин әйткәнчә: «Әйе, һәркемнең үз Мәһдиеве бар». Яхшы мәгънәсендә көнләшеп әйтсәк, Тәлгат Галиуллин «ачкан» Мәһдигә беребезнең дә кулы җитәрлек түгелдер, мөгаен.

Мин элек-электән, һәрбер татар

*Галиуллин Т. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы: роман-эссе. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 191 б.

язучысы үз халкының күренекле бер улы турында китап язарга бурычлы дигән караштa тордым. Шөкер, безнең әдәбиятта моның мисаллары байтакка җыйнала. Берничәсен генә искә төшерик: Тукай турында — Ә.Фәйзи, И.Нуруллин, Батулла әсәрләре, М.Хәбибуллинның — «Кубрат хан», Р.Мөхәммәдиевнең — Мирсәет Солтангалиев, Равил Вәлиевнең атаклы биючебез Рудольф Нуриев турындагы романнары һ.б. Композиторлар Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев турында мин үзем дә күләмле әсәрләр иҗат иттем. Вәләкин шуны уйлыйм: инде әллә кайчан бакыйлыкка күчкән олуг шәхесләребез турында язуга караганда, әле кайчан гына үзебезнең арада яшәгән, эшләгән реаль кеше хакында китап язу, миңа калса, күпкә катлаулырак һәм җаваплырак. Бу очракта фантазия һәм шартлы алымнарга мөмкинлек чикләнә, уйдырмаларга бирелсәң, тәнкыйть утына эләгәсеңне көт тә тор!

Шушындый да күләмле (нәкъ утыз бүлек!) һәм мәртәбәле хезмәткә тотыныр алдыннан автор сүз башында ук үзенең максатын ачык билгели: «Алдыма куелган максатым — бу олы затны ...гадәти кешеләр кебек ярата, көнләшә, курка, кирәк чакта «күзгә төтен җибәрә» белә торган, тулы тормыш белән яшәгән, гаилә, дуслык, иҗат бәхетен татыган кеше буларак сурәтләү». Әйтергә кирәк, автор вәгъдәсендә тора: М.Мәһдиевне тормышта ничек булган, шулай сурәтли. Палитрасындагы буяуларның җетелеге һәм куелыгы сокландыра. Романның буеннан-буена, пәйгамбәрләрчә нур чәчеп, төп герой — Мөхәммәт Мәһдиев образы бара... Кыскасы, аның белән ризыкны һәм фәлсәфәне чүмечләп эчкән кеше буларак, Т.Галиуллинның «сәгате» суккан, барасы эше барып чыккан!

М.Мәһдиевнең тормышына, иҗатына бәйле вакыйга һәм эпизодлар, шуның белән бергә авторның фәлсәфианалитик уйланулары, сөземтәләре бүлекләп, оя-оя итеп, баблар рәвешендә бирелгән, тәсбих төймәләредәй бер җепкә тезеп куелган. Мондый алым

Алабуга педагогия институнда очрашу. 1989 ел

исә, һичшиксез, укуны һәм материал пластларын үзләштерүне җиңеләйтә.

Т.Галиуллин — галим һәм язучы («Сәет Сакманов» трилогиясен хәтерлик). Менә шушы ике канаты, бер-берсен тулыландырган ике сыйфаты аңа уй-фикерләр киңлегендә коштай иркен очарга, балыктай ансат йөзәргә, теләсә кайсы борылышларда да җитез элдерә торган капландай хәрәкәтләнергә мөмкинлек бирә. Язмаларда дүрт төрле стиль, этешмитөртешми генә, бер-берсен баетып, табигый рәвештә үрелеп бара: проза, әдәби тәнкыйть, фәнни-аналитик бәяләр һәм юмор...

Мәһдиев — тапкыр сүзле ораторлыгы, галимлеге, киң эрудициясе, әдәбияттагы һәр күренешкә үз карашы булу өстенә, йомшак-ягымлы юморы, табигать күренешләрен оста һәм үзенчә тасвирлавы белән дә безне таң калдырган шәхес, кабатланмас феномен иде. Хаталанганда да үз югарылыгындагы олы шәхес булып кала белде. Т.Галиуллин боларның һәммәсен төгәл һәм гыйбрәтле мисаллар белән җентекләп, аның якты образын тудыра алган.

Әсәрдә М.Мәһдиев нинди генә вазгыятьтә һәм статусларда күрсәтелми: «халык дошманы» баласы, әтисенең сыйнфый фаҗигасе, туган авылы, мәктәп, Арча педагогия училищесы, флот, Казан университеты, аспирантура, гаилә, хатыны Лилия ханым һәм балалары, фән кешеләре, каләмдәшләре дисеңме... Ә инде иң якын дуслары чолганышында, иҗади яисә сәфәри мохиттә, ял сәгатьләрендә аның дәрәҗәсен белеп кенә үз-үзен тотышы, сүз айгырын уйната белүе, яратып кына (рәнҗетмичә) табындашларын сарказм дулкынында коендырып алуы, саллы-мәгънәви анекдотлар — боларның һәммәсе Шукшин рухындагы дистәләгән хикәяләргә торырлык! Автор каләме аша хронологик вакыйгалар да, лирик чигенешләр дә берберсенә оста ялганып китә, Мәһдиевнең дәреслек битләрендәгесенә охшамаган «портреты» ачылганнан-ачыла бара.

Портрет димәктән, Т.Галиуллин китапның беренче битләреннән үк үзенең портретлар остасы икәнлеген раслый. Бу җәһәттән чагыштырулары, фикер сөреше ышандырырлык. Каләмдәш дустын менә ничек тасвирлый ул: «Кайсыдыр ерак бабасының Кырым, Хәзәр, хәтта мәгърур Эллада якларыннан ук икәнлегенә тышкы кыяфәте ишарә ясап тора кебек. Уртачадан озынрак буй, төз гәүдә, уртасы чыгынтылы, һавалы кылыч борын, аска таба очланыбрак төшкән мәрмәр ияк, карчыганыкы шикелле үткен күз дисеңме — һәммәсе шул хыялый фаразга дәлил булып тора».

Моны коеп куелган һәйкәл димичә ни диярсең...

***

Бүлек атамалары уңышлы, истә калырлык итеп куелган һәм алар эчтәлекне турыдан-туры ачып бирүгә хезмәт итә. Мәсәлән, «Кем кияве икән Мөхәммәт Мәһдиев?», «Егетлек флотта сынала», «Җилнең җаны бармы?», «Юмор — табигать бүләге», «Татарда зыялылар бармы?» һ.б. Мондый җөмләләр, ташка уйган кебек сүзләр магнит сыман үзенә тартып, кызыктырып тора, билгеле.

Китапның башында ук, ягъни беренче бүлеккә куелган исемне читләтеп үтү мөмкин түгел: «Мөрәүвәтле шәхес». Автор татарның менә шушы тыгыз, саллы, ике генә сүзе белән героеның кем икәнлеген математик төгәллек белән әйткән дә биргән! М.Мәһдиев һәм аның иҗаты турында әле үзе исән чагында ук байтак кына мәкаләләр дөнья күрде. Автор, үз фикерләре белән генә чикләнмичә, бер җепкә тезеп, Дания Заһидуллина, Фоат Галимуллин, Марсель Галиев, Тәбриз Мөбәрәков, Рим Халитов (Татарстанның атказанган төзүчесе) һ.б. әдипкә нинди бәя бирүләрен әйтеп, уйлануларын әнә шундый мисаллар белән дә ныгытып куя.

М.Мәһдиев язмышындагы иң зур фаҗигане әйтми китү мөмкин түгелдер.

Бу булачак әдипнең балачагына бәйле. Советлар яраткан, үз иткән әрсез гайбәт аның газиз әтисенә — авыл мулласы һәм соңрак укытучылык эшенә күчкән Сөнгать абыйга «халык дошманы» дигән кара тамганы суга. Әлеге урында Т.Галиуллин, бер дә яшереп-икеләнеп тормыйча, ачыктан-ачык дөресен әйтеп яза: «Аның җанына хакимияттән, тирәлектән курку хисе кереп кала. Бу шом озак саклана».

Бик хәтәр һәм акыллы сүзләр.

Шушы хәлгә бәйле рәвештә, Т.Галиуллин игътибарга лаек бер фаразны алга сөрә: «Ул милли хәрәкәтнең лидеры була алыр иде», — ди. Мин моның белән килешәм. Чөнки М.Мәһдиев шундый да дәрәҗәле һәм җаваплы вазифага (миссиягә) бар яктан да әзерлекле, бөтенесен ерып чыга ала торган эшчән шәхес иде. Аның халык ташкынын үзе артыннан ияртәсенә тамчы да шик юк. Вәләкин Мәһдиевнең баш очында әтисенең теге «кара күләгәсе» һәрвакыт айбалтадай эленеп тора. Суверенитет башы елларында ул мөнбәргә күтәрелсә, аның башына тукмак оручылар, һичшиксез, табылыр иде. Җанына тигән НКВДның тамырлары үлмәгән ич әле, җай чыкса, кылыч уйнатырга һәрвакыт әзер торалар…

Әңгәмәләребезнең берсендә мин аңа шундыйрак «текә» сорау да биргән идем:

— Сез нишләп татар иҗтимагый үзәге эшендә катнашмыйсыз, нишләп митингларда чыгыш ясамыйсыз?

Ул озак уйланып тормастан, болай дип җавап бирде:

— Мин табигатем белән митинговой кеше түгел, андый сәләт миңа бирелмәгән. Газеталарда мәкаләләр белән һәм иҗатым белән катнашам, мин дә милләтемнең күзен ачарга үземнән өлеш кертәм.

Аның бу җавабы һәм сүзләре аңлаешлы. Ләкин минем өчен бер сер ачык: куркытылган буын вәкиле буларак, ул барыбер өч хәрефле КГБдан, аның җитез әләкчеләреннән уңайсызланып яшәде шикелле. Аңардан батырлык көтмик. Ул болай да милләтнең үзаңын уяту һәм татар әдәбиятының сулышын яңартуга бик кирәкле эшләрне һаман саен башкара килде.

Бераз читенеш ясап, үземнән бер штрих. Авыл мулласы Сөнгать абыйның өлкәнрәк улы Рәшит Мәһдиев тә бар бит әле дөньяда. Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр сапёр булып катнашкан, Европа түренә кадәр үк барып җиткән бу фронтовик турында (үзе исән чагында ук!) «Дүрт гөрелте» дигән очерк язган идем. «Татарстан яшьләре» газетасында басылып чыкты ул. Мөхәммәт абый әлеге язманы укыган икән, рәхмәт әйтеп шалтыратты. Аны карчыгадай үткер күзле Аяз Гыйләҗев тә укыган булып чыкты. Матбугат йорты коридорында очратып, остазым буларак яратып та, шелтәләп тә әйтә куйды ул миңа:

— Мәһдинең абыйсы икәнен нигә сиздермәдең язмаңда? Әтиләре Сөнгатьнең КГБ тырнагына эләгүен дә каләм очына эләктерсәң, хакыйкать күбрәк ачылган булыр иде…

Әле минем яшь чак, юләр чак дигәндәй, күп нәрсәләрне белми идем шул. Рәшит агай да, әтисе турында сөйләп, ул чакларның михнәтен йөрәгендә кузгатырга теләмәгән, күрәсең.

Ходайның рәхмәте белән, болар хакында тулырак һәм тәфсиллерәк сөйләп бирү вазифасы Т.Галиуллин каләменә насыйп булган, күрәсең.

***

«Кем кияве икән Мөхәммәт Мәһдиев?» дигән сорау куелган икән, әдәбиятыбыз аксакалы Гомәр ага Бәширов турында әйтми калу мөмкин булмагандыр. Мантыйк шуны таләп итә. Фактлар үҗәт нәрсә: җилкәсенә күп кенә погоннар салынган, хөкүмәт дәрәҗәсендәге президиумнарда һәм олы түрәләр тирәсендә еш кайнаган Г.Бәширов турында автор бик җылы һәм якын итеп сөйли, истәлекләрен уртаклаша. Мәһдиевнең хатыны Лилия ханым

турында да күпләребез белмәгән кызыклы сәхифәләргә юлыгабыз. Боларны сөйләп кабатланасым килми, китапны кулына тотып укыган кеше һәммәсен дә үзе һәм үзенчә кабул итсен. «Кияү белән бабай арасындагы җылы мөнәсәбәтләр» матур чагылыш тапкан. Автор, пакусны киң алдырып, Бәширов иҗатына һәм аның холкына рас килердәй сүзләрне бер җөмлә белән әйтеп сала белгән: «Кабаланып яшәмәде, ашыгып эшләмәде». Чикләвек йомарламыдай бу җөмләгә нинди дә булса яңалык өстәү мөмкин түгелдер кебек.

Йолдызлыкта әле М.Мәһдиевнең замандашлары, каләмдәшләре турындагы сәхифәләргә дә иркенләп урын бирелгән. Бу тезмәдәге бүлекләрнең «Гариф абый!», «Аяз ага!» һәм инде «Онытмадык сине, Фәрваз дус!» дип өндәү билгеләре белән бирелүе, үзенчәлекле бер алым булудан бигрәк, аларны әле дә булса ярату, ихлас сагынуны аңлата лабаса! Т.Галиуллин: «Мин алар белән дус идем», — дип күкрәк сугып мактанмый, ләкин шушы «өч баһадир» (бу фотоның тарихын күпләр хәтерлидер — беләдер) турында авыз тутырып, тел яшермичә язганнарыннан ышанычлы, арка терәге булырдай каләмдәш дусларына җылыягымлы-төртмәле мөнәсәбәте һәр абзац саен диярлек үзен сиздереп тора.

Бу өч әдипне рухи якынлык, татар әдәбиятының язмышы һәм киләчәге өчен җаваплылык берләштергәнен әйтү белән генә чикләнмичә, Т.Галиуллин моның тагын бер тарихи сәбәбен — советлар дәверендә өчесенең дә тоталитар режим камчысын үз җилкәсендә татыган шәхесләр икәнен дә ассызыкларга онытмый.

Үземнән бер штрих. Аяз Гыйләҗев йомшак, җебек кешеләрне яратмады. Үзе исә бәяләмәләрдә кырыс, аяусыз һәм усал телле иде. Шулай бервакыт «Идел-Пресс» ашханәсенә әбәткә кердек. 90 нчы еллар башы бу, гайрәтле КПССның сүтелгән, ишелгәнрәк чагы. Күзләрен күзлек пыяласы аша елтыратып, үзенә хас бер усаллык белән әйтеп салды бу: «Ата коммунистларның кайберләрен тиздән багана саен асып куячаклар!» — ди. Мин моны усаллыктан битәр, үзенең яшьлеген Карлаг лагеренда үткәрергә мәҗбүр иткән совет хакимиятенә таш ыргыту, рәнҗетелгән буыннан үзенчә бер үпкә дип кабул иттем ул чакта.

Т.Галиуллин үзенең язмаларында «Өч баһадир» образына кергән әдипләрнең өчесенә дә югары, гадел, принципиаль бәя бирә, аларның эшчән һәм кешелекле сыйфатларын ача, җанлы образларын тудыра.

Үземнән тагын бер штрих.

Бервакыт (1988 еллар тирәсе) биш язучы Әтнә районына «Волга» машинасында сәфәргә киттек: Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Р.Мөхәммәдиев һәм мин. Мөхәммәт абыйның, гадәттәгечә, «Волга»га утырып (алгы рәттә), уң терсәген машина тәрәзәсеннән яртылаш чыгарып, кәефле генә барган чагы. Юлданиләр генә сөйләшмәдек тә, нинди генә канатлы-шаян сүзләр әйтелмәде икән! Болар хакында аерым мәкалә язарга кирәктер. Тоткан юлыбыз — «Искра» колхозына, аның рәисе, инде үзе дә калын китап чыгарып өлгергән Фәйзи Галиев авылына.

Ул безне бик җылы каршылады. Чын татарча бәлеш кенә түгел, яңа гына ягылган мунча да көтеп тора икән. Тышта ноябрь салкыны. Өлкәннәр, суык тияр дигән сылтау белән, мунчага керүдән баш тарттылар. Р.Мөхәммәдиев алар янында табындаш булып калды. Без Мөхәммәт абый белән тәвәккәлләдек. Аның: «Авыл мунчасын калдыру ярамас», — дигән сүзләре истә калган. Ашык-пошык дигәндәй (бәлеш көтеп тора!) юынып чыктык та, затлы сөлгеләр белән аххух килеп сөртенгәннән соң, карлы сукмактан кире өйгә таба элдердек. Мунча кергәндә юньләп берни дә сөйләшмәдек диярлек. Тән-гәүдә кыяфәтенә карап, мин аның ябыга төшкәнен сиздем,


24.II.1995.

Хөрмәтле Тәлгать дус!

Март аенда мин теге дөньяга китеп барам. Врачлар килде, консилиум булды.

Синең белән әйбәт дус яшәдек, сиңа рәхмәт. Васыятем:

1. Мине озатырга дип укучылар, студентлар алып килә күрмә.

2. Мине бик шыпырт кына үземнең авылга озатачаклар.

3. Транспорт-фәлән мәсьәләсен Р. Мөхәммәдиев, Арча, Н. Мостафин хәл итәр дип уйлыйм.

4. Ренат Мөх-в белән сөйләшкән — мин бик теләр идем (кабердә инде нигә ул!) некрологка университетның бүгенге ректорының да кул куюын (Р.М. бу турыда белә).

5. Бөтен коллективка минем ихтирамымны тапшыр, соңгы сәламемне әйт. Минем балаларым сиңа йомыш белән килсә — ярдәм ит.

Хуш, бәхил бул!

М.Мәһдиев

Коллективка минем бу бәхилләшүемне уч.советта белдер. Күмгәч, билгеле.

М.Мәһдиевнең Т.Галиуллинга язган соңгы хаты. 1995 ел

ләкин яман авыруга тарыганын бөтенләй белми идем. «Мунчада авыз тутырып сөйләшү килешмәс», — дип, икебез дә әдәп сакладык булса кирәк.

***

Т.Галиуллин тарафыннан хакимиятне кулында чорнап тоткан элекке обком секретаре Мирзаһид Вәлиев, бүлек мөдире Мөдәррис Мусин, монстр дәрәҗәсендәге кара цензура башлыгы Динә Шакирҗанова исемнәренә дә конкрет мисаллар аша бик гадел бәя бирелгән. Мәскәү җырын җырлап, татар мәгърифәте һәм әдәбият-сәнгате үсешенә үзләре дә аңлап бетермәстән (!) ирексездән зыян салган бу шәхесләр рәнҗеп ятмаслардыр.

Үземнән тагын бер штрих. «Идел» журналында эшләп йөргән чакларым. Кирәк-ярак ашамлыклар алу өчен, Бутлеров урамындагы атаклы «Горняк» кибетенә кергән идем. Чыгып барам дигәндә генә... Кибет залының бер читендә басып торган Мөдәррис ага Мусинны күреп алдым. Урамда таза салкын вакытлар иде. Колакчынлы бүреген төшереп кигән. Йөз-кыяфәтендә элеккеге тәкәбберлекнең чалымнары юк диярлек. Менә шул чакта нигә аңа сүз кушмавым, тәүбәгә килдеме-юкмы икәнен җай гына белешмәгәннәрем өчен әле дә булса үкенеп куям...

***

Китапның бер урынында мине Т.Галиуллинның: «Дусларын, танышларын искә алганда, янә бер кешене онытсам, Мөхәммәт мине гафу итмәс иде», — ди. Ул — ифрат киң күңелле, кунакчыл, ул чактагы Бауман районы администрациясе хезмәткәре, керәшен татары Николай Егорович Мышев («Югарыч» — Мәһди биргән кушаматы). Бу егетне азмы-күпме мин дә беләм. Бауман район советы депутаты булгач, әле шуннан соң да дүрт-биш чиновниктан суыткыч сатып алу турындагы рөхсәт кәгазенә култамгалар җыйгач, ул миңа иптәшләрчә ярдәм күрсәткән иде. Алда әйткәнемчә, тел яшереп тормастан, Т.Галиуллин «Сөяксез тел» дигән шушы бүлектә тормышындагы хәлләрне ничек булган, шулай күрсәтеп, Мәһдинең сүз айгырын оста уйната белүен, җорлыгын тасвирлы һәм сурәтле итеп яза.

Тагын шунысы игътибарга лаек: Т.Галиуллин Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, билгеле ки, М.Мәһдиев әсәрләренең хикмәтен, серен, яшәүчәнлеген аңлатып, бик тә кызыклы фикерләр әйтә. Аларның үзара дуслыгын тасвирлаганда бу дуслыкның башка каләмдәшләренә

каршы юнәлмәгәнлеген билгеләп, затлы фикер үткәрә.

М.Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала» повестена бәя биргәндә, ул бөтенесен бер җөмләгә сыйдырган шикелле: «Повестьнең һәр бүлеге, һәр җөмләсе, күзәнәге, сүзе, тыныш билгесе татар халкына, аның яшәү, фикерләү рәвешенә олуг мәхәббәт белән сугарылган», — ди. Кыскасы, М.Мәһдиев феномен, аның милли язучыбыз икәнлеген бүлекләрнең күбесендә диярлек бик күп дәлилләр, аргументлар белән ныгытып бара.

***

Бу язмам гел мактаулардан гына тормасын дип, Т.Галиуллин хезмәтеннән кимчелекләр эзләргә дә тырышып карадым, билгеле. Мин боларны әллә ни табалмадым.

Шулай да кайбер вак-төякләрне әйтеп узарга була. Мәсәлән, Тукай заманнарыннан килгән «мисле», «өслүб», «мәүзугъ», «дәкыйка», «нәзик», «зәмин», «менәз» кебек архаик сүзләрнең дистәләрчә тапкыр кабатланып килүе, миңа калса, үзен аклап бетерми кебек. Ни әйтсәң дә, мондый борынгы сүзләрне кулланганда, чама хисе дә кирәктер. Вак-төяк булса да әйтик: Фәрваз Миңнуллин турында бик яратып, хөрмәт белән язылган бүлекләрдә «азау тешен суырып» дигән гыйбарәнең еш-еш кабатлануы да автор файдасына түгел.

Аннары ки, шома-җайлы гына укып барган җирдән, берничә урында «тимер-бетон» җөмләләргә «абынып» калдым. Уемны бер генә мисал белән ныгытам: «Язмыш безне сайламыйча, үзебез аңа хуҗа була алсак, Мәһдиев хатынының атасы, бәлки, үзе кебек үткен йөгерек телле, очрашуларны, яшьләрчә әйтсәк, «продвинутый» кешене сайлап алыр иде». Тагын әнә шундый чытырманлы, тиз генә үзләштереп булмый торган җөмләләргә берничә урында тап булдым мин. Йөгерек телле Т.Галиуллинның каләмен мондый җөмләләр бизәми, әлбәттә.

Болар — вак кимчелекләр, билгеле. Иң мөһиме: татар дөньясындагы зур шәхесләр, тере әдәби хәрәкәт һәм андагы тирән бәйләнешләр бар. Полифоник, ягъни төрле аваз гаммалары, минор һәм мажор төсләр белән тукылган колачлы әсәр иҗат ителгән. Андагы вакыйгалар һәм хикәятләр калейдоскоптагы кебек гел үзгәреп, алмашынып торса да, бербөтен тормыш панорамасын тәшкил итә.

Т.Галиуллин үзенең бу күләмле хезмәтендә М.Мәһдиев иҗатындагы халыкчанлыкны, туган җиргә мәхәббәтне, геройларның халәтен табигать күренешләре аша бирү, кешеләрне юмор һәм тормышчан детальләрдә ача алу осталыгына ия язучыны гына түгел, аның рухи яктан торгынлык кичермәгән әдип һәм шәхес икәнен кие буяулар, төгәл мәгълүмат һәм тасвирлар аша гәүдәләндергән дисәк, бу һич кенә дә арттыру булмастыр. Татарның Мөхәммәт Мәһдиев кебек шәхесне күрми үскән буыннары өчен дә бу, һичшиксез, өстәл китабы булып торырлык.

Безнең бабайлар шундый акыллы фәлсәфә әйтеп калдырган: башкаларны олыласаң, үзең дә зур булырсың. Мәһдиевнең бай табигатьле кеше булуы турында сөйләп, Т.Галиуллин үзенең дә әзерлекле татар әдибе икәнлеген раслап күрсәтә.

Мин узган гасыр уртасындагы бер шигарьне яхшы хәтерлим: «КамАЗ безне күтәрде, без КамАЗны күтәрәбез!» Автор, замандаш әдибен югары мөнбәргә күтәргән кебек, үзенең шәхесен һәм каләм — фикер куәсен дә әнә шундый югарылыкка күтәргән. Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителгән әдип Тәлгат Галиуллинның бу китабы, һичшиксез, хуплауга лаек.

Ике әдипнең сүзенә һәм иҗатына алга таба да хәерле юл, мәрхәбә! ■

РӘФИКЪ ЮНЫСКА 70 ЯШЬ

ШАГЫЙРЬ, ПУБЛИЦИСТ, Г.ИСХАКЫЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ӘДӘБИ ПРЕМИЯ ЛАУРЕАТЫ, «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ **РӘФИКЪ ЮНЫСКА** ШУШЫ КӨННӘРДӘ 70 ЯШЬ ТУЛДЫ. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ АНЫҢ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.



АЛДА БЕЗНЕ НИ КӨТӘ?

– Шагыйрь, публицист, мөхәррир; йөгерешче – стайер – марафончы!.. Бер кеше өчен бик күп түгелме? Рәфикъ абый, марафончы-йөгерешче башка спортчылардан кайсы сыйфаты белән аерыла? Мин кайбер аерым билгеләрен әйтә алам: нәфис гәүдә, тыгыз мускуллар. Болары тышкы билгеләр. Ә эчтә, күңелдә нинди утлар яна?

— Кызык сорау. Бу турыда уйлаганым юк иде әле... «Күкләргә» ялганышың көчле булмаса, илһам дигән Сизгербикә, Нәфисбикә сине уратып уза башларга, шигырьләрең, примитивлашырга да мөмкин. Ләкин ул ярдәм дә итә аладыр. Дөньяга, тормышка «гамь» дигән көчле антенна аша ялгану шигъриятне көчәйтеп тә куйгалыйдыр. Ә минә мөхәррирлек арыта, шигырьнең тансыклыгын киметә. Кыскасы, өч башлы «иҗат аждаһасы» булу бер дә җиңел түгел ул.

...Марафон ул иң әүвәл, әлбәттә, түземлек. Һәм шул түземлекне тәэмин итеп торган эчке дәрт. Җиңү хәбәрен ирештерәм дип чапмасаң да, җиңүгә омтылу. Хәтта җиңүдән ерак булып, шушы авыр дистанцияне күңелең теләгәнчәрәк йөгереп үтә алу да зур ләззәт бирә. Минем өчен бу инде — үткәндәге хәлләр, ләкин кайчан, ничек йөгергәнемне һәм йөгергәндә ниләр кичергәнемне әлегәчә оныта алмыйм. Тик төгәлләнмәгән бер марафонымны исә күңелдән әле хәзер дә кат-кат йөгереп бетерәм.

Марафон буенча республика беренчелеге иде бу. Мондый кимәлдәге ярышта әле беренче тапкыр гына катнашуым. Үзәк стадионнан чыгып китеп, Аккош күле яныннан үтеп, Горький юлы буйлап җәмгысе 21 чакрым баргач, кире борылдык. Мин, шуңарчы «тыйнак кына» урта тирәдә барган яшь марафончы, ару әсәре юклыгын чамалап, алдагы берәүне уздым. И, рәхәт соң узу! Шулай узгалый торгач, иң алдагы төркемгә дә якынайдым. Ләкин куркыта да: марафон 30 нчы чакрымнан соң гына башлана бит ул. Менә ул чик тә үтелде, ә мин һаман

«исән» әле! Һәм ул 7-8 кешене дә берәм-берәм «чүпли» башладым. Инде Идел күперенә якынаеп киләбез, көч-гайрәт тулы, кәеф искиткеч шәп! Һәм шунда... сул аякның тез турысы кинәт үтереп авырта башлады. Асфальт юлда гәүдә авырлыгының дистә меңнәрчә тапкыр аякка төшеп алуыннан көч килгән инде. Туктап калдым. И авыр да булды соң стадион күренеп, дәшеп торган, Татарстанның иң көчле марафончылары арасына керәм дигән чакта шул рәвешле туктап калу! Җиңелчә йөгергәләүләрдән нибары бер-ике ел эчендә шулай марафон режимына күчү дә китергәндер инде бу травмага... Шуннан соң ничәдер атна йөгерә алмадым, ләкин өч айдан 50 чакрымлы йөгерештә өченче урынны алдым.

Марафон әзерлегенең тәнгә ни бирүенә килсәк, фиништан соң йөрәкнең 240 тапкыр типкәне булды. Ягъни секундка 4 тапкыр типкәндә дә шартламаган ул. Иртән исә 37-38 тирәсе дә булгалый иде. Эшкә (7 чакрым) йөгереп бару, йөгереп кайту җип-җиңел нәрсәгә әйләнде. Мәскәүнең «Украина» кунакханәсендә подвалдан 37 нче катка йөгереп менә алдым. Болай, кызык өчен генә инде.

– Син беркайчан да публичный булырга теләмәдең... Ә үзең – публицист. Синең аерым публицистик язмаларың да, күренекле шәхесләр белән үткәргән әңгәмәләрең дә бик мәгънәле, һәрчак көтелмәгән яңалыклар ача. Әмирхан Еники, Равил Фәйзуллин, Миргазиян Юныс, Фәндәс Сафиуллин, Адлер Тимергалин, Рәшит Сюняев һәм тагын дистәләрчә шәхесләр. Аларны берләштергән уртак сыйфат нәрсә? Син шул уртак сыйфатларны эзлисең дә бугай.

— Сара Садыйкова, Мөхәммәт Мәһдиев, Шәриф Хөсәенов, Шәүкәт Биктимеров белән җитмешенче елларда үткәргән әңгәмәләремнең үзәгендә — аларның иҗади һәм шәхси үзенчәлекләре. Бер-берсенә шул беркемгә охшамаулары белән охшаган бу гаҗәеп затлар белән гәпләшүе бик тә тансык иде һәм рәхәтлек бирде миңа. Туксанынчы елларда исә «Тәфсилле әңгәмәләр» үткәрә башладым. Бусы инде сорауларга җавап алу гына түгел, чын әңгәмәләр. Үзәктә исә һәрчак татар язмышы, Татарстан язмышы.

– Бу темага килү ничек булды соң?

— Килмәскә дә мөмкин иде. Мәктәптә шәп укыган бик тә тәртипле бала идем мин. Бөтен «кызыл» тәрбияне сеңдереп кенә бардым. 1953 елның 5 марты да күңелгә кап-кара көн булып уелып калды әнә. Безнекеләр әле чәй эчеп утыра, ә мин, ун яшьлек малай, инде торып, кара тәлинкә — радио янына килеп басканмын. Кайгылы тавыш (Левитанныкыдыр) җәлеп иткән инде мине. «...скончался товарищ Сталин», дигәнне ишеттем дә, әтидән: «Скончался» ни дигән сүз ул?» — дип сорадым. «Үлгән» дигән сүз», — диде әти. Шунда мин, дикторныкыннан да кайгылырак тавыш белән «Сталин үлгән!» — дип игълан иттем. Ул көнне (әллә икенче көннеме, бәлкем, бу көндезге я кичке як булгандыр) мәктәпкә дә кайгыга батып бардым мин. Авыр ишекне ачып килеп керсәм, коридорда балалар чабышып,

көлеп, уйнап йөриләр. Аптыравымның һәм нәфрәтемнең иге-чиге булмады! Һәм бу пионер өчен милли мәсьәлә юк иде.

– Әтиең берни дә әйтмәдемени соң? Мулла нәселеннән бугай бит инде син, Рәфикъ абый?

— Юк, Илфак әфәнде, четерекле темаларга бер генә сүз дә әйткәне булмады аның. 37 нче еллар аша (шөкер, исән-имин) үткән кеше бит ул. Үләр алдыннан, мине дәшеп алып, нәрсәдер әйтәсе килде аның, ләкин әйтеп өлгермәде шул…

– Милли мәсьәлә кайчан синең «көн тәртибеңә» басты инде?

— Совет тарихчыларына рәхмәт — шулар кертте аны минем аңга. Казанны алуның шәп, прогрессив эш булуын әйтү белән бергә алар шундый мәгълүмат та биргәннәр: Казанны камаучылар — 150 мең, татарлар исә 30 мең генә булган. Ләкин алар батырларча сугышканнар. Күңелгә салып калдырылган шушы орлык, күп еллар үткәч, шытым биргән инде. Күңелдә һәм башта үзгәрешләр ничек барганын әйтә алмыйм. Әмма 1978 елны ошбу шигырь юллары язылган:

Һәркайсыгыз тарихыбыз, телебездән
Баш тартсагыз да,
нәрсәдер отар булып,
Үлмәс әле бөек халык, яшәр әле:
Мин калырмын җирдә
соңгы татар булып.

– Шагыйрь Рәфикъ Юныс – табигать баласы. Табигатьнең үзе кебек камиллек, сафлык, ихласлык хас синең шигъриятькә... Публицист буларак исә тынгысызлык, таләпчәнлек һәм хәтта усаллык та бар кебек. Бу бигрәк тә «Татарстан референдумы» дигән китабыңда ачык чагыла. Әлеге китапка ничек килдең син?

— Өч президент белән бер түбә астында утырып алган кеше мин. Брежнев белән Мәскәүдә хоккей карадык — «Спартак» һәм Ленинградның армия клубы уенын… 1990 елның 9 августында Язучылар берлегенең Тукай



клубында Ельцин татар зыялылары белән очрашты. Шунда ул Татарстанга Россиядә шәп булачагын, Россия составыннан чыкмаска кирәклеген кат-кат әйтте. Мин аңар язып җибәргән: «Татарстан моңа күнмәсә, мөстәкыйльлек алып чыкса, ни булыр?» — дигән сорауны бик тырышып укып чыга алгач, җилкәсен җыерып: «Ул чакта берни дә эшләп булмый инде», — диде. Бераз соңрак шул залда ук: «Суверенитет»ны булдыра алган кадәр алыгыз», — дигән сүзне дә әйтте ул…

Горбачёв Михаил Сергеевич белән, ул Россия президентлыгына кандидат буларак сайлаучылар белән очрашуга килгәч, Казан авиация институтының төп бинасында «гәпләшү» насыйп булды. Татарстанны союздаш республика итү теләге бик көчле иде бит. Татарстан җитәкчеләре әйтүенчә, мондый вәгъдә алынган да булган. Горбачёвтан мин: «СССР таркалмаган хәлдә, Сез, чыннан да, Татарстанны союздаш республика итәр идегезме?» — дип сорадым. Һәм моңа тагын әле әһәмиятсезрәк сорау да өстәдем. Ул менә шул сорауга озаклап, урап-урап җавап бирде

дә утырды. Мин, янә торып басып: «Михаил Сергеевич, беренче сорауга да җавап бирегезче инде!» — дидем. СССРның экс-президенты шунда: «Ә мин ул сорауга җавап бирдем инде», — диде. Горбачёвның нindirәк кеше икәнен мин әнә шул хәлдән соң чамалап калдым.

Боларны сөйләвем шуңа: бер генә милли оешмага катышлы булмасам да, бер генә практик эш башкармасам да, Суверенитетка бәйле үзгәрешләрне тансыклап, сөенеп көтеп алдым мин һәм һәр вакыйганы күңелгә сеңдереп бардым. Референдум ае исә (үткәрү турында карар кабул ителү белән референдум көне арасы) бөтенләй тынычлыгымны алды. Түзмәдем, референдум участокларының берсендә күзәтүче булдым. Референдум үткәч, аның хакындагы хәбәрләрне җыеп бардым. Һәм референдумны тарихка тәфсилләп теркәп калдырачак саллы язма кайчан басылып чыгар икән дип түземсезләнеп көтә башладым. Юк та юк бит! Аптырагач, бу хәлләрне шәп белгән каләмдәшләргә һәм сәясмәннәргә*, «Идел»дә чыгарабыз дип (баш мөхәррир урынбасары идем бит), үзем дә тәкъдим итеп карадым, ләкин берәү дә алынмады бу эшкә. Шунда тәмам куркуга калдым. Татар тарихындагы иң олы казанышларыбызның берсе — ошбу референдум тере вакыйга буларак бөтенләй җуелачак бит! Шуннан, сәяси темаларга язу тәҗрибәм бик аз булса да, тәвәккәлләп, үзем тотындым. Референдумга һәм тулаем суверенитет чорына караган матбугат язмаларын укып чыктым, Югары Совет утырышлары беркетмәләрен, референдумга кагылышлы документларны җентекләп өйрәндем. Бу вакыйганың үзәгендә кайнаган кешеләрнең барысы белән дә диярлек сөйләшеп чыктым (аларның икесе, Сәйфихан Нәфиев һәм Марат Мөлеков, мәрхүмнәр инде). Менә шуннан соң язылды инде ошбу документаль әсәр.

– Бу китап белән син, Рәфикъ абый, анда тасвирланган каһарманнар кебек, гүяки үзең дә әдәби каһарманга әйләнеп барасың... Без бик катлаулы егерме ел кичердек. Суверенитет темасы – олы тема. Мәңгелек тема. Яңа буын, яшь буын язучылар аңа алынырга бик җөрьәт итмиләр әле. Син, Рәфикъ абый, бу юнәлештә тагынниләр эшлисең? Каләмдәшләребез, әдәби җәмәгатьчелек, зыялыларыбыз ни эшләргә бурычлы?

— Һаман шул: язам да язам инде. «Яхшылык эшлә дә суга сал. Халык күрер, халык күрмәсә, балык күрер», — дигәндәй, сүзеңне милләттәшләреңнең аңына, күңеленә җиткезә алу могҗизага тиң эш хәзер.

Әйткәнемчә, 1992 елның 21 мартында суверенитет мәсьәләсен халык үзе хәл итте. «Сез Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коруына ризамы?» — дигән сорауга тавыш бирүчеләрнең 61,39 проценты «әйе», дип җавап бирде. Референдум карары нигезендә, 1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Конституциясе кабул ителде. 1994 елның 15 февралендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасындагы Шартнамәгә кул куелды. Димәк, суверенитетыбызны хәтта Рәсәй үзе дә таныды! Димәк, Татарстан халкы мөстәкыйльлегебезнең әҗерен тоеп яшәрлек тормыш корыр өчен бер киртә дә калмады. Һәм моның матди базасы да җитәрлек иде. Татары, урысы, чувашы, тормышның яхшырганнан яхшыра баруын тоеп, сөенепләр яшәгәндә, безнең мөстәкыйльлекне беркем дә җимерә алмас иде. Ләкин моның киресе булды. Шартнамәгә кул куелу белән диярлек чигенү башланды. Нигә? Моңа Рәсәйнең капитализм төзи башлавы сәбәп булды, күрәсең. Ашыгыч

*Сәясмән — политолог

рәвештә миллионерлар һәм миллиардерлар кирәк булды. «Обогащайтесь!» дигән шигарь игълан ителде. Ул безнең җитәкчеләрне дә ымсындырды булса кирәк... Референдум артты — аны хакимият әһелләренең инде телгә алганы да булмады, хәтта ун, унбиш, егерме еллыгында да.

Хәзер исә халык менә шушы өзлексез чигенүнең «әҗерен» тоя. Һәм «суверенитет», «мөстәкыйльлек» кебек сүзләрне мыскыллау кебек кабул итә. Безгә, мөстәкыйльлек тарафдарларына, патшалар, түрәләр күзенә карап кына яшәргә өйрәнгән халыкка аның гаме үзгәрәк тә була алганны төшендерергә кирәк. Ягъни башка илләрнең халыклары инде берничә гасыр элек «киптереп элгән» нәрсәне: халык дәүләткә түгел, киресенчә, дәүләт халыкка хезмәт итәргә тиеш. Ашау, сулау кебек тап-табигый нәрсә — татар кешесенә татар телендә сөйләшү, татар телендә белем алу мөмкинлеген тәэмин итүне һәрдаим кайгыртырга тиешле Татарстан җитәкчелеге бермә-бер активлашырга тиеш.

Кызганыч ки, бүген күп кенә татар газета-журнал редакцияләре, бигрәк тә аларның баш мөхәррирләре, милләтебез өчен хәлиткеч ошбу мәлләрдә татарның киләчәге өчен җитәрлек көрәшмәүдән түгел, кемнәргәдер көрәшкән булып күренүдән куркалар. Юл ярып, алдан барырга тиешле зыялыларыбыз, бик азларны гына санамаганда, 37 нче елларда да булмаган куркаклык белән шәхес түгел, күләгә булып яшәргә дә ризалардыр шикелле.

«Корабыбыз батып барганда...» — «Казан утлары»нда (2008, №12) чыккан бер мәкаләмне шулай дип атаган идем мин. «Титаник»та да кәеф-сафа корып, безнең күк гамьсез, ваемсыз йөзә биргәннәр әнә. Ләкин алар алда ни көткәнен белмәгәннәр бит.

– Безгә хәзер иң әүвәл нишләргә кирәк инде?

— Иң әүвәл берләшергә кирәк. Милләтпәрвәрләр аз хәзер һәм аларның берсе дә фәрештә түгелдер. Ләкин олы уртак каза килгәндә, уртак олы гамь тирәсендә тупланалар бит инде.

Аермыйкчы эзләп тик аерма —
Канат каеручы җитәрлек.
Җилем кирәк безгә, җилем кирәк —
Җиде җилне давыл итәрлек...

– Авыр барды безнең бу әңгәмә, Рәфикъ абый. Берәр сөенечлерәк яңалык белән очлап булмыймы соң аны?

— Әйе, кара кайгыга батмыйк әле. Әйбәт максатка төбәлеп эшлик тә эшлик. Нәтиҗәсе булмый калмас. Туксанынчы еллар эзсез югалмаячак ул. СССРдагы алтмышынчы елларны беләбез бит. Ул «җылынып алу» бик кыска булды. Ләкин туксанынчы еллар дулкынының саллы бер өлешен нәкъ менә шул «һава»ны сулаучылар тәшкил итте. Миңа СССР Югары Советында Ельцин һәм Сахаров белән төбәкара төркемгә җитәкчелек иткән шанлы академик Юрий Афанасьев белән гәпләшү насыйп булды. Татарстанга да, татар халкына да хәерхаһлы чын демократ иде ул. Бездә дә туксанынчы елларның милли һавасын сулаган яңа бер буын үсеп җитеп килә әнә...

«Нинди яңалыклар бар?» — дип сораганда, мин, шаярта төшеп, «искеләре дә ярап тора», дип җавап бирәм. Тормышыбызны җиңеләйтә, матурлый торган яңалыклар да булмый калмас. Ә менә бер яңалык мине бик сөендерде. Бу — «Чын мирас»ның чыга башлавы. Эшләрегез гел уң булсын.

– Рәхмәт, мөхтәрәм Рәфикъ абый! Без, үз чиратыбызда, Сезне гомерегезнең олуг бәйрәме, 70 яшьлек юбилеегыз белән ихластан тәбрик итәбез. Алышларда, ярышларда ал бирмәгән ихтыярыгыз, кайнар йөрәгегез сау булсын. Туры каләмегезгә тугры калыгыз!..

Әңгәмәдәш —
Илфак Ибраһимов

БАТЫРША

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА,
язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты,
тарих фәннәре кандидаты

1756 елның октябрь һәм ноябрь айларында Батырша хәзрәт Мәскәүдә, Яшерен канцелярия төрмәсендә тотыла һәм биредә ул патшабикә өчен аңлатма хатын — «Гарызнамә»не яза. Батырша хәзрәт бу хатны, ягъни сорауларга җавап рәвешендәге аңлатмасын 1756 елның 4 ноябрендә яза башлый һәм аны 21 ноябрьдә тәмамлый. Батыршаның язганын каравыл башлыгы князь Болховский туктаусыз күзәтеп тора, һәр кәгазь бите катгый хисапта була. Төрмә архивы чыганакларыннан күренгәнчә, Батырша хәзрәткә 7 каурый каләм бирелә, каралама өчен бер төргәк саргылт начар кәгазь, акка күчерү өчен бер төргәк яхшы кәгазь бирелә. Батырша хәзрәт үзенең «Гарызнамә»сен башта сорауларга җаваплар рәвешендә караламага яза, аннан инде зур эпик документаль әсәр рәвешендә акка күчерә. Тәрҗемәче Ильяс Моратов ул күчереп язган һәр битне русчага аударып бара. Төрмә белешмәләреннән күренгәнчә, Батырша башта һәр көнне бер бит каралама яза, аны ярты бит акка күчерүдән арттыра алмый. Аннан бу сан 2, хәтта 4 биткә кадәр җитә һәм аннан да артып китә. Шулай итеп караламалары белән бергә, йөз биткә якын күләмле хезмәт барлыкка килә. (РГАДА. ф.7. оп.1. д.1781. ч.1. л.218-223.)

Батырша хәзрәт рус булмаган җирле халыкларның, бигрәк тә мөселман-татарларның фаҗигале хәлләрен тасвирлауны алгы планга чыгара. «Гарызнамә»дә көчләп чукындыру фаҗигаләре бөтен тирәнлегендә ачыла, рус генераллары һәм түрәләренең, христиан дин әһелләренең җирле халыкларга каршы явызлыклары тасвирлана, икътисади изүләр дә өстәлә. Ул чукынмаган өчен татарларга өстәмә салымнар салу турында, көчләп гаскәргә алулар, татарларны кол итеп авыр хезмәттә, лашманлыкта, завод эшләрендә тотулар, аларны бушка шәһәр һәм кальгалар салуда файдаланулар турында патшабикәгә хәбәр итә. Баш күтәрүнең төп сәбәбе булып дини һәм милли изүләр торганлыгын, төп максат динне һәм милләтне саклап калу икәнлеген Батырша хәзрәт ачыктан-ачык яза.

Обер-секретарь Михаил Хрущёв күз алдында бу аңлатма-хат караламалары һәм тәрҗемәсе белән бергә махсус пакетка салына. Пакетка мөһер куяр алдыннан, Батырша рус офицерының хатны падишаһ кулына тапшырачагын тагын бер тапкыр ант белән ныгыта. Хрущёв сүз бирә, Батырша хәзрәт мөһерен куя, махсус хат курьер белән шул көнне үк Петербургка озатыла. Батырша хәзрәтнең бу хаты Яшерен канцелярия архивында бүген дә саклана...

Хат язган көннәрдә бераз терелептернәкләнеп киткән Батыршаның үзен дә Петербургка озатырга әзерли

*Ахыры. Башы журналның 2012 елгы 10-12 нче, 2013 елгы 1, 2 нче саннарында

башлыйлар. Яшерен канцеляриядән тагын әмер килә: «Куркыныч вор Батыршаны ничек тә исән-сау Петербургка алып килеп җиткерергә!» Чөнки аннан әле бик җентекләп сорау алырга җыеналар һәм Батыршаның җаваплары мөселманнарга ярдәм итү өчен түгел, аларны мәңгелеккә бастыру юлларын эзләү өчен кирәк була.

1756 елның 30 ноябрендә, иртәнге якта, кул-аяклары богауланган Батырша хәзрәт көчле сак астында Петербургка озатыла. Аның артыннан ук, 1756 елның 20 декабрендә, Батыршаның хатыны Зөлхәбирә дә кызлары белән Петербургтагы Яшерен канцеляриягә җибәрелә. 1756 елның декабрь урталарында көчле конвой астында Батырша хәзрәтне Петербургка китереп җиткерәләр, Петропавел крепостеның Яшерен канцелярия төрмәсенә ябып куялар. Берничә көннән Петербургка көчле каравыл астында Зөлхәбирә белән кызларын да китерәләр.

Петропавел крепостенда Батырша хәзрәт ел буе диярлек ята, биредә ул кыйнап сорау алу газапларын кичерә, хөкем карарын ишетә, үзен көчләп чукындыруга каршы көрәшә. Кул-аяклары богауланган татар мулласын камерасында көне-төне өч кораллы сакчы каравыллый, караңгы бүлмәдә көне-төне шәм яна... Батыршаны көне-төне кыйнап сорау алалар, ә ул һаман берни сөйләми, һаман патшабикә белән очраштыруларын таләп итә. Явызлыгы белән бөтен Петербургка данлыклы сорау алучы-палач Степан Шешковский да Батыршаның авызын ачтыра алмый.

Патшабикә белән очраштырмаячакларын Батырша инде үзе дә аңлый башлый. Патшабикәгә язган хатына җавап булмагач, Батырша Яшерен канцелярия җитәкчесе Александр Шуваловның үзе белән сөйләшергә ниятли һәм 1757 елның май аенда аңа хат яза. Үзенең патшабикәгә хат язуын генералның исенә төшерә, шуның нәтиҗәләрен сорый. Сорау алучылар белән сөйләшүдән катгый рәвештә баш тарткан Батыршаның үзенә мөрәҗәгать итүенә генерал башта бераз гаҗәпләнсә дә, соңыннан бу бунтарь татар белән очрашырга була. Әмма очрашу бер нәтиҗәгә дә китерми. Батырша хәзрәтнең авыр чагыннан файдаланып, аны чукынуга үгетләү өчен, Петропавел чиркәве побы Стефан Левицкий да татар тоткыны янына кергәли башлый. Поп Батыршага, әгәр христиан диненә күчсә, гаиләсе белән кушылу бәхетен вәгъдә итә, аны чит илләргә илче итеп җибәрү мөмкинлеген әйтә, Россия империясенең теләсә кайсы урыннан йорт-җир бирәселәрен сөйли. Әмма Батырша хәзрәт ирек бәрабәренә дә иманын сатмый, ахыргача мөселман-татар булып кала, чөнки ул христиан динен кабул итсә, үзен дә, милләтен дә утка саласын яхшы аңлый.

1757 елның 24 декабрендә Батыршага хөкем карары чыгарыла.

Баһадиршаһ Туктаргали улы (Габдулла Галиев) патша хакимиятенә каршы коткы таратуда, татар халкын русларга каршы сугышка чакыруда гаепләнә. Бу эштә төп дәлил итеп аның халыкка язган өндәмәсе алына, җирле түрәләрнең Батырша өстеннән язган шикаятьләре дә теркәлә. Шулай ук төбәктә кабынып киткән баш күтәрүләрне дә Батырша исеме белән бәйлиләр. Татар мулласы дәүләт өчен гаять куркыныч кеше дип табыла һәм мәңгелеккә төрмәгә ябарга хөкем ителә. Хөкем карарында шулай ук Батыршаның телен һәм борынын кисеп алу, камчы белән суктыру да күрсәтелгән була. Ике көннән бу карар тормышка ашырыла — Батыршаның тимер кыскыч белән телен һәм борын яфракларын өзеп алалар, камчы белән яралар. Гадәттә, камчы белән берничә тапкыр суктырудан кеше шунда ук үлә, ә Батырша хәзрәтне, төрмә белешмәләреннән күренгәнчә,

40-50 тапкыр суктыралар. Ул исән кала... Канга баткан Батырша мулланы Петербург хәрби гарнизонының көчле сагы астында декабрь азагында су уртасындагы Шлиссельбург крепосте төрмәсенә китереп ташлыйлар. Мәңгелек зинданга ябалар. (Сенатский архив. Т.12. — С.130.)

Хатынын һәм балаларын исә, кулаякларын богаулап, монастырьга ыргыталар. 1759 елда олы кызлары Зөләйха монастырьда үлә, Зөлхәбирә белән нәни Салиха гомерләренең калган өлешен Мәскәү шәһәренең Девичий монастыренда уздыра. Ул вакытта күпчелек монастырьлар татарлар өчен төрмә ролен башкарган, патша хөкүмәте аларның, шул исәптән Батырша гаиләсенең дә иректә булуын теләми, туган якларына кайтып, яңадан ислам динен тота башлауларыннан курка. Рус хакимияте Батырша хәзрәтнең нәселе дәвам итүдән дә курка, шуңа күрә аның бердәнбер кызы Салиханы ирексезләп монастырьда бикләп тоталар.

Зөлхәбирә белән Салиханың язмышына караган соңгы указ 1763 елның 18 сентябрендә чыгарыла, бу фәрманда аларны монастырьда көчле күзәтү астына алырга кирәклеге әйтелә: «По указу ею императорского величества правительствующий Сенат по ведению оной конторы с посланной известного вора и возмутителя башкирцев Батырши жене, воспринявшей веру греческого исповедания Марьи Александровны, дочери и с малолетнею дочерью Верой, в имеющейся в Москве Девичий монастырь, где велено быть ей под присмотром, производя ей и с дочерью пишу против одной монахини, приказали оной Марии и с дочерью её в рассуждении того, дабе оне каким-либо образом на прежнее свое жилище, возвратитца не могли, где б иногда живущим тамо не нанесли какого сумнения, или б ж по-прежнему в магометанский закон не обратились, быть в помянутом монастыре под присмотром».

Батырша хәзрәтнең хатыны Зөлхәбирә турында патшаның махсус указ чыгаруы әлеге мәсьәләнең никадәр җитди икәнлеген күрсәтә. Бу вакытта инде ил белән Елизавета Петровна түгел, ә Екатерина II идарә иткәнлеген дә искә алырга кирәк. Указ Батырша хәзрәт үлеп, бер елдан соң чыгарыла, димәк, хөкүмәт алдына аның гаиләсе белән ни эшләргә дигән проблема килеп баса. Мәңгелеккә монастырьга ябарга, төрмәгә бикләргә! Шулай эшлиләр дә. Алга таба тарихи документларда аларның исеме телгә алынмый, димәк, Батырша хәзрәтнең хатыны һәм кызы монастырьда җан биргән.

Инде Батырша хәзрәтнең үз язмышына килик.

1757 елның ахырында канга баткан, аяк-куллары богауланган Батырша хәзрәтне Шлиссельбург төрмәсенә китереп ташлыйлар...

Шлиссельбург...

Ул — Ладога күленә Нева елгасы койган урындагы утрауга салынган су эчендәге таш крепость. Бөтен яктан да су белән уратып алынган бу кальгада Яшерен канцеляриянең төрмәсе урнашкан. Россия империясе үзенең иң куркыныч дошманнарын монә шушында саклый. Бирсдә, нигездә, патша тәхетенә, рус хакимиятенә куркыныч тудыручы дәүләт дошманнары утыра, алар арасында императорның тәхет көндәшләре дә, Батырша кебек халыкны Россия империясенә, басып алучы русларга каршы сугышка чакыручылар да бар. Патша кызы Мария Алексеевна, патшабикә Евдокия, тәхет варисы Иоан Антонович Шлиссельбург тоткыны булалар һәм шунда үлеп тә калалар. Бәлки, яшерен рәвештә үтерелгәннәрдер. Россия тәхетендә утыручыларга мондый көндәшләр кирәк булмый. Бөек князьлар Дмитрий Голицын һәм Михаил Долгорукий да шушы төрмәгә ябыла. Заманында патшага тел тидергән нәшер Иван Новиков та Шлиссельбург тоткыны була.

Крепость яр читеннән үк биек таш стеналар белән уратып алынган. Таш дивардардан тугыз каланча-бастион калкып чыккан, алардан кораллы сакчылар көне-төне тирә-юньне күзәтә. Сакчылар шулай ук крепость стенасының ике ягына да тезелеп баскан, алар бирелә күренгән тоткыннарга кисәтүсез атарга тиеш булган. Күп очракта патша хакимияте үзенең көндәшләрен шушы юл белән үтерткән, имеш, качып барганда атканнар... Стенаның эчке ягында — Яшерен канцелярия төрмәсе, ул тагын бер кат таш дивар белән әйләндереп алынган. Төрмәдән ерак түгел — каберлек, Шлиссельбург тоткыннарының соңгы йортлары да шушында...

Бу төрмәдә дәүләт сере шулхәтле нык саклана ки, тоткыннарга хәтта үзара аралашырга да рөхсәт итмиләр. Һәр тоткын аерым камера-бүлмәгә бикләнгән һәм һәр тоткынны сакларга 3-4 кораллы сакчы куелган була. Бу солдатлар, бер-берләрен чиратлашып алыштырып, көне-төне тоткын белән бер бүлмәдә яшиләр, тоткын турында берни белмәскә, сорашмаска, аның белән аралашмаска тиеш булалар. Әйтерсең лә үзләре дә тоткын... Шуңа күрә бу сакчылар котырган эт кебек явызлана, үзләрен шушы хәлгә куйган хуҗаларыннан ала алмаган үчне еш кына мескен токыннардан ала. Кеше түзә алмаслык шушы шартларда Батырша хәзрәт биш елга якын газап чигә...

1758 ел...

1759 ел...

1760 ел...

1761 ел...

1762 елның 24 июле...

Һәр мизгеле, һәр сәгате, һәр көне тоташ җәберләрдән торган дүрт ел ярым гомер... Ул үзенең бирегә мәңгелеккә ябылганын белә, тик ул мәңгелекнең кайчан бетәсен генә белми...

Таш капчыкта богауланып яткан Батырша тышкы дөньяда барган күп нәрсәләрне дә белми. 1762 елның 5 гыйнварында патшабикә Елизавета Петровнаның кинәт кенә үлеп китүен, аның урынына тәхеткә Петр IIIнең утыруын да, Пётр IIIнең Пруссия белән сугышны туктатуын, немецлар белән тагын дуслашуын, илдә бөтен кешенең котын алып торган Яшерен канцеляриянең юкка чыгуын да белми әле ул... Үзен 1762 елның башында Себергә, Нерчинскига каторгага сөрү турында Сенат карары барлыгын да белми ул. Бу карарның үтәлүен шул ук Пётр IIIнең туктатып торуын да белми Батырша хәзрәт. Нәкъ шушы көннәрдә Пётр IIIнең үзен тәхеттән бәреп төшерәчәкләрен, аның урынына хатыны — Екатерина II утырасын да белми...

1762 елның июнь ахырында, Батыршаның үлеменә бер ай кала, Россия тәхетенә Екатерина II утыра, шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, дәүләт өчен куркыныч дип табылган кешеләр тиз генә юк ителә. Бәлки, Батырша хәзрәт тә шушы «чистарту пычагы»на эләккәндер дигән версияләр бар. Себергә каторгага җибәрелергә тиешле Батырша хәзрәт 1762 елның 24 июль төнендә Шлиссельбург төрмәсе сакчылары белән бәрелештә һәлак була. Кайбер тарихчылар Батыршаны рус сакчылары агулап яки кыйнап үтергән, дип бара, төрмә архивында сакланып калган документлар исә Батыршаның үзен «гаепли». Аннан күренгәнчә, Батырша, кул-аяклары богаулы килеш, берьюлы дүрт сакчы белән сугышкан, икесен балта белән чабып үтергән, икесен яралаган. Һәм үзе дә егылып үлгән...

Әлеге хәл күпне күргән Шлиссельбург төрмәсе өчен дә зур вакыйга була һәм бу хакта икенче көнне үк Сенатка хәбәр итәләр:

«Правительствующему Сенату от подполковника Шлютельбургского

коменданта Ивана Бередникова доношение.

У содержащегося в Шлютельбургской крепости колодника Батырше находились на карауле с данною на тот караул инструкциею полков Санкт-Петербургского гарнизона, а именно Невского капрал Данила Никитин, солдаты Максим Хомутов, Григорий Епифанов, Санкт-Петербургского Андрей Лазарев, который колодник, имев у себя ногах ножные с заклёпом железа, а на руках наручник, сего июля на 24-е число по полуночи в первом часу, напав на оных, во-первых, на капрала, и солдат спящих, на которых и бывший на часах солдат Епифанов при зажжённой свече заснувший был, о чём он уже извинение принёс, что подлинно спал. Оной колодник, взяв принесённый в казарму солдатом Хомутовым топор (которого, також никакого орудия, чем человек может себя повредить, по данной на тот караул инструкции в арестанской казарме иметь было запрещено, сверх того, чтобы он из-под караула утёски не сделал, на собою ж и караульному каковы повреждение таковыми орудиями не учинил), по одиночки у капрала Никитина тем топором голову разрубил на двое, у солдат — у Хомутова головы левую сторону разрубил и правый висок проломлен, у Лазарева в двух местах брюхо пропорото, у головы же по левую сторону тела схватил, у Епифанова, который был на часах, в двух местах голову разрубил же, из которых капрал Никитин, солдат Хомутов сего же числа умерли. А Лазарев и Епифанов лекарем пользуютца. Оной же колодник Батырша и сам умер без всяких язв и побой…» (Витевский В.Н., Неплюев И.И. и Оренбургский край. — С.883-884; Гернет М.Н. История царской тюрьмы. — Т.1: 1762-1825. — М., 1960. — С.229.)

Әйе, Батырша хәзрәтнең соңгы явы да тарихка кереп кала — ул аяк-куллары богаулы килеш дүрт коралллы сакчы белән алыша, аларны җиңә, иреккә чыга һәм… Һәм мәңгелеккә күчә…

Ул үлемне җиңә… Ул империяне җиңеп китә… Ул Шлиссельбург төрмәсеннән качкан һәм ирек юлында үтерелгән бердәнбер тоткын була.

Татар халкының соңгы җиһад сугышчысы Батырша мулла, үзенең антына һәм өндәмәсенә ахыргача тугрылыклы булып, бер ялгызы яу кырында ятып кала…

Каһарманнарча китүе белән дә ул дастаннарга тиң тарих калдыра, батырлык үрнәге калдыра, өмет орлыклары чәчеп калдыра…

***

Батырша милләтенең бәхете, дине һәм ирегe өчен шәһит китә, Әле Батырша хәзрәт ирректә чагында ук, 1755 елның 3 сентябрендә, патшабикә Елизавета Петровна яңа указ чыгара. Бу указында ул чукынмаган татарларны көчләп башка урынга күчерүне вакытлыча тыя, ягъни, авылда чукынган татарлар булса да, мөселман-татарларны алар өчен генә авылларыннан кумый башлыйлар. Татарлар яуга күтәрелмәсен өчен, патша хөкүмәте хәтта көчләп чукындырудан да вакытлыча чигенеп торырга мәҗбүр була.

1755 елның 26 сентябрендә патшабикә татарлар файдасына тагын бер указ чыгара. Аның нигезендә, мөселман татарлар чукынган татарлар өчен рекрут бирүдән азат ителә, ягъни чукынмаган татарлар чукынганнар өчен мәҗбүри армия хезмәтен үтми башлый. Шулай итеп, Батырша хәзрәт куйган таләпләрнең бер өлеше инде бер ай эчендә үтәлә. Көчләп чукындырулар, чукынмаган өчен артык салым түләүләр, керәшеннәр өчен армия хезмәте үтүләр, чукынмаган өчен авылдан сөрелүләр патша указы белән туктатыла. Татар күтәрелешеннән коты чыккан Рәсәй хөкүмәте аларны тынычландыру өчен алга таба тагын да

зуррак адымнар ясый — 1756 елның 23 сентябрендә Сенат «О допущении татар магометанского закона, жительствующих особыми деревнями в Казанской, Нижегородской, Астраханской и Сибирской губерниях к постройке мечетей, и о переселении новокрещённых татар в другие деревни» дип аталган указ чыгара. Ягъни татарларга авылларында мәчетләр салырга рөхсәт ителә һәм инде катнаш авыллардан мөселман-татарлар түгел, чукынган татарлар күчеп китәргә тиеш була.

Мөселманнарның таләбен искә алып, көчләп чукындыруда татарларның бәгыренә төшкән Казан архирее Лука Канашевич һәм Тубыл митрополиты Сильвестр Гловацкий башка урынга күчерелә. Татарларга дәүләт бирүгә караганда, бу ташламаларны ясау Россия өчен күпкә отышлырак икәнен патша хөкүмәте яхшы аңлый...

Батырша күтәрелешенең сәяси файдасы булган кебек, ул халыкның икътисади хәлен дә бераз җиңеләйтә. Җирле халыкның үзенә каршы зур яуга кузгалуыннан курыккан патша хөкүмәте татар һәм башкортларга җир һәм тоз салымын азайта, халык хезмәт күрсәтергә теләми торган почта станнарын бетерә, татар һәм башкортларны Оренбургка бушка казна урманы ташудан азат итә, халыкны теләсә ничек походларга (хәрби өйрәнүләргә) җыймый башлый. Башкортларга хәтта турыдан-туры Россия җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәргә рөхсәт бирелә.

«Ислам динен юкка чыгаруны максат итеп куйган, камчы һәм кылыч ярдәмендә алып барылган чукындыру сәясәтенә каршы мөселман татар халкының фидаи көрәше генә чукындыру сәясәтен туктатырга һәм Россия хакимиятен ислам динен рәсми тану юлына басарга мәҗбүр итә. Восстание җиңелсә дә, төп максат — патшабикә Елизавета Петровнага мөселманнарның аяныч хәле турында хәбәрләр барып җитә, ә хакмият органнары мөселманнарны тынычландыру өчен иң мөһим чараларны тормышка ашырырга мәҗбүр була». (Ислаев Ф. Батырша восстаниесе. 1755 ел. — Казан, 2005. — Б.114).

Батырша күтәрелешен махсус өйрәнгән һәм бу хакта берничә китап язган тарих фәннәре докторы Фәйзелхак Ислаев бу күтәрелешнең Идел-Уралда ислам динен саклап калуда зур өлеше барлыгын әйтә: «Именно восстание Батырши стало поворотным пунктом в изменении государственной политики в отношении ислама, — дип яза ул. — С этого момента начинается постепенный поворот от религиозной нетерпимости к толерантности... Основной урок восстания Батырши заключается в том, что принуждение мусульман в духовной сфере порождает только ответное насилие со стороны верующих». (Ислаев Ф. Восстание Батырши. Год 1755. — Казань, 2004. — С.140, 144.)

Әйе, татар халкы Батырша хәзрәтне үзенең милли каһарманы итеп таный, аны ярата һәм олылый. Аның турында заманында күренекле дин белгече Риза Фәхретдин дә, тарихчылар Газиз Гобәйдуллин, Габделбари Баттал-Таймас та зурлап үз фикерләрен язып калдырган. Батырша хәзрәтнең хезмәтләрен һәм абруйлы исемен халыкка кайтаруда галимнәр Мәсгуд Гайнетдин, Сәлам Алишев, Марсель Әхмәтҗанов, Фәйзелхак Ислаев, Раиф Әмиров, язучылар Җәмит Рәхимов, Вахит Имамов, Дамир Гарифуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Кыям Миңлебаев, Эдуард Мостафин, Ркаил Зәйдулла, Хәмзә Шәрипов һәм башка зыялыларыбыз күп көч куйды. Батырша явы турында романнар һәм поэмалар язылды, күпсанлы публицистик язмалар дөнья күрде, фәнни-гамәли конференцияләр уздырылды, тематик китаплар һәм брошюралар чыгарылды, музейлар ачылды, рәсемнәре ясалды. Батыршаның образын мәңгеләштерүдә

аның якташы, рәссам Мэлс Вафин зур хезмәт куйды.

Башкортстан галимнәре арасында да Батыршага һәм аның көрәшенә дөрес бәя бирүчеләр бар. Әйтик, галимнәр Д.Вәлиев һәм Р.Янгузин үзләренең хезмәтләрендә ул чорга һәм Батырша шәхесенә гадел бәя бирергә тырышалар. Дамир Вәлиев Батырша күтәрелешенең төп сәбәбе итеп мөселманнарны дини яктан кысуны күрсәтә, шул ук вакытта бу күтәрелешнең иҗтимагый-сәяси протест икәнлеген дә әйтә, Батырша хәзрәтнең милләткә өндәмәсен басып алу сәясәтенә каршы программ документ дип атый.

«Воззвание это, имевшее программный характер, является ярким памфлетом против колониальной политики в Башкортостане, — дип яза ул. — К тому же отличительная черта его — это конкретность и наличие ответа на вопрос, что должен делать угнетённый народ… В воззвании содержится не только призыв к вооружённому выступлению против колониального рабства, но и разоблачается стратегия и тактика колонизаторской политики России на восточных окраинах… Слова Батырши оказались пророческими: время показало, что политике России, а затем и СССР в Казахстане и Средней Азии никогда не был чужд дух экспансионизма… Самым большим злодеянием русского царизма, по мнению Батырши, является насильственная христианизация, что и было основной причиной выступления Батырши с призывами за освободительную войну всех мусульман против христианской России». (Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755-1756 гг. — Уфа, 2000. — С.67-70.)

Башкорт галиме Р.Янгузин да, Батырша хәзрәтнең татар телендә язылган өндәмәсен һәм «Гарызнамә»не өйрәнеп, аларга нигезләп, Батыршаны зур сәясәтче һәм акыл иясе дип атый, Россиядә булып узган күтәрелешләр тарихында аның белән янәшә куярлык кеше сирәк, дип яза. Өндәмәнең колониаль сәясәткә каршы программа икәнлеген әйтә, Батыршаның күтәрелешне оештыручы булуын таный, аның төп максаты бу җирләрдән басып алучыларны куып чыгару икәнлеген ассызыклый.

«Из руководителей народных восстаний в истории России редко кого можно поставить рядом с Габдуллой Галиевым — Батыршой… Батырша — политик и мыслитель… Единство всех мусульманских народов тогдашней России в вооружённой борьбе против колонизаторов — вот основная идея Воззвания Батырши. «Объединяйтесь! Объединяйтесь! Объединяйтесь!» — призывал он». (Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755-1756 гг. — Уфа, 2000. — С.72-74.)

Бүген Батыршаның туган авылы Карышбашта (Башкортстанның Балтач районы) аның исемендәге мәктәп бар, мәчет төзелде, ә район үзәге Балтачта 2003 елдан бирле Батырша музее эшләп килә, мәчет тә аның исемен йөртә. Бу музей белән гаярь милләттәшебез, районның мөхтәсиб-имамы, Батыршаның якташы һәм ерак туганы Рафис хәзрәт Шәйхәйдәров җитәкчелек итә. Бу музей-йортта Батырша хәзрәткә һәм шул чорлар тарихына кагылышлы кыйммәтле ядкәрләр тупланган, шуларның иң кадерлесе — Батырша хәзрәтнең китапханәсе. Гарәп әлифбасында язылган дини һәм мәдәни кулъязма китаплардан торган 80 томлык бу китапханәне Рафис хәзрәткә бабасы биреп калдырган булган, ул башта чормада сакланган, хәзер музейның түрендә урын алган. Шунысын да әйтергә кирәк: һәр кулъязма китап кимендә 600-700 биттән тора, чит-читләрендә Батырша хәзрәт үз куллары белән язып калдырган

искәрмәләр дә саклана. Музейга шулай ук Батырша хәзрәтнең халыкка өндәмәсе һәм патшага язган хатының фотокопия-күчермәләре дә куелган.

«Азатлык» татар яшьләре берлеге 2012 елны «Батырша елы» дип игълан итте, чөнки 2012 елның 24 июлендә Батырша хәзрәтнең һәлак булуына 250 ел тулды. Шушы нисбәттән Казанда һәм Чаллыда, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә төрле милли һәм дини чаралар үткәрелде, календарьлар бастырылды, түштамгалар таратылды.

Әйе, татар халкы үзе өчен Батырша шәхесен өр-яңадан ача һәм өйрәнә башлады. Яңача өйрәнә башлады. Батырша — тарихта тиңе булмаган батырлык үрнәге. Әйе, Батырша — татар халкының милли азатлык көрәшчесе, милләтне империягә каршы җиһадка өндәгән дин әһеле.

Батыршаның тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә үзенең ярты гомерен багышлаган фән аксакалы Мәсгуд ага Гайнетдин аны зур акыл иясе, гайрәтле көрәшче, баһадир зат итеп сурәтли:

«...Батыршаның язмалары, күтәрелеш документлары һәм хәлләре белән танышканда, барыннан да бигрәк, җитәкче шәхесе кешене хәйран калдыра, — дип яза ул. — Явыз Иван заманында ил-йорты, дәүләт-җәмәгатьчелекләре, мәктәп-мәдрәсәләре пыр туздырылып, кабат дөмкараңгы җәһилият баткагына колактан батырылган татар тормышында шул кадәр уңганлык, белем, сәләт, талант кайдан килгәндер? Нинди генә олы хезмәткә алынса да, Батырша иң югары булдыклылык үрнәкләре күрсәтә. (Максатка ирешә алмастан эше киселә икән, монда аның шәхсән үзенең тузан кадәр дә гаебе юк.) Һичнинди катлаулы вазгыятьтә дә Батырша каушау, югалып калу әсәре күрсәтми. Шунда ук ул бу, чишелеше юк диярлек катлаулы хәлләрдән чыгу-арыну кәсебенә керешә. Балкып янган ялкын диярсең: аны кул, уч белән тотып булмый. Шул үзенчәлекләре белән ул кеше генә түгел, азатлык фәрештәсе (небожитель) кебек, гали заттыр кебек күренә». («Дин вә әдәп», 2005, октябрь. — Б.З.)

Әйе, Батырша хәзрәт ул — азатлык фәрештәсе...

Һәм бүген дә Идел-Урал буйларына, Себер киңлекләренә, азатлык гимны булып, Батырша дастаны тарала, аны татар аналары сабыйларына бишек җыры итеп җырлый:

Нух пәйгамбәр токымы син, Батыршаһ!

Сәхәбәләр нәселе син, Батыршаһ!
Әүлияләр затыннан син, Батыршаһ!
Каһарман татар баласы, Батыршаһ!
Милләтеңә ирек китер, Батыршаһ!
Бәйсез дәүләтеңне төзе, Батыршаһ!

И, татар милләте!

Үз дәүләтең юкка чыкканнан соң, син шулкадәр күп газаплар күрдең ки, дөнья тарихында башка мондый мисаллар юк! Бер йомшак милләт булса, бу кадәр вәхшиләрчә, максатчан юк итүдән инде күптән беткән булыр иде, ә син һаман яшисең! Син телне дә, иманны да бирмәдең, татарлыгыңны һәм ислам динен саклап калдың! И, бөек татар милләте! Чөнки син — Аллаһның рәхмәтендә, чөнки син — Батыршаларны бирә алган милләт, чөнки син — сәхәбәләр заманыннан алып бүгенге көнгә кадәр җир шарының төньяк өлешендә ислам байрагын югары күтәреп баручы ИМАМ МИЛЛӘТ! Һәм заман ахырына кадәр шулай булып калсаң иде!

Бу әсәрем синең даһилыгыңа мәдхия булсын, ТАТАР ХАЛКЫ!

Бу язганнырым Батырша хәзрәт һәм дин-милләт өчен көрәшеп шәһит киткән милләттәшләребез рухына дога булып барсын иде! Амин.

2004-2012 еллар

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

МУСА ҖӘЛИЛНЕ ИСКӘ АЛУ

15 февраль көнне Казан каласында шагыйрь Муса Җәлилне искә алу кичәсе булды. Мәдәни чара шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салудан башланды. Һәйкәл янында узган чарада Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, шагыйрьләр Разил Вәлиев, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин һәм башка мәдәният, фән әһелләре шагыйрь-көрәшче шәхесен һәм иҗатын халык күңелендә тагын бер кат яңартты. Шул ук көнне Милли музейда Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» тантаналы рәвештә күргәзмәгә куелды, «Батырлык елларда калачак» дип исемләнгән шигырь укучылар конкурсында җиңүчеләр бүләкләнде.

ГИМН СҮЗЛӘРЕН ТӘКЪДИМ ИТҮ

21 февраль көнне Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында республиканың Дәүләт симфоник оркестры һәм Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры хоры тарафыннан Татарстанның тәүге мәртәбә дәүләт гимны сүзләре яңгырады. Гимн сүзләренең авторы — Рамазан Байтимеров, әдәби эшкәртүчесе — Гәрәй Рәхим, рус теленә тәрҗемә итүчесе — Филипп Пираев. Тарихи чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, премьер-министр Илдар Халиков һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашты. Исегезгә төшерәбез: Татарстан Республикасының дәүләт гимнының музыкасы моннан 20 ел элек кабул ителгән иде. Аның авторы — композитор Рөстәм Яхин.

РАУЗА ХӘЙРЕТДИНОВАНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

22 февраль көнне Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рауза Хәйретдинованың иҗат кичәсе узды. «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә, «Казан сөлгесе»ндәге Мөршидә, «Галиябану»дагы Галиябану, «Шәмсекамәр»дәге Разыя кебек 120 ләп хатын-кызның катлаулы, фаҗигале, кырыс һәм көлкеле сәхнә образы артистка башкаруында халкыбызның күңелендә тирән уелып калды. Иҗат кичәсендә спектакльләрдән өзекләр, хакимияттән килгән вәкилләрнең, дусларының һәм хезмәттәшләренең котлавы яңгырады.

ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

25 февраль көнне Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә булды. «Кыр казлары артыннан» дип исемләнгән әлеге әдәби-музыкаль кичәдә шагыйрьнең әсәрләреннән өзекләр, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады, ТР Мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Башкортстанның Яңавыл районы делегациясе вәкилләре, Г.Камал һәм К.Тинчурин исемендәге театр артистлары һәм башка сәнгать әһелләре катнашты.

ЯҢА КИТАПЛАР



ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ: «ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ, ИСТӘЛЕКЛӘР, ӘСӘРЛӘР, АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ, ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ, СЦЕНАРИЙЛАР» **(проект авторы һәм төз. Т.Р.Шакирова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 199 б. Тиражы 3000 данә)**

2012 ел Татарстанда тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан ителгән иде. Бу датаның күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның юбилеена – тууына 125 ел тулуга туры килүе татар җәмәгатьчелеге тарафыннан аерым мәгънә салып кабул ителде. Чөнки XX йөз башы татар җәмгыятендәге күтәрелешне әзерләүчеләр, башкаручылар – милләтебезнең зыялы, киң карашлы уллары арасында бу исем аерым бер урын тота. Ул мәдәният дип аталган киң мәйданның бик күп юнәлешләрендә башлап юл сала, яңа сүз әйтеп, үсеш юлларын билгели. Фәнни юнәлешләр буларак, татар тарихы, татар теле тарихы һәм белеме, төрки телләр тарихы һәм белеме, татар әдәбияты тарихы, дөнья әдәбияты тарихы, тәнкыйть, әдәбият белеме, теориясе, сәнгать белеме, сәяси тарих, милли мәктәпләр концепциясе, аларда укытыла торган фәннәрнең методикасы, педагогика кебек өлкәләр турында сүз барганда, Г.Ибраһимов хезмәтләренең әһәмияте, роле, урыны аермачык күзгә ташлана. Ибраһимов – татар әдәбиятын үзгәрткән, аны яңа заман әдәбияты буларак күзаллаган һәм шуның төрле сукмакларында төрле иҗат методлары ярдәмендә тәҗрибәләр ясаган, зур-зур әсәрләр язган каләм иясе дә. Ул – милли әдәбиятыбызда романтизм юнәлешенә нигез салучыларның берсе! Аның сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, журналист, публицист буларак эшчәнлеген дә онытырга ярамый.

Г.Ибраһимовка үзгә мөнәсәбәт, хөрмәт яши. 2012 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Галимҗан Ибраһимов: тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре, сценарийлар» китабы да шушы җылы мөнәсәбәтнең бер чагылышы, Г.Ибраһимов юбилей чараларының «ноктасы», тарихи-мәдәни мирас елының бер нәтиҗәсе кебек кабул ителә.

Әлеге китап «Укучы һәм укытучы» сериясен дәвам итә, ул язучы һәм аның иҗаты хакында шактый тулы һәм кызыклы мәгълүматларны үз эченә туплаган. Монда Галимҗан Ибраһимовның тәрҗемәи хәле дә, М.Х.Ибраһимов төзегән нәсел шәҗәрәсе агачы да, аның хакында истәлекләр дә җыйналган. Шулай ук әсәрләре: сигез хикәясе, «Кызыл чәчәкләр» повесте кергән. Урынлы урнаштырылган әдәби материаллар – Ш.Галиевнең «Тирән тамырлар», Х.Туфанның «Абыйлар бар иде» шигырьләре китапка матур хисси төс бирә.

Шунысы аерым әһәмияткә ия: китапта Г.Ибраһимов иҗатына гомуми күзәтү һәм аерым әсәрләренә анализ үрнәкләре чагылыш тапкан. Укытучылар өчен аеруча кирәкле һәм файдалы дәрес эшкәртмәләрен, сценарийларны төзүдә тәҗрибәле мәктәп укытучыларының катнашуы аерым игътибарга лаек.

Китапның бизәлеше, композициясе – материалны урнаштыру тәртибе турында сәнгать белгечләре әле үз сүзен әйтер. Бу яктан да китап татар басмалары арасында аерым урын тота һәм, чын мәгънәсендә, XXI гасыр китабы буларак бәяләнергә лаек. Автор-төзүчеләр, мөхәррирләр тарафыннан яратып эшләнгән китапны укучы да яратып кабул итәр дип ышанабыз.

Илдус Заһидуллин,
тарих фәннәре докторы

Индекс 54132

МИРАС
№3 / 2013